Безнен МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

09

сентябрь 2017

ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ИЛДАР ЗАРИПОВ. «МИЛӘШЛӘР»

ЯУЛАР, СУГЫШ-ОРЫШЛАР КАЛСЫН БАРЫ ТАРИХТА!

12-13 августта Изге Болгарда халыкара «Бөек Болгар» Урта гасыр сугыш уеннары фестивале уздырылды. Чараны ТР Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья конгрессы Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразиев ачты.

Фотолар «Татар-информ» сайтыннан алынды

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең Мирас 12 +

9 (285)

сентябрь 2017

1991 елның апреленнән башлап «Мирас»,
2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ
тарафыннан кабат гамәлгә куелып,
«Чын мирас» исемнәре белән чыкты.
2014 елның маеннан «Безнең мирас»
итеп үзгәртелде.

52

68 **ЙӨРӘКЛӘРДӘ ИМАЙ НАСЫЙРИ**

108 **ГАВРИИЛ ДЕРЖАВИН ИСТӘЛЕГЕ**
Руфия Мөхетдинова

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 *Галимҗан Ибраһимов*

ТАРИХИ МИРАС

4 **Төрек вә татар тарихы.** *Әхмәтзәки Вәлиди*
9 **Мөһаҗирләр хәле.** *С.Габди*
16 **Урманасты Үтәмеш: авылны кем һәм кайчан нигезләгән?** *Ф.Ислаев*
22 **Әтнә төбәгенең ташъязма истәлекләре.** *Р.Мәрданов, И.Һадиев*
30 **«Әй, кырылды адәмнәр...»** *А.Казаков*
35 **Эдуард Ганиев: «Үрнәк күрсәтү — безнең бурыч»**
40 **Туган як елъязмасы.** *М.Хәсәнов*

ТАТАР ГАМЕ

46 **Халкыбызның асыл улы.** *Р.Шәйдуллин*

ДИНИ МИРАС

52 **Ислам дөньясы.** *Г.Ибраһимов*
57 **Онытылган Барудилар.** *Х.Бәдигый*

ӘДӘБИ МИРАС

62 **Әдипнең кабере саклангнамы?** *Л.Хәмидуллин*
68 **Йөрәкләрдә Имай Насыйри**
74 **«Атаудагы хисләр»**
76 **Горурлык (хикәя).** *Ф.Гыйльми*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

79 **Сүз һәм сурәт.** *Н.Таиров*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

80 **Сәгыйть Сүнчәләй**

СУГЫШ КАЙТАВАЗЫ

82 **Татар хәрби разведчиклары.** *Р.Зарипов*
88 **Безнең иң үткен һәм иң көчле корал.** *Ә.Шамова*

СӘНГАТИ МИРАС

94 «Курай сызып, гөслә, дутар чыңгылдатып...» *Э.Каюмова*

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

96 Миллият сүзлеге. *А.Тимергалин*
97 Тәрбияле кеше туган телен бозмый. *Р.Юсупов*
104 Исемнәребез — халык мирасы. *А.Тимерханов*

ХӘТЕР САГЫНДА

108 Гавриил Державин истәлеге
110 Ядкәрләргә — бер гасыр
112 Мәрҗаниләргә һәйкәл

100 ЕЛ ЭЛЕК...

114 «Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: *1917 елның сентябрь ае.*
116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Сентябрь*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Марат Закиров
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР мәгариф һәм фән министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-91)

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Заказ №А-2017. Тираж – 1700 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 22.08.2017
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең
Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Ул хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61
телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Миләшләр». *И.Зарипов.*
1996 ел. Киндер, майлы буяу.



ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ
(12.03.1887 - 21.01.1937)

***

Яшь рух беткән өмид урынына яңадан-яңа һәм һәрберсе матурлык вә нур белән тулган өмидләр тудыра бара.

***

Бәхетле булсак, бәндәгә бәндә булмас идек.

***

Кәләшкә йөрергә шәп ат кирәк.

***

Идея фәкать гали рухларда гына яши.

***

Хуҗалар белән бергә эчсәң, һич булмаса савытта чәең, кабып эчәргә шикәрең, ашарга күмәчең булырга кирәк.

***

Кеше үзенә үзе хуҗа, һәрбер эшенә үзе мәсьүл (җаваплы).

***

Кеше ни-нәрсә эзләсә, шуны таба.

***

Адәмнең эчке дөньясы, хәят юлында кичергәннәре аның йөзендә эз калдыра.

***

Кеше идея аркасында кәмаль (камил) вә фазыйләткә ирешә. Шуның сәүкы (алга юнәлтү) илә хезмәткә тотынып, тарихта нам (шөһрәт) вә ихтирам казана.

*Текстны **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2017

ТӨРЕК ВӘ ТАТАР ТАРИХЫ

Әхмәтзәки Вәлиди

ҮЗБӘК ХАН[1] (ЯКЫНЧА 1283-1341)

Тактай урынына Мәнгү Тимернең Тогрулҗа исемендә углының Мөхәммәд Үзбәк исемендә углы хан ителде (1312). Мисыр патшасы Мәлик Насыйр Мөхәммәдкә Үзбәк якын кардәшләреннән беренең кызын биреп кодалашты, бик мәһабәт сурәттә туйлары булып үтте. Моның заманында Һүләкү балалары илә сугышлар дәвам итте, ләкин һәр ике тарафта һич нәтиҗә күренмәде.

Михаил Тверской Үзбәк хан янында. В.П.Верещагин рәсеме



[1] Әхмәтзәки Вәлидинең 1912 елда Казанда дөнья күргән «Төрек вә татар тарихы» исемле китабыннан бер бүлекчә. Кайбер бүлекчәләре журналның 2015 елгы 9 һәм 11 нче саннарында басылды.

Үзбәк хан булган вакытларда Тверь кенәзе Михаил илә Мәскәү кенәзе Георгий арасында күптән бирле низаглар дәвам итә иде. Кенәз Михаил Тверьдә рәсми сурәттә түгел, русларның ихтыяры илә генә кенәз булып тора иде. Үзбәк хан булгач та, Михаил Үзбәккә бәйгать бирмәк[2] өчен Сарайга килде. Хан янында, Сарайда ике ел кадәр торды. Үзбәк хан, моның кенәзлеген раслап, указ бирде вә бер микъдар гаскәр илә Михаилны Тверьгә җибәрде (1315). Моның соңында Михаилның көндәше кенәз Георгий, хан янына килеп, өч ел кадәр торды. Үзен хан хозурында – яхшы, Михаилны гаепле күрсәтмәк өчен, хан тирә-ягындагы әмир вә түрәләргә бирмәгән һәдияләрне[3] калдырмады. Ахырдан Михаилны кенәзлектән азат иттереп, үзе Великий кенәзлек указы алды. Хан үзенең хезмәтендә булган җарияләрдән Агафия исемендә берсен Георгийга бирде. Каугады исемендә бер әмир кул астында, бер микъдар гаскәр һәм әлеге җария илә Георгийны Владимирга җибәрде.

Михаил бу хәбәрне ишеткәч тә гаскәр илә Георгийга каршы чыкты, Каугадыга сугыш итеп, Георгийны хатыны илә әсир алды. Каугадыга күп һәдияләр биреп, сыйлап, гаскәре илә Сарайга озатты, үзен хан хозурында гаепсез күрсәтүен үтенде. Шулвакыт Георгийның хатыны Агафия вафат итте. Моны Георгий Үзбәк ханга, Михаил агулап үтерде, дип шикаять итте. Хан боларның һәр икесен дә хөкем өчен Сарайга чакырды. Һәр икесе килделәр, хөкем көнендә һәрбере үзләрен гаепсез күрсәтү өчен, артык дәрәҗә иҗтиһад иттеләр. Ханның гаскәренә каршы сугыш итүе вә аның биргән җариясен агулап үтерүе кеби гаепләр өчен, Михаил үтерелде вә Георгийга тагын элеккеге вазыйфасы кайтарылды (1318).

Бу эшләр соңында Михаилның Дмитрий исемендә угылы Сарайга барып, ханның күңелен йомшартырлык сүзләр сөйләде вә әтисенең ханга ихлас булуын исбат итәргә тырышты. Хан аны Тверьгә кенәз итте. Михаил балалары илә Георгий арасында дошманлык гаять каты иде. Георгий Болгар юлы илә Сарайга китте. Моны ишетеп, Дмитрий янә кардәшләре илә Сарайга барды, хан хозурына һәр икесе керделәр. Дмитрий ачу илә хан сараенда Георгийны кылыч илә чапты да үтерде. Дмитрий янә кыйсас өчен[4] үтерелеп, Дмитрийның энесе Александр Теврьга кенәз ителде (1325).

Сарай хөкүмәте рус вилаятьләренә баскак исеме илә әмирләр куя иде. Күп вакыт ошбу баскаклар рус руханиларын хөрмәт итмиләр, кәнисләр хираҗдан[5] мәгаф ителгән[6] була торып та, хираҗ алалар иде. Баскакларның ошбу эшләрен русларның митрополитлары Үзбәк ханга белдерде. Үзбәк хан

Үзбәк хан сарайда

[2] Бәйгать бирү – буйсынуны белдерү.
[3] Һәдия – бүләк.
[4] Кыйсас – үтерүчегә үлем җәзасы бирү.
[5] Хираҗ – мөселман булмаганнарга салына торган салым.
[6] Мәгаф ителгән – азат ителгән.

ошбу сәбәптән митрополит кулына ярлык язып бирде. Ярлык ошбу эчтәлектә: *«Мин Үзбәк үземнең барлык бөек һәм урта һәм кечек кенәзләргә, барлык вәзирләргә, әмирләр вә дәфтәрче, вә баскак, вә язучы, вә илчеләргә, вә һәрбер хөкемем йөргән тарафларның халыкларына фәрман итәмен: нәсари вә гайреләрнең барлык руханилары, поплары, монахлары, кәнисәләр вә гыйбадәт урыннары вә ошбу кәнисәдә гыйбадәт урыннарына тәгаен ителгән милекләр, вәкыфлар – барысы да хираҗдан коткарылган. Боларга һич берәү кул тигезәчәк булмасын! Чөнки болар Алла өчен әзерләнгәннәр. Болар безгә вә безнең гаиләләребезгә дога кылсыннар. Әгәр берәү, боларга каршылык итеп, болардан бер-бер нәрсә алачак булса, аннан өчләтә түләтелер. Әгәр берәү боларны үтерсә, Алланың кәһаре аңа булсын! Язылды: куян елында, көз фасылында, беренче айның дүртенче көнендә».*

1327 елда Үзбәк хан бәгъзе эшләрне ислях өчен якыннарыннан Чал хан (Шәфкал) исемендә берсен бераз гаскәр илә Тверьгә җибәрде. Тверь кешесе Александр вә иптәшләре русларга ошбу эшне: «Татарлар безне ислам диненә көчләргә, әгәр тыңламасалар, бөтен русларны кол итеп алырга киләләр», – дип күрсәттеләр. Ошбу сәбәптән гаскәргә каршы зур фетнә купты. Кенәз Александр Шәфкалны тавышсыз гына гаскәре илә үзенең сараена кертте. Александрның командасы буенча, халык төн илә сарайны ихата кылып алдылар да гаскәргә һөҗүм итәргә керештеләр. Аз гына гаскәр, бераз үтерешүдән соң, янә сарай эченә керде. Ошбу вакыт Александр үзенең сараена ут салды, гаскәрләрнең берсе калмый янды. Тверь халкы шәһәрдә булган барлык мөселман сәүдәгәрләрен үтереп бетерде.

Моның өчен Үзбәк гаять хурланды, бөтен рус кенәзләренең котлары очты, чөнки

Дмитрий хан сараенда Георгийны үтерә



Хан сараенда Яңа ел башлануны бәйрәм итәләр. Рәшидетдин кульязмасыннан миниатюра. 1330нчы еллар

Үзбәк моның илә бөтен рус кенәзләрен гаепле дип игълан итте. Тикшерү соңында фәкать Тверь халкының гына гаепле идекен белде. Мәскәү кенәзе Иван Калитаны Сарайга чакырды вә илле мең гаскәр биреп, Тверьдәге юлбасарларга әдәп бирергә җибәрде. Суздаль кенәзе Александрга гаскәр илә Иван янында булырга боерды. Боларның килүен ишетү илә Тверь кенәзе, җинаятьче Александр Псковка качып китте. Иван Калита Тверь, Кашин, Турҗик (Торжок) калаларын таш өстендә таш калдырмый һәлак итте. Халыкларның урамннарга качканнары гына котылды. Үзбәк Иван Калитага бүләк итеп Великий кенәзлек указын биреп, Мәскәүгә җибәрде. Мәскәү ошбу вакытка кадәр кечкенә шәһәр иде, зурая башлады.

Иван гакыллы, хәйләкәр кеше иде. Бер яктан, хан хозурында итагать күрсәтә, икенче яктан, бөтен русларны бер ноктага җыю өчен, мөмкин кадәр иҗтиһад сарыф итә иде. Бу гакыллы Иван русларга истикъляль[7] орлыгы чәчте. 1340 елда Иван вафат итеп, угылы Симеон бөек кенәз итеп билгеләнде. Үзбәк хан 1341нче ел вафат иите.

***

Үзбәк хан, Батудан соң, Сарай ханнарының иң эшлекле, гадел, башка мәмләкәтләрдә иң нафизле[8], галим вә голәмәгә иң якын падишаһыдыр. Үзбәк гадел-

[7] Истикъляль – бәйсезлек.
[8] Нафиз – сүзе үтә торган.

лек илә дус, кайчакта исламның вә гыйлемнең таралуына, мәмләкәтнең тынычлык вә рәхәтлегенә күп хезмәт итте.

Үзбәк вакытында Сарай вә башка шәһәрләрдә булган тәртипкә мәдәни мәмләкәт сәяхәтчеләре хәйран булдылар. Бу вакыт Дәште Кыпчакның Сарай, Маҗар, Судак, Кырым, Кәфа, Азак, Хуарз кеби шәһәрләре дөньяның иң мәгърур шәһәрләреннән санала иде.

Сарай шәһәре Үзбәк вакытында кямил зураеп, кямил интизам[9] алып төзелеп җитте. Урамнары киң вә төз, йортлары бер-берсенә тоташ булып, араларында җимерелгән вә бозылганнары булмас иде. Шәһәр халкы татар, чиркәс, рус, кыпчак, рум халыкларыннан гыйбарәт булып, һәрбер таифә үзенә аерым мәхәлләдә тора иде. Базарлар да бик эшлекле вә зур булып, Гыйрак, Мисыр, Шам тарафларыннан мөселман сәүдәгәрләре күп була, бу сәүдәгәрләр тагын Сарайда аерым бер мәхәллә булып утыралар иде. Боларның мәхәлләләре мал илә тулы булганлыктан, малларын саклау өчен мәхәлләләре кальгалар илә ихата ителгән иде. Хан сарайлары үзенә аерым уратылып алынган вә биек урында алтыннан ай сурәте куелган иде[10]. Хан сараен «Алтын таш» дип атыйлар иде.

Сарайда мөселманнар шәфигый вә хәнәфи мәзһәпләрендә булып, шәфигый, мәлики, хәнәфи мәзһәпләрендә фәкыйһ вә голәмәләр күп була иде. Мөселманнарның унөч биек җомга мәчетләре, моннан күп өлешләр илә артык башка мәчетләре бар иде. Үзбәк хан галим вә голәмәгә артык дәрәҗә мәхәббәт вә ихтирам итте.

Үзбәк сараеның бөек голәмәсеннән шәех Ногман әл-Хәрәземне һәр көн килеп зиярәт итә, шәех Ногман аны хөрмәтләп каршы алмый иде. Аяк үзрә торып урынфәлән күрсәтми, бәлки бөек падишаһ Үзбәк үзе шәех Ногманның алдына килеп тезләнә һәм түбәнчелек илә генә сөйли иде. Хәлбуки, шәех Ногман үзе фәкыйрь вә гарипләргә артык дәрәҗәдә хөрмәт вә кадер итә иде.

Исламның җәгърафия[11] голәмәсенең зурларыннан ибн-Батутта ошбу Үзбәк хан хозурына килде вә гадәттән тыш кадер-хөрмәт күрде, хан вә хатыннарыннан күп һәдияләр алды.

Ибн Батута әйтүенчә, Дәште Кыпчак халкында угрылау булмас, бу сәбәптән боларның маллары сакчысыз торыр. Угрылап тотылса, малны хуҗасына кайтару һәм янына үзенең малыннан тугыз мәртәбә кушып, ун итеп бирү тиештер. Әгәр көче җитмәсә, балалары алына, балалары да булмаса, үтерелә иде. Килгән-киткәннәрнең һәммәсе боларның кунакларыдыр. Һинд илә меңләп мал куып сәүдә итәләр. Ун меңнәр илә аяклы малларга ия булган адәмнәр болар арасында күп була. Хатыннарын гаять хөрмәтлидерләр, пәрдәсез гизәләр...

Үзбәк хозурында мөселман, гарәп галимнәре хөрмәт күргән кеби, Яуропаның христиан галимнәре дә зур хөрмәтләр күрделәр. Мәшһүр Марко Поло ярым күчмә, ярым мәдәни булган Үзбәкнең мәмләкәтендәге байлыкка, аның бөеклегенә, мәһабәтенә вә гаҗәеп тәртипкә гаҗәпләнә.

Үзбәкнең Тәнибәк, Җанибәк, Хозырбәк исемнәрендә угыллары калды. Тәнибәк Үзбәкнең вафаты вакытында Ак Урдада иде, урынына Җанибәк хан була торды. Тәнибәк гүзәл егет иде. Фәкать хан сарае эчендә Тәнибәк урынына Җанибәкнең хан булуы тиеш булганлыктан, Тәнибәк Сарайга кайтып җитәр-җитмәстән юк ителде вә Җанибәк хан булып калды. ■

---

[9] Кямил интизам – камил тәртип белән.
[10] Галәмәт итеп ай кую гарәпләрдән, исламнан калган эш түгел, төрекләрдән калган бер гадәттер. – *Автор иск.*
[11] Җәгърафия – география.

2008-2013 елларда Красноярск краендагы Казанка, Югары Казанка, Икшермә, Яңа Тимершык, Стәрлетамак кебек 18 авылның, Иркутск өлкәсендәге Черемшанка авылының оешуына йөз тулу уңаеннан, җирле халык бу вакыйганы зурлап бәйрәм итте.

Элегрәк Идел-Урал буе татарлары Себер киңлекләренә каторгага хөкем ителеп яки йомышлы-хәрбиләр буларак күчерелсә, бер өлеше сәүдә-кәсеп эшләре белән үзләре барып төпләнсә, XX йөз башында исә П.А.Столыпин реформалары нәтиҗәсендә гади крестьяннар күпләп Урал аръягына, Себергә һәм Ерак Көнчыгышка максатчан күчерелгән. Күченүне гамәлгә ашыру өчен, 1906 елда «мөһаҗирләр идарәсе» (переселенческое управление) һәм «җир төзү» (землеустроительный) комитетлары төзелә. Төмән һәм Том губерналарына Казан һәм Уфа төбәгеннән күченгән татарлар җирле себер татарлары белән бер авылга урнаштырылган һәм андагы халыкның мәдәнияте, хуҗалыгы үсешенә йогынты ясаган. (Әмма 1909 елда Столыпин хөкүмәте Көнбатыш

Мөһаҗирләр хәле

Төмән имамы С.Габди

Уфа губернасыннан күченүчеләр. Бертуганнар Сәхибгали һәм Сәедгали (уртада) балалары белән. 1936 ел

Себернең уңайлы районнарына күченүче халыкка бушлай биләмә бирүне, төрле ташламаларны, ссудаларны бетерә һәм җирне бай крестьяннарга сата башлый).

Шулай итеп, Көнбатыш Себер губерналарына күченү ярлы крестьян өчен мөмкин булганлыктан, татарлар, ачлык, җир җитмәү һәм утынга кытлык булу сәбәпле, туган авылларын ташлап, 3-4 мең чакрымдагы Енисей, Иркутск һәм Байкал арты губерналарына күченгән. Әмма руслар һәм украиннарга караганда татарлар, тормыш авырлыгына соңгы чиккә кадәр түзеп, һиҗрәткә шактый соң кузгала. Моның объектив сәбәпләре дә булган. Беренчедән, мөһаҗирләр идарәсендә, җир төзү комитетларында нигездә руслар гына булып, анда татар мәнфәгате аз якланган. Икенчедән, татарлар арасында Себергә күченүне пропагандалау шактый соң башлана. Рус телендә Себернең табигатен, анда күченү тәртипләрен тасвирлаган белешмә китаплар даими рәвештә чыгып халыкка таратылган вакытта, татар телендә шундый эчтәлектәге «Урал артына һиҗрәт» исемле бер генә китап бар. Ул да шактый соң, 1913 елда гына басылып чыга. Бу һәм башка сәбәпләрнең нәтиҗәсе буларак, татарларга начар һәм иң ерак җирләр калган. Әгәр дә без Красноярск крае һәм Иркутск өлкәсе карталарына күз салсак, татар авылларының тимер юл, зур шәһәр һәм елга буйларыннан шактый еракта, караңгы урман эчендә урнашканлыгын күрәбез.

1907-1911 елларда Енисей губернасында 52 татар авылы нигезләнә, аларның күбесе хәзерге Пировский районына туры килә (бүген дә биредәге халыкның 30 проценты татар). Иркутск губренасының Нижнеудинск һәм Балаган өязләренә мең ярымнан артык татар күчеп китә.

Әмма Себер тайгаларына күченү вакытында фәкыйрь авыл агае коточкыч зур мәшәкатьләр кичергән. Дәүләт тарафыннан һиҗрәт бик түбән дәрәҗәдә, начар оештырылган. Крестьяннар йорт-җирне сатып, үзләре өчен бөтенләй ят булган җирләргә гаилә, бала-чагасын, хуҗалык өчен кирәк-яракны да алып чыгып киткән. Алар өчен махсус тәгаенләнгән «столыпин вагоннары» айлар буе барган. Юл авыр һәм газаплы булып, «сигез ат төялә торган вагоннарга кырык кеше чебен шикелле килеп тыгылган», авыручы пассажирларны станцияләрдә төшереп калдырганнар. Күченәчәк участокларда да эш тиешле дәрәҗәдә оештырылмаган, шалаш, землянкада яшәү өстенә, һәр җирдә ришвәт, күчеп килүчеләрне җирле халык, хакимият вәкилләре тарафыннан талау һәм җәберләүләр күзәтелгән.

Татар игенчесенең Себер тайгаларына күченгән вакытта күргән михнәт-газаплары Төмән имамы С.Габдинең 1910 елда «Вакыт» газетасында басылган (№672. – 26 сент.; №673. – 28 сент.) «Мөһаҗирләр хәле» исемле мәкаләсендә чагылыш таба. Авторның мәкалә язуда максаты күченергәме, күченмәскәме, дип икеләнеп торган мөселман игенчеләренең күзен ачу, аларны чынбарлык белән таныштыру булган.

Шуны да искәртик: хәзерге әдәбиятта «мөһаҗирлек», «һиҗрәт» кебек сүзләр татарларның Госманлы дәүләтенә күчеп китүенә бәйле кулланылса, революциягә кадәрге матбугатта Себергә күченгәннәрне дә «мөһаҗирләр» дип язганнар.

***

Соңгы елларда Русия эченнән Сибирия тарафына әллә никадәр мөһаҗирләр күчеп килделәр. Фәкать бу мөһаҗирләрнең начар вә кызганыч хәлләре күп кешеләргә мәгълүм улмады. Гүя ки анлар Русиядә ватаннарында вакытта җирләренең азлыгыннан бик аптыраган, бер-бер артлы берничә сәнәләр игеннәрнең уңмавыннан тәмам ач вә мохтаҗлыкка калган иделәр дә Сибириягә килү илә әүвәлдәге начар хәлләреннән тәмам котылдылар, йирләре күп булды, тыныч кына

тамакларын туйдыра башладылар. Гүя алар фәкыйрьлектән байлыкка, рәхәт дөньясына чыктылар, хәлбуки мөһаҗирләрнең күргән мәшәкатьләре вә мөһаҗирләр башына килгән бәла вә җәфалар гакылларны хәйран калдырыр дәрәҗәдәдер. Бичараларны мөһаҗәрәт тәмам эштән чыгарды. Һиҗрәт сәясендә бөтен гаиләләре илә рисвай[1] булдылар. Ошбу һиҗрәт бакчаларының иң ачы йимешләрен безнең мөселман кардәшләребез татыдылар, һиҗрәт бабындагы наданлыклары сәясендә һаман да шундай күңелсез хәлләргә төшеп тормакталардыр. Һиҗрәт ишеге ачылганнан бирле хөкүмәт кешеләре, һичбер милләт вә дин әһелен аермаксызын, халыкны Сибирия тарафына күчәргә димлиләр вә бу чиновниклар һиҗрәт итүчеләргә һәртөрле уңайлыкларны вә ярдәм итүләрне вәгъдә кылалар. Әлбәттә, алдын-артын уйламаган кешеләр күчеп китүнең кайда барып терәләчәген белмиләр. Кайда булса да ватаннарын ташлап күчеп китүне ихтыяр итәләр. Ләкин ошбуны кабул итүчеләр байлар түгел. Чөнки байлар вә бала-чагасы юк кешеләр кайда булса да көн итә, бәлки бәгъзеләре күчүчеләрнең йирләрен үзләренә калдырып, шул тора торган ватаннарында ныклабрак урынлашырга тырышалар. Әмма туган-үскән илләрен ташлап китүчеләр исә – дөньяның тормышыннан бизгән, фәкыйрьлек вә гаҗизлек илә аптырап беткән бала-чагалы, зур семьялы кешеләрдер. Менә шундый бичаралар киләчәк көннәрендә күңелсез сәгатьләр булачагын исләренә алмай: «Без инде яңа җиргә күчәмез, фәкыйрьлектән котыламыз», – дия, ата-бабадан калма йирләрен җыеп саталар яки банкага заложить итәләр. Шуннан соң туып-үскән йортларын вә йорт әсбапларын ярым бәһагә төрле тарафларга урынлаштырып, кулларына бераз акча хасил итәләр дә көтү кадәр бала-чага илә яңа йиргә «баерга» чыгып китәләр. Фәкать яңа йиргә барып йиткәнче юлда үзләрен ниләр көтә? Хәбәрләре юктыр.

Авыл киртәсеннән чыкмаган хатын-кызлар, сабыйлыктан котылмаган балалар: «Машинага утырамыз! Пароходка утырамыз!» – дия, куанышып сөйләшәләр. Чынлап та, әгәр мөһаҗирләрнең күчеп бара торган вакытлары матур җәй урталыгында булса иде, бераз күңеллерәк вә хозуррак булыр иде. Ләкин җәй көнендә күчәргә тугры килми яисә хөкүмәт, авыру-сырхаулар куәтләнер, күбәер уе илә җәй көнендә күчәргә рөхсәт бирми. Бәс, мөһаҗирләргә һиҗрәт сәфәре яз көнендә яисә көз көнендә, яхуд[2] бөтенләй кыш урталыгында тугры киләдер. Кайсы вакытта улса да, бичараларның арбаларга төялеп барган вакытларында ук өстләренә кар яки ягъмур явып кәефләрен йибәрә, кан яшьләре илә кардәш кабиләсеннән аерылган хатын-кызлар, ата-аналарының күңелсез хәлләрен күреп эчләренә агу йоткан балалар суыклыктан яки ягъмур юеше үтүдән туңа башлыйлар. Юллар начар була, атлары тарта алмый, арбалары әле бер йирдән, әле икенче йирдән бозыла вә ватыла. Шулай да көч-хәл илә ыстансә, яхуд пароход пристаненә килеп җитәләр.

Имди машинага килеп йиттек яки пароходка килеп йиттек, ат берлән килгәндәге кыенлыкларны күрәчәк түгелмез, машинада булса да, пароходта булса да рәхәтләнеп барырмыз, дия шатланышалар, фатирга кереп чәй эчәләр, елыналар, ләкин ыстансәгә килеп: «Безгә фәлән йиргә машина кайчан булыр икән?» – дип сорасалар: «Бу көн поезд юк, иртәгә, фәлән сәгатьтә!» – җавабын алалар. Пароход конторына төшсәләр дә шулай ук. Мәгәр мөһаҗирләр күбрәк поезд илә йөриләр. Бәс, әлеге һиҗрәт сәфәренә чыккан бичараларга вокзалда юеш вә туңган көе булса да поездны икенче көнгә кадәр көтәргә тугры килә. Төн суык, хафа илә йокылар качкан, балалар өстләре юешлеккә борчылалар.

[1] Рисвай – хур, мәсхәрә.
[2] Яхуд – яки.

Төн үтә. Иртән поезд килеп җитә. Кычкырыша-еглашына «машинага» – вагонга утырышалар, ләкин болар утырган вагоннарда адәм бер сәгать чыдаралык түгелдер, чөнки мөһаҗирләр утыра торган вагоннар япон сугышы вакытында гаскәр йөретер өчен хәзерләнгән иделәр. Бу вагоннарда ике яклап зур капкалар вә дүрт йирендә кечкенә генә тәрәзәләр була. Урта йирләрендә даими ягылып тора торган тимер мич, уртадан һәм ике яклап сәке ясалган, яисә катлау-катлау шүрлекләр корылган була. Сигез ат төялә торган вагоннарга кырык кеше чебен шикелле килеп тыгыла. Бичаралар, шул вагоннарга төялеп, ыстансәдән кузгалып китәләр. Озатырга килгән тирә-күршеләр вә дуст-ишләре, кан-яшь илә егълап, тилмерешеп катып калалар. Аһ, газиз ватан вә сөекле бабаларының тапкан йирләре! Нә чара ки, күзләрдән гаиб[3] булды! Машина үз юлында чаба, вагоннар да калмыйлар, фәкать вагоннарның эчләре күңелле түгел. Ачык ишекләреннән буранлы йилләр исеп тора. Йитмәсә, ишек төпләрендә хатыннар, вагондагы һәртөрле җенестән җыелган халыкның күбесе исерек вә бөтен вагонда тәмәке тартмаган кеше күренми, каюсы ачы тавыш берлән җырлый вә каюсы еглый, балалар шаулашалар. Шул балалар өстендә исерекләр акырып-бакырып сугыша башлыйлар. Һәр тарафтан төрле әшәке сүзләр ишетелеп тора. Азрак сулу алып йокламак түгел, тик утырмак өчен бер сәгать тыныч вакыт юк. Ашар-эчәр идек, табигатьне боза торган һәртөрле начар исләр уйнап тора. Хатыннар үзләренә зарланалар. «Башым авырта, баламызга суык тигән, артымдагы тәңкәмне кисеп алганнар», – кеби сүзләр илә колаклар шау килә, һәркем сабырсызлана. Аз гына инсанияте бар кешеләр, өйләрендә вакытта кара икмәк ашап, фәкать тынычлыкка аптырап ятканнарны исләренә алалар, ләкин эш узган, яңадан әйләнеп кайтмак имкяне[4] юк, зирә[5] йортларын вә йорт әсбапларын юк бәһагә сатып бетергәннәр, йирләре кулларыннан ычкынган. Кире кайтып иске тереклекне табарлык өмид калмамыштыр. Һәр сәгать вә һәр минут зәхмәтле уйлар башка килеп торса да, бернәрсә кылып булмый – поезд һаман бара. Бер-ике көн баргач, пересадка була, ягъни икенче вагонга күчеп утырырга туры килә. Зур ыстансәгә килеп туктыйлар. «Вагонда начар вә суык булды, вокзалда бераз елынырбыз», – дия, аңгы-миңге булып, вагоннан нәрсәләрен чыгаралар. Боларны: «Вагоннан төшкәнне көтеп тора торган «калай кылычлар»сыз таралмагыз, бергә баракка барамыз, әле сез бу көннәрдә китә алмыйсыз, бу көн китүчеләр нәүбәт-чират көтеп баракта бер атна яттылар, сезгә дә берәр көн көтәргә лязим була», – дия, вокзал эченә йибәрми, салкын йил вә буранга каршы яки йилләп яуган ягмур астында бичараларны көтү-көтү туплап, барак юлы илә алып китәләр. Каюсы күтүмкәсен күтәреп вә каюсы икешәр баласын асып, ике-өч чакрым кадәр ераклыктагы баракка җәяүләп баралар. Канаты сынган күгәрчендәй хатыннары, анасыз калган чебиләр кеби балалары «Йә Алла, йә Ходай» илә карлы-бозлы һавада былчырак юлларны сөреп, барак дигән йортларга барып керәләр.

Дөрест, баракларны хифзыссыйхәткә[6] муаффәкъ итәргә[7] дә тырышалар, фәкать телсез хайваннар бәрабәрендәге хохол җәмәгате арасында ничек нәзафәтне[8] сакларга кирәк?! Шул сәбәпле баракларда бик сасы вә бик былчырак буладыр. Әле Чиләбегә йиткәнче бик ул кадәр читенлекләр булмый, зирә Чиләбегә кадәр улган пересадка-

[3] Гаиб булды – күздән югалды.
[4] Имкян – чара.
[5] Зирә – чөнки.
[6] Хифзыссыйхәт – сәламәтлекне саклау.
[7] муаффәкъ итәргә – туры китерергә.
[8] Нәзафәть – пакьлек-пөхтәлек.

ларда мөһаҗирләр аз улганлыктан, юлда, төшкән ыстансәләрдә озак торырга тугры килми. Әмма Чиләбегә килеп йиткәч, тиз чыгып китмәк мөмкин түгел. Бердән, Чиләбедә икенче вагоннарга күчеп утырырга лязим була – һәр йирдә пересадка. Һәм дә мөһаҗирләр юл кирәгенә хөкүмәт тарафыннан бирелә торган акчаларын Чиләбедә туктап алалар.

Әгәр Чиләбедә мөһаҗирләр күп җыелган булсалар, яңа килгән мөһаҗирләр нәүбәт[9] көтеп берничә көн яки берничә атналар яталар һәм дә мөһаҗирләр күп җыелган чакларда баракларның эчләренә сыеша алмыйлар. Бичара мөһаҗирләр гаиләләре илә баракның ишеге алдында, ачык һавада, кар-ягъмур астында кичлиләр, фатирга барсалар – акча кирәк. Мәгълүм ки, мөһаҗирләрдә акча булмый. Акчалары булса да, киләчәктә кирәк урыннары күренеп торганлыктан, фатирда торып расходланасылары килми. Читен, бик читен булса да, шул бараклырының ихатасында яталар, менә шул вакытларында араларында авыру сырхаулар заһир[10] була. Юлда салкын тию илә яки әүвәлдәге авырулары көчләнүе илә хатын-кызлар, бала-чагалар авырый башлыйлар.

Юлларында вакытта, ягъни һиҗрәт сәфәренә чыкмастан әүвәл сау-таза булган хатыннар, сау-сәламәт булган балалар, юл газабының йөдәтүе сәбәпле, юлда вакыт ук яисә баракларга килгәч тәмам саусызланалар. Әле ярты юлларын йитмәгән булсалар да, араларында авыру-сырхаулар күбәя. Авыруларны исә тизлектә больницага алалар һәм авыру көенчә беркая йибәрмиләр. Гаиләсе арасында сихәтлек булмаган мөһаҗирләр, йә шул авыруларын бер хәл булганчы көтеп яталар яки калдырып китәргә мәҗбүр булалар. Бичаралар, ничек итсәләр дә кыен, ничек итсәләр дә ачы хәсрәт. Әгәр калдырып китсәләр, ул калган сөекле якыннарын икенче мәртәбә йә күрә алалар, йә юк. Сәламәтләнеп, арттан барып йитәрлек булсалар берхәл иде, ләкин күбрәк авырып калучылар бала-чагалар һәм аз канлы хатыннар булганлыктан, сәламәтләнүләрен өмид итәрлек тә булмыйдыр. Әгәр көтеп ятсалар, әле ул кайчан сәламәтләнә, ярты юлда туктап күп вакытларын уздырырга, бар кебек акчаларын ашап бетерергә тугры киләдер. Хәлбуки мөһаҗирләргә тизрәк барып йитеп кирәк-яракны корыштыра башларга вә юлда акчаны бетермәенчә саклый барып, барган йирдә иң кирәкле нәрсәләрне сатып алырга лязим[11] иде. Нә эшләмәк кирәк? Бәгъзе вакытта гаилә башы булган олуглар авырып китәләр. Бичара балалар кая барсыннар? Баш кешеләре берхәлгә килгәнче көтеп ятарга мәҗбүр булалар һәм дә яхшук кешеләрнең балалары ачы көннәрне татып, хәерчелеккә әйләнәләр. Шулай да мөһаҗирләр күбрәк вакытта авыруларны көтеп ятмыйлар, газиз балаларын вә сөекле җефетләрен юл буенда төрле йирләрдә калдырып китәләр. Салкын тию сәбәпле, авырый башлаган балалар вә бала имезә торган хатыннар, табигатьләре нечкәлектән һәм дә куәтле авыруны күтәрерлек хәлләре булмаганлыктан, тиз сәламәтләнә алмыйлар вә күп вакытта дөньдан үтәләр. Менә шул бичара мөһаҗирләр бара торган йирләренә барып җиткәнче, юлда вакытта ук әһел әүләдләрен[12] төрлесен төрле йирләрдә таратып бетерәләр. Нә чара ки, гаилә арасыннан бер бөртеген дә әрәм итәсе килми, ләкин тәкъдир адәм баласының күз яшенә игътибар кылмыйдыр.

Юлда барган вакытында газиз балаларын төрле йирләрдә дәфен кылмай[13] вә

---

[9] Нәүбәт – чират.
[10] Заһир була – барлыкка килә.
[11] Лязим – тиешле.
[12] Әһел әүләдләрен – балаларын.
[13] Дәфен кылмай – җирләми.

төрле урыннарда калдырмай бара тоган йирләренә барып йиткән кешеләр – бик бәхетле мөһаҗирләрдер. Бичаралар Чиләбедән китсәләр һаман шул сигез ат, кырык кеше утырта торган вагоннарга төялеп китәләр. Мәгълүм ки, мондый вагоннарның тәрәзәләре бик кечкенә һәм бик югары, кар яки ягъмур яуган вакытта капкачлары ябык була, чебен кеби тыгылган халык күзләр тонардай караңгылыкта кала. Чиләбедән киткән вагоннар бигрәк тә тыгыз булалар, чөнки һәр тарафтан җыелган мөһаҗирләрнең бара торган юллары – Чиләбедән Себергә таба киткән юллардыр. Һәр вагон саен хисаптан тыш халык тула. Вагоннар тәмам сасыйлар, былчыраналар, түзә алмаслык дәрәҗәдә тавышлы булалар. Йитмәсә, мөһаҗирләр утырган поездлар һәр ыстансәдә туктап, озак торалар. Машиналар туктаган вакытта вагон капкаларының ачыклыгыннан файдаланып, хатыннар бала искеләрен юып киптерәләр. Шулвакытта ачык капкалардан карарга барган балаларның рельс өстенә егылып төшүләре дә булгалый. Кыскасы, бичара мөһаҗирләр һәр ыстансә саен туктап вә һәр йирдәге баракларда төшеп калып төрле хурлыкларны күреп, берничә атналардан соң билгеләнгән йирләренең тугрысындагы актык ыстансәгә килеп йитәләр, ләкин һаман күңелләре тынычланмый, чөнки боларның бара торган йирләре ыстансәгә якын түгел, бәлки әллә ничә чакрымнар читтә, еракта буладыр. Соңгы елларда ыстансәләргә якын участкалар юктыр. Инде нишләргә кирәк? Әшәке булса да, машина юлы ярый иде, ләкин инде машина юлы бетте вә вагоннардан төшерделәр. Пароходлар дәхи[14] булмый. Чөнки пароход берлән барырлык урыннарны мөһаҗирләр мөкаддәмрәк[15] мәшгуль иткәннәр. Бәс, чар-начар[16] атларга утырып барырга лязим була, бәгъзе вакытларда атлар да булмый, яхуд ат берлән йөрерлек юллар салынмаган булалар. Бәс, бичараларга берникадәр чакрым йирләрне җәяүләп барырга тугры киләдер. Әгәр дә участкалар ыстансәгә якынрак җирләрдә булсалар, ничек тә тиз барып йитәрләр иде, ләкин хәзер участкалар тимер юллардан берничә йөз чакрым йирләрдә генә калмыштыр. Ат берлән барырга мөмкин булган йирләрдә дә бик кыйммәт булалар. Илтеп куярга ямщикләр күп акча сорыйлар. Шунлыктан, акчалары бар кешеләр бер атны бөтенләй сатып алырга мәҗбүр булалар, ләкин ялгыз ат алып бармый, арба яки чана вә ат җигү нәрсәләре алырга тиеш була. Бунларны, зарурәт көчле булганлыктан, әлбәттә, тиешле бәһасенә алынмый, әллә никадәр артык бәһа биреп алырга тугры килә, чөнки сатучылар беләләр ки: боларга ат-арба бик кирәк. Бәс, сатучыларның инсафлары нигә йитсә, бичараларның шулкадәр акчаларын алып калалар. Менә бусы мөһаҗирләр өчен уйламаган расход һәм иң зарур акчаларын юлга ташлау кабиленнәндер.

Элегрәк, ягъни мөһаҗирләр яңа күчә башлаган вакытларда участкалар ыстансәләргә һәм иске карьяләргә якын булаганнар. Һәм дә юллар яхшы булганлыктан, ыстансәләр илә участкаларның арасын йөрү читен булмаган, карьядән карьягә туктап, кирәк-ярак ашамлык, эчемлекләр алып, фатирларга кереп хәл җыеп барырга мөмкин булган. Ләкин хәзер алай түгел: ыстансәләргә һәм иске карьяләргә якынрак җирләрдә участкалар тәмам беткәннәр. Ераклаша-ераклаша имди участкалар йә бөтенләй кеше басмаган сахраларда яисә бәдәвиләр яши торган җирләрдә, яхуд бөтенләй кеше керә алмаслык караңгы урман араларында гына калганнар. Хәтта бәгъзе учаскаларның юллары да юк, диләр. Бәс, бичара мөһаҗирләр каюсына барсалар да уңайсыз. Асылын, хакыйкатен белмәгән сахраларга барып керсә дә, адашкан

[14] Дәхи – тагын.
[15] Мөкаддәмрәк – баштарак.
[16] Чар-начар – теләр-теләмәс.

хайван хөкемендә калалар, чөнки болар теләгән һичнәрсә юк. Барып йиткән сәгатьтә әүвәл кое казырга ябышалар. Мәгълүм ки, Сибирия сахраларының күбесе сусыз яки сулары булса да, эчәргә яраклысы бик тозлы була. Әгәр бәдәвиләр арасына килеп керсәләр, дәхи күңелле түгел. Телләрен аңламыйлар, бәдәвиләр исә читтән килгән халыкны ачык йөз белән каршы алмыйлар – куркалар.

Вә әгәр бер дә кеше басмаган караңгы урман арасына барып бушансалар, тәмам аптырап калалар, чөнки агачтан башка бернәрсә дә юк. Нә эшләргә? Ташлап кире кайтып китәргә хәл калмаган һәм дә килгән вакытта күргән юл газаплары күз алларында уйнап йөриләр. Землянка ясый белсәләр, землянка ясап, бала-чаганы елыга кертәләр. Әгәр землянка ясый белмәсәләр, яхуд агачсыз участкаларда булсалар, землянка ясар өчен дә күп мәшәкатькә төшәләр. Бичараларның бала-чагалары берничә кичләрне шалашта яки арба астында, яхуд бөтенләй ачык һавада кичерәләр. Агач булмаган участкаларда мөһаҗирләр берничә айларны вә хәтта берничә елларны землянкаларда уздыралар. Йорт-йир корыштырырга яраклы агачларның урыны бик ерак булганлыктан һәм дә юллар төшеп йитмәгәнлектән, кирәк кадәр агачларны тиз килтереп булмыйдыр. Шул сәбәпле, бичаралар барган йирләрендә дәхи ярты гомерләрен кыскарталар. Землянкалар исә бала-чагалар илә торыр өчен бик уңайсыз, тыгыз, юеш һәм былчырак вә караңгы булалар. Шул сәбәпле, балалар арасында тир хастасы дигән куркынычлы хасталар тарала. Бу авыру күп балаларны һәлак итмәктәдер. Бичаралар юлда вакытта нәзер итеп калдырган балаларын да заигъ итеп бетерәләр. Мөкаддәмрәк мөһаҗирләр иске карьяләргә якынрак йирләргә күчкәнгә күрә, әүвәл елларны фатирларда торып уздырганнар. Әмма хәзер исә, югарыда әйттегемчә, иске карьяләргә якын участкалар калмаган. Бәс, йөз чакрымлы яки ике йөз чакрымлы йирләрдән йөреп, ничек яңа йиргә урынлашырга кирәк? Бу мөмкин түгел. Шунлыктан, хәзер яңа йиргә барган мөһаҗирләр, йә шул барган йирләрендә урынлашып калырга тырышалар яисә яңадан шул тарафтагы ерак карьяләргә кайтып, искедән тереклек кылучыларга хидмәткә керешәләр, яхуд бөтенләй соранып ризыклану юлын тоталар. Бичараларга ничек итсәләр дә читен: балалары, юл буенда татыган газапларының ачысына түзә алмай кайсы кайда төрле йирләрдә тәләф булып беткәнлектән, яхуд гаилә арасында сәламәт кеше калмаганлыктан, барган җирләрендә урынлашырга да күңелләре тынычланмый. Әгәр урынлашмасалар, актык каннарына кадәр иза вә җәфа чигеп килүләре бушка чыга. Менә һиҗрәт галәмендә әсир булган адәм балаларының хәлләре вә татыган йимешләре ошбуыннан гыйбарәт. Бу безнең күз алдыбыздан үткән кадәресе һәм һиҗрәтнең читтән карап күренгән нәтиҗәләре генәдер. Әмма һиҗрәтнең эченә кереп кителсә һәм дә мөһаҗирләрнең барган йирләрендәге мәшәкатьләрен карап күрелсә, бу язып ишарә кылдыкларым бик аз булып калачактыр. Нә булса да, Җәнабе Мәүла бичара мөһаҗирләргә хәерле ярдәм бирсен.

Ленар Гобәйдуллин *әзерләде.* ■

---

[17] Заигъ итеп – югалтып.
[18] Тәләф – бозылып.

Чирмешән районындагы Урманасты Үтәмеш авылының килеп чыгу тарихы, башка авыллар кебек үк, серле һәм катлаулы. Аның башлангыч тарихын ачыклауны Үтәмеш атамалы авылларның берничә булуы шактый катлауландыра, чөнки биредә уртак тамырлар булу ихтималы бар. Чирмешән районында ике Үтәмеш авылы булса, Лениногорск һәм Тәтеш районнарында да шундый ук исемле авыллар билгеле.

Урманасты Үтәмеш: авылны кем һәм кайчан нигезләгән?

Фәйзелхак Ислаев

Һәр авылдагы шикелле үк, Урманасты Үтәмештә дә авылның килеп чыгуы турында риваятьләр сакланган. Алар бик күп булмаса да авылны нигезләүчеләр турында мөһим мәгълүмат бирә. Үтәмеш авылларының исеме турында авыл халкы арасында сакланган берничә риваятьне китерәбез.

«Сөембикә-ханбикәнең Үтәмешгәрәй исемле улы булган. Имеш, шул Үтәмеш дигән кеше Иске Үтәмеш авылыннан Урманасты Үтәмеш авылына күчеп килгән. Ике бертуган Үтәмешевлар, икесе ике авылга бүленеп, безнең төбәккә нигез салганга охшый». Биредә Урманасты Үтәмеш авылына Иске Үтәмештән күчеп килгән кешеләр нигез салган, дигән фикер дөреслеккә туры килсә дә, ул тулаем алганда тарихи чынбарлыктан ерак тора. Үтәмешгәрәйнең бу тирәгә килеп чыгу мөмкинлеге юк дәрәҗәсендә, ул Мәскәүдә, Иван Грозный карамагында яши һәм шунда вафат була.

Икенче риваять: *«1552 елда Казанны Иван Грозный гаскәрләре яулап алгач,*

анда яңа рус хакимиятенә каршы бунт купкан. Бунтта катнашкан Үтәмеш, эзәрлекләүдән качып, авыл төзеләчәк урынга, кизләү янына килеп төпләнгән. Ул чорда тирә-юньне куе урман уратып алган. Авылны Үтәмеш бабаның исеме белән атаганнар». Менә монысы тарихи дөреслеккә якынрак, чөнки чыннан *40 хуҗалык элекке урында калган, 40 хуҗалык – Югары Чагатай авылына, 40ы Урманасты Үтәмеш урынына килеп урнашкан.* Чыннан да, 1796 елда язылган документка караганда, Иске Үтәмештә – 52 йорт, Урманасты Үтәмештә – 46, Югары Чагатайда 36 йорт булган[1].

да Иван Грозный гаскәрләре Казанны алгач, 1552-1557 елларда татар халкы, җимерелгән ханлыкны яңадан торгызу өчен, биш елга сузылган изге көрәшкә күтәрелә, тик, көчләр тигез булмаганлыктан, җиңелә. Баш күтәрүдә катнашучы буларак, эзәрлекләүдән, көчләп чукындырудан шикләнгән казан татарлары Көньякка, Көньяк-Көнчыгышка һәм Көнчыгышка күчеп китә башлый. Шулар арасында Үтәмеш бабай да булырга мөмкин. Тик аның бирегә кайчан килеп утыруы гына билгесез.

Иң күп таралган һәм тарихны дөрес тасвирлаган өченче риваять буенча, *Урманасты Үтәмешне Иске Үтәмештән аерылып чыккан кешеләр нигезләгән. Иске Үтәмешнең халкы бик күбәеп киткән, 120 хуҗалыкка җиткән һәм авыл халкы 3 төркемгә бүленгән:*

Кызганыч, бу риваятьтә авыл халкының бүленү сәбәбе һәм вакыты әйтелмәгән. Шулай да, авыл халкы, Иске Үтәмештән ерак булмаган җайлы урыннарны үз биләмәсе итеп саклап калу өчен, эшкәртелгән җирләр, печәнлекләр, урман-кырлар авылдан бик ерак булмасын, дип кайгырткан булуы көн кебек ачык. Ә бәлки бу күчеш Кама аръягында икенче саклау ныгытмаларын, Чирмешән һәм Шушма крепостьләрен төзегәннән соң, әлеге якларга күпләп руслар һәм башка халыкларның (чуаш, мордва, калмык) вәкилләре җир эзләп килеп, яңа авыллар нигезләвенә бәйле булгандыр.

Бу риваятьтәге «Зкә аерылып 3 авыл төзелгән» дигән мәгълүмат Чирмешән җирлеге өчен генә чынбарлыкка туры килә. Моңа өстәп, хәзерге Лениногор-

[1] РГАДА. Ф. 1355, Оп.1. Д. 1874. Л. 345 об.



ски районында, Самара өлкәсе белән чиктә, кечкенә генә Яңа Үтәмеш авылы барлыгын һәм ул авылны 1770 нче елларда Иске Үтәмештән чыккан кешеләр нигезләгәнлеген искәртеп үтү кирәк. 1785 елда биредә 39 ир-ат теркәлгән, димәк, 9-10 йорт булган, дип әйтеп була. Шулай булгач, 3 урынга түгел, 4 урынга күчеп киткән Иске Үтәмеш халкы.

Ә Чирмешән районында иң борынгы авылларның берсе булган Иске Үтәмеш авылына килгәндә, аңа XVI гасырның ахырында, яисә XVII гасырның өченче чирегендә (1675 елга кадәр) хәзерге Чүпрәле районындагы Яңа Шәйморза авылыннан күчеп килгән 17 гаилә нигез салган. Аларның юлбашчысы Чабак исемле булган.

Кызганыч, Үтәмеш авылын нигезләүчеләр арасында биредә Үтәмеш исеме дә, фамилиясе дә күренми. Ә кагыйдә буларак, авыл – авылны нигезләүче исемен, яисә элекке атамасын ала. Шәйморзадан күчеп килүчеләр яңа авыл нигезләмәгән, ә бәлки элек булган Үтәмеш авылына гына килеп кушылган, дигән фикер туарга мөмкин.

Сембер өязе Олы Тархан вулысы Үтәмеш авылы (хәзер Тәтеш районы) турында да мәгълүмат биреп китәргә кирәк. Ул авылның нигезләнү вакыты – 1698-1699 еллар. Биредә яшәгән татарларның Россия патшалары сараена турыдан-туры буйсынганлыгы, удель крестьяннар булып, оброк түләп һәм дә башка дәүләт йөкләмәләрен башкарганнары билгеле. Мондый статустагы татар крестьяннары Тау ягындагы авылларда очрый, тик аларның саны күп түгел. Үтәмеш халкы үзенең патша крестьяннары икәнлеген белгәч тә, әллә көчләп чукындыра башлагач, биредән икенче урынга, шул ук Чирмешән төбәгендәге Иске Үтәмеш авылы урынына күчеп киткән булырга мөмкин. Шуңа күрә, бу авыл белән Чирмешәндәге Иске Үтәмеш авыллары арасында да ниндидер бәйләнеш булуы бик ихтимал.

Шунысын әйтергә кирәк: Урманасты Үтәмеш авылына Иске Үтәмештән Бохарай бабай җитәкчелегендә күчеп килүчеләр нигез салган. Шуңа күрә, авыл беренче мәртәбә 1782 елны халык санын язып алган документта «Верхний Ключ, Бухарайкино тож» дип теркәлгән.

Авылга нигез салучы Бохарай бабайның нәсел башы Мәмәт Дербышев дигән йомышлы татар турындагы хәбәр 1661 елгы документка теркәлгән. Шушы елны Мәмәт бабага һәм тагын 32 иптәшенә Олы Тигәнәле авылы (хәзерге Алексеевск районы) җирләреннән Русия дәүләтенә хезмәтләре өчен җир биләмәләре бүлеп бирелә[2]. Бу йомышлы

[2] НА РТ. Ф. 20. Спасский уездный суд. Оп. 1. Д. 3. Дело по отношению Чистопольского уездного суда от 15 мая 1807 г. за № 549 о спорной между обывателями деревень Больших и Средних Тигин и Новоадыльшиной земле. – Т. 1. Л. 74-75.

Урманасты Үтәмеш авылы

татарлар Идел буенда урнашкан Кострома, Ярославль, Романов (Тутаев) шәһәрләрендә яшәгән йомышлы татарлардан булырга мөмкин. Алар, нигездә, нугай, себер, әстерхан, казан татарларыннан формалашкан мишәрләр булса кирәк. Фамилиясеннән чыгып карагандa, Мәмәт бабай татар халкында мәшһүр Шәех Дирбеш нәселенә мөнәсәбәтле булырга мөмкин.

Мәмәт бабаның Тигәнәле авылында күпме гомер иткәне билгесез. XVIII гасыр башында аның улы Бимәй Мәмәтов гаиләсе белән хәзерге Чүпрәле районындагы Иске Шәйморза авылында яшәгән[3]. 1729 елда Бимәй баба вафат була. Шул ук елны аның оныгы Рахманкол, авылдашлары белән берлектә, Иске Шәйморзадан аерылып чыгып, Яңа Шәйморза авылын нигезли. Әтиләре Биккенә Бимәев кече уллары белән иске нигездә кала.

1758-1760 еллар тирәсендә Яңа Шәйморзадан – Рахманкол Биккинин, Иске Шәйморзадан Биккенә Бимәев гаиләләре Иске Үтәмеш авылына күчеп килә. Барлыгы Иске Шәйморзадан – 7, Яңа Шәйморзадан 2 гаилә Үтәмешкә күченә[4]. Биккенә бабаның икенче улы Бикколның гаиләсе аталары нигезендә, Иске Шәйморзада кала. Алары да 1771 елда Яңа Шәйморза авылына китеп урнаша. Иделнең ике ярында урнашкан татар авыллары арасындагы йөз елдан артыкка киткән күчеп йөрүләр, алар арасында электән калган бәйләнешнең өзелмәве татар иленең киң пространствоны үзләштерүен яхшы чагылдыра.

Рахманкол Биккинин гаиләсе башта Иске Үтәмештә урнашкан. 1766 елга караган документта Биккенә һәм аның улы Бохарай Үтәмеш авылы кешеләре буларак күрсәтелә. Шушы елның мартында алар Мәмәт бабаларыннан мирас булып калган Тигәнәле авылындагы 50 чирек (четверть ~ 75 дисәтинә) биләмәне шушы авыл кешеләренә сатып калдыралар. Ул вакытта Биккенә бабаның шундый ук күләмдәге җир биләмәсе Шәйморза авылында да калган була[5].

---

[3] РГАДА. Ф. 350. Ландратские книги и ревизские сказки. Оп. 1. Д. 158. Книга переписная служилых новокрещенов, мурз, татар, чувашей, дворовых людей в дворах мурз Ногайской дороги Казанского уезда. 1716 г. Л.52об-53.

[4] РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Д. 1221. Сказки о служилых татарах и чувашах Ногайской дороги Казанского уезда. 1762-1772 гг. Л. 136об, 1353, 1373 об.

[5] РГАДА. Ф. 1209. Поместный приказ, Вотчинная коллегия и Вотчинный департамент. Оп. 2. Д. 6945. Отказная книга г. Казани с городами. Дела молодых лет. Л. 308об.

Шулай итеп, без Урманасты Үтәмеш авылы 1766-1782 еллар арасында Үтәмештән аерылып чыгучылар тарафыннан нигезләнгән, дип әйтә алабыз. Димәк, Урманасты Үтәмешне һәм Иске Үтәмешне ике бертуган Үтәмешовлар нигезләгән, дигән риваять тарихи дөреслеккә туры килми.

1782 елгы халык санын алу вакытында авылда 22 ир-ат һәм 17 хатын-кыз теркәлә. Әлеге кешеләрнең барысы да Биккенә бабаның уллары Бохарай, Габделкәрим, Баязит һәм аның туганнары нәселеннән[6]. Ул үзе авыл аерылганчы ук вафат булган. Олы улы Рахманколның балалары барчасы да Иске Үтәмештә кала. Ул вакытта авыл әле Урманасты Үтәмеш исеме белән йөртелмәгән, ә Югары Чишмә дип аталган. Авылның старостасы булып, 1796 елда вафат булганга кадәр, аңа нигез салучы Бохарай баба Биккинин торган. 1795 елдагы ревизия сказкасында Бохарай Биккининга – 70, аның хатыны Гөлбәрбану Сөендековага – 53 яшь.

Шулай итеп, Иске Үтәмештән күчеп килеп Урманасты Үтәмеш авылына нигез салучы Бохарай Биккинин булганлыгы архив документлары белән раслана. Ә авылга нигез салынган вакыт 1766-1782 еллар, дип әйтергә мөмкин. 1795 елда авылда үткәрелгән халык санын исәпкә алу вакытында авылны «яңадан салынган – новопоселенный» дип юкка гына теркәмәгәннәр.

Кама аръягындагы авыллар арасында Бохарай авылы турында тагын хәбәрләр бармы? Бар. 1735 елның 1 августына караган документта Бохарай авылы һәм анда яшәүче Бәкер Кулаев, Заһит Аитов һәм Бәкернең туганы Бикмәтнең Бигәш (хәзер Әлмәт шәһәре составына кергән) авылында үткәрелгән җыелышта катнашуы турында мәгълүмат бар. Авыл 1735 елларда ясалган картага да төшерелгән. Тик шулай да 1735 елда искә алган Бохарай авылы һәм Урманасты Үтәмешнең Бохарае белән уртаклык бөтенләй юк. Биредә искә алынган Бохарай авылы хәзер дә яшәвен дәвам итә, ул Зәй районында урнашкан.

Урманасты Үтәмешнең өченче атамасы да бар. Ул Югары Чишмә дип тә атала. Иске Үтәмешнең дә икенче исеме «Үтәмеш, Түбән Чишмә, шул ук Мансур», дип, «Вакыт дәрьясында Иске Үтәмеш» китабы авторлары ялгыша[7]. Чыннан да «Үтәмеш, Түбән Чишмә, шул ук Мансур» дип аталган авыл бар, тик ул Иске Үтәмеш авылы түгел, ә Югары Чыгтай авылы. Бу фактны архивта сакланган 1796 елгы карта бик яхшы раслый, чөнки биредә «Иске Үтәмеш», «Үтәмеш, Югары Чишмә» һәм «Үтәмеш Түбән Чишмә, шул ук Мансур» авыллары картага төшерелгән.

Шулай итеп, авыл исемнәрен тикшергәннән соң, мондый нәтиҗәгә киләбез: Урманасты Үтәмешнең исеме алмашынып торган: Үтәмеш – Югары Чишмә – Бохарай – Урманасты Үтәмеш. 1811 елны үткәрелгән халык санын алган вакытта язылган Урманасты Үтәмеш исеме хәзерге көнгә кадәр сакланган.

Алда язылган буенча, авылның нигезләнү вакыты 1766-1782 еллар булуга карамастан, төрле язмаларда, авылның нигезләнгән вакытын ачыкламыйча, риваятьләргә яисә документларга сылтама ясап, 1735, 1760, 1785 еллар һәм XIX гасыр башы, дип тә әйтелә. Шулай да да Урманасты Үтәмеш авылының нигезләнгән вакыты 1766-1782 еллар арасы хакыйкатькә туры килә, чөнки нәкъ шушы еллар арасында, әйткәнемчә, бу авылга Үтәмештән чыккан Бохарай бабай һәм аның туганнары күчеп килә.

Тик Бохарай исеме ни өчен 1795 елда Үтәмеш исеменә алмашынган? Бу иң четерекле сорауга әлегә кадәр җавап

[6] 8. ЦГИАРБ. Ф. И-138. Оп. 2. Д. 22. Ревизская сказка. 1795 г. Л. 99-100об.
[7] Закиров Ә., Закирова М. Вакыт Дәрясында Иске Үтәмеш. – Бөгелмә, 2015.
[8] 9. ЦГИАРБ. Ф. И-138. Оп. 2. Д. 84. Ревизская сказка. 1811 г. Л. 177.

табып булмады. Бохарай Биккинин вафат, аның балалары, ни сәбәптәндер, 1795 елга кадәр авылдан икенче урынга күчкән. Шуңа күрә, 1795 һәм 1796 елларда Үтәмеш авылларының җирләре картасының авторы Бохарай турында бернинди сүз дә язмаган.

Урманасты Үтәмеш авылына башка авыллардан да кешеләр күчеп утырганнар: Әлмәт авылыннан (хәзер Әлмәт шәһәре) – Мөлековлар, Мәмәттән (хәзер Әлмәт районы) – Хәсәншиннар. Тимәш (хәзер – Лениногорск шәһәреннән 3 км читтә) авылыннан да булган күчүчеләр, чөнки авылда Мөлековлар заты, Тимәш заты, Мәмәт, Җәлил затлары булган.

Икенче яктан, Урманасты Үтәмеш халкы да башка авылларга күчкәләп торган. 1810 нчы елда Бохарай бабайның барча нәселе, улы Рәхмәтулла белән Габделкәрим бабай Иске Иштерәк-Каратай авылына күчеп китә[8]. Бу авыл хәзерге Лениногорск районында, Мөэмин Каратай дип атала. Урманасты Үтәмештә Биккенә бабай нәселеннән Фәиз бабайның өлкән улы Нигъмәтулла гына кала. Гомумән алганда, авылда 1811 елгы ревизия вакытында ир-ат затыннан барлыгы 10 кеше генә теркәлә. Иске Үтәмештә дә Биккенә бабайның нәселе кими. Шул ук 1810 елда бу авылда яшәгән Рахманкол Биккининнның оныклары Миндән, Хәмит, Вахит, Гыйсмәт Әминовлар һәм Рәхмәтулла Субаев Бөгелмә өязенең Туктар авылына китеп урнаша. Бу авыл да хәзерге Лениногорск районында, Туктар Урдалысы дип йөртелә.

Табигый, Урманасты Үтәмеш егетләре кәләшләрне үз авылларыннан гына түгел, тирә-яктан да алган. 1795 елгы материалларга нигезләп, шуларның берничәсен атап китик: Денис, Мәмеш, Тимәш, Чыршылы, Урмышлы, Сарабиккол, Кара Чишмә, Түбән Каменка, Чаллы, Керкәле һәм башкалар.

***

Урманасты Үтәмеш авылы административ яктан төрле өлкә-губерна составына кергән. Әүвәл бу җирләр Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы, Нугай Урдасына караган. XVIII гасырның утызынчы елларына кадәр биредәге халык Казан һәм Уфа өязләре арасында булган, тик кайсы авылның кайсы өязгә керүен ачыклау өчен, махсус тикшерү кирәк. Иске Үтәмеш авылы да, Урманасты Үтәмеш тә Уфа өязенең Казан юлы авыллары арасында, беркадәр старшина Нәдер Уразмәтов вулысында исәпләнгән.

Урманасты Үтәмеш авылы 1917 елгы революциягә кадәр административ яктан Бөгелмә өязенең Мордва Афонькәсе вулысына кергән дип атау да дөреслеккә бик туры килми, чөнки ул төрле вакытларда төрле вулыска караган. Шуларны документларга нигезләп атап үтик: Яңа Афонькә (1795-1816), Денис (1834), Спиридон (1850), Яңа Куак (1858), Мордва Афонькәсы (1867-1920). Ә Бөгелмә өязе башта Оренбург, аннары Уфа губерналарына, 1850 елда Самара губернасы оештырылгач, яңа административ берәмлек составында 1920 елга кадәр булган.

1920 елда, ТАССР оешканнан соң, Бөгелмә Татарстан составында кантон дип атала башлый, ә Урманасты Үтәмеш авылы Иске Куак, Чирмешән вулыслары составында 1930 елга кадәр исәпләнә. 1930 елның 10 августында вулыслар, кантоннар бетерелеп районнар оештырылгач, Урманасты Үтәмеш үзе аерым авыл советы булып 1935 елга кадәр Шөгер (хәзер Лениногорск), аннары 1936 елның гыйнвар ахырыннан Беренче Май районына керә. 1963 елдан – Лениногорск районы составында. 1965 елның 12 гыйнварыннан бүгенге көнгә кадәр Урманасты Үтәмеш авылы Чирмешән районында. ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2017

Республикабызның Әтнә районы җирлегендә гарәп язулы татар кабер ташлары гаять күп сакланган. Тарихчы галимнәр Гали Рәхим 1927-1928 нче елларда, Һарун Йосыпов 1947, 1956 һәм 1959 елларда Әтнә төбәгенең XVI-XVII гасырларга караган ташъязмаларын өйрәнеп, фәнни әйләнешкә керткәннәр[1]. Галим Марсель Әхмәтҗанов китапларында да төбәкнең кайбер зиратларындагы кабер ташлары хакында мәгълүмат бирелгән[2]. Шулай да, Әтнә районының моңа кадәр эпиграфик максатта тулаем өйрәнелмәгәнен истә тотып, 2015-2016 елларда бу төбәктә фәнни-эпиграфик экспедицияләр үткәрдек.

2015 елның яз һәм көз айларында районның 25 авылындагы 29 зират-каберлектә барлыгы 722 тарихи кабер ташы өйрәнелеп, исәпкә кертелде, фотога төшерелде, үлчәмнәре теркәлде, текстлары укылып, махсус тәртип белән язып алынды. 2016 елда 24 авылдагы 35 зират-каберлек тикшерелеп, гарәп язулы 755 ташъязма өйрәнелде. Нәтиҗәдә, киң күләмле һәм катлаулы эш башкарылып, район җирлегендәге 49 торак пунктның (берничәсе хәзерге вакытка беткән) зират һәм каберлекләрен өйрәндек, 1477 кабер ташын исәпкә алдык һәм тикшердек.

Өйрәнелгән ташъязмаларның өчесе XV йөзгә, 58 данәсе XVI, дүртесе XVII, берсе XVIII гасырга нисбәт ителә, калган зур күпчелеге XIX йөзгә һәм XX йөз башына карый.

ӘТНӘ ТӨБӘГЕНЕҢ ТАШЪЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Раиф Мәрданов, Ирек Һадиев

ИҢ БОРЫНГЫ ЯДКӘРЛӘР

Югары Сәрдә авылының борынгы зираты шактый зур һәм тарихи ташбилгеләргә бай. Аны халык «Юкәсәр Изгеләр зираты» дип йөртә. Монда XV гасырның икенче яртысына һәм XVI гасырның беренче яртысына караган 11 кабер ташы табылды. Сакланышлары төрле дәрәҗәдә: бөтеннәре дә, калдык хәлендәгеләре дә бар. Даталары төгәл укылганнары арасында иң элеккесе 1476 елга, соңгысы 1536 елга карый. Гали Рәхим 1930 елда басылган мәкаләсендә Югары Сәрдә авылының әлеге «Иске зират»ына (галим зиратның аталышын шул рәвешчә күрсәткән) гомуми тасвир ясаган, анда барлыгы 8 ташбилге булуын белдергән. Ташъязмаларның үзе укыган кадәр текстларын һәм үлчәмнәрен биргән. Һарун Йосыпов әлеге зиратта җиде таш күргәнен, шуларның икесендә язулар юклыгын әйтеп, биш ташъязманың текстларын теркәп калдырган[3]. Һ.Йосыпов мәкаләсен басмага әзерләгән һәм аны искәрмәләр белән тулыландырган Марсель Әхмәтҗанов 1973 елның җәендә шушы зиратта 9 кабер ташын исәпкә алган[4]. Без күргән 11 ташның тугызында текстлар укылды, унынчысында бер генә булса да сүз ачыкланды,

[1] Рахим А. Татарские эпиграфические памятники XVI века // Татарстанны өйрәнү җәмгыяте хезмәтләре = Труды Общества изучения Татарстана. Т.1. – Казань, 1930. – С.145-172; Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / төз. Р. Мәрданов, И.Һадиев. – Казан: Җыен, 2008. – Б.214-283; Юсупов Г. Эпиграфические памятники Атнинского района Республи-

1 рәс. **Әтнә районындагы иң борынгы ташъязма. Югары Сәрдә авылы. 1476 ел**

Г.Рәхим һәм Һ.Йосыпов укылышларына шактый өстәмәләр һәм төзәтмәләр кертелде, даталар һәм кеше исемнәре ачыкланды.

Галимнәр тарафыннан моңарчы бөтенләй телгә алынмаган, бик таушалган, җирдә ятучы үзенчәлекле эпиграфик истәлек Югары Сәрдә авылының бу зиратындагы һәм, гомумән, Әтнә районындагы иң борынгы ташъязма булып чыкты. *(1 нче рәсем)*. Ул 1476 (1477) ел белән даталана. Ташның сакланышы, әйткәнебезчә, яхшылардан түгел, кайбер язулары, мәсәлән, кеше исеме, танылмый. Бу ташның эшләнеш-бизәлеше XVI гасыр истәлекләреннән аерылып тора: язу юлларын бүлү өчен төрле ысулдагы үсемлек орнаментлары һәм ике үрелмәле тасма сыман бизәкләр кулланылган, бордюрының (таш читенең) буеннан-буена дини гыйбарә язылган. Тексты һәм бордюр язуы белән моңа охшаш ташны Һ.Йосыпов Арча районының Урта Аты авылында күреп укыган булган[5]. Ул таш та датасы белән Югары Сәрдәнекенә бик якын – 1475 (1476) елгы. Ихтимал, аларны бер үк оста эшләгәндер. Юкәсәр Изгеләр зиратында 1499 (1500) елгы таш та сакланган.

Югары Сәрдә авылының көньяк читендә дә борынгы каберлек

ки Татарстан // Татарская археология. – 2005. – №1-2. – С.71-84.

[2] Әхмәтҗанов М. Олы Мәңгәр авылы тарихы. – Казан: Идел-Пресс, 2000. – Б.26-28; Әхмәтҗанов М. Татар археографиясе: милли-мәдәни мирас хәзинәләре системасына сәхифәләр. – Казан, 2011. – Б.131-134, 148, 153-154, 178, 181, 190, 204, 209.

[3] Юсупов Г. Эпиграфические памятники Атнинского района Республики Татарстан // Татарская археология. – 2005. – №1-2. – С.74-76.

[4] Татарская археология. – 2005. – №1-2. – С.85.

[5] Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.–Л.: изд-во АН СССР, 1960. – Приложение: текст 3.

бар, хәзерге вакытта андагы бер чардуган эчендә Казан ханлыгы чорына караган ике таш сакланган. Гали Рәхим берсенең алгы ягындагы язуларны тулаем укыган (әмма бер санын ялгыш укып, 1533 елга туры килә, дип күрсәткән, чынлыкта исә ул 1540 елга карый). Текстның 5-6 юлларындагы «Мөлкеәман угылы Мамай газатка барганда» дигән өлеше галим тарафыннан «Мөлек-Әман угылы Мамайгол тәка барганда» рәвешендә укылган, биредәге «тәка» сүзен аңлата алмавы белдерелгән. Марсель Әхмәтҗанов әлеге гыйбарәне «Мәлик Аман углы Мамай Голатка барганда» дигән үз вариантында язып: «Голатны – Алат каласының исеменең бер фонетик яңгырашы диеп саныйбыз», – дигән фараз тәкъдим иткән[6]. Ике белгечкә дә табышмак тудырган «газатка» сүзе «изге сугышка» дигән мәгънәгә ия, болай укылышның шиксезлеге кабер иясенең «кяфер кулындин шәһид» булуы белән дә раслана. Гали Рәхим, каберлектәге икенче ташъязманың берничә юлы гына сакланган, дип белдергән, без ул укыган кадәр текстны ян-яклардагы язулар белән тулыландырдык.

Ашыт елгасының биек уң яры өстендә борынгы гасырларда Әйшияз шәһәрчеге («Кала тавы») урнашкан мәйдан билгеле. Аның янындагы «Хан каберлеге»ндә өч данә борынгы кабер ташы хәзерге вакытка кадәр сакланып калган. Әмма аларда язулар юк, хәтта аерым хәреф элементлары да беленми. Археолог галимнәр бу ядкәрләрне XVI гасырныкы дип билгеләгән. Гәрчә аларда язу һәм бизәк элементлары сакланмаса да, калыплары һәм үлчәмнәре (84x42x26 см һәм 86x63x20 см) – бу ташларның шул чорга караганына дәлил. XVI гасыр кабер ташларының уртача 73-125 см биеклектә, 42-63 см киңлектә, 20-30 см чамасы калынлыкта булуы фәнни хезмәтләрдә дә язылган һәм эш тәҗрибәбез белән дә раслана.

«Хан каберлеге»ннән ярты чакрымлап көнбатышта «Изгеләр зираты» дип аталган тагын бер урын бар, тик анда элекке кабер ташлары юк. Җирле халык бу ике каберлекне ханнар, аларның якын даирәсе, дин әһелләре белән бәйләп, төрле риваятьләргә керткән. Ул риваятьләрдә 960-985 еллар аталган. Безнең уебызча, болар – һиҗри даталар. Аларны миладига күчергәндә 1553-1577 еллар килеп чыга һәм бу чынбарлыкка якын. Мөгаен, әлеге еллар биредә кальга булып тупланып яшәгән татарларның соңгы чорына нисбәтледер.

«Кала тавы» турында татар тарихчылары хезмәтләрендә мәгълүматлар бар. Хөсәен Фәезхановның 1863 елгы «Казан тарихы», Шиһабетдин Мәрҗанинең 1885 елгы «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтләрендә бу урында, чынлап та, борынгы татар шәһәр-крепосте булганлыгы язылa[7]. Шундый ук фикер төбәк тарихчысы С.М.Шпилевский хезмәтендә дә әйтелгән[8].

Иң борынгы ташъязмаларның тагын берсе Ябынчы авылы янындагы аерым каберлектә. *(2 нче рәсем.)* Ул Ябынчы исемле кешенең 1503 елда вафат булган улына куелган. Хәрефләре уалган булу сәбәпле, аның исемен төгәл уку мөмкин түгел. Мәрхүмнең атасы, XV гасырда яшәгән Ябынчының исеме бу авыл атамасында сакланган, дип уйларга төпле нигез бар. Ә таштагы «солтан» сүзе,

[6] Әхмәтҗанов М. Татар археографиясе: милли-мәдәни мирас хәзинәләре системасына сәхифәләр. – Казан, 2011. – Б.153.

[7] Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык / төз.-авт. Р.Мәрданов. – Казан: «Җыен», 2006. – Б.114-115, 232-233; Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татар. китап нәшр., 1989. – Б.160-161. Югарыда күрсәтелгән китапта Хөсәен Фәезхановның татар халкы этногенезы уңаеннан белдергән кайбер фикерләре фән өчен инде искергән. Мәсәлән, Казан арты төбәгендәге кайбер авылларның «чирмешләрдән татарлашкан» дигән фаразы белән килешеп булмый. Авыл атамаларының килеп чыгышы башка бер телгә нисбәтле булуына нигезләнеп кенә аларда яшәгән халыкны да шул тел вәкилләренә бәйләргә тырышу ялгыш. (Шунда ук, Б.23-24.)

[8] Шпилевский С.М. Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губернии. – Казань, 1877. – С.487-488.

2 рәс. **«Иң борынгы ташъязмаларның тагын берсе Ябынчы авылы янындагы аерым каберлектә». 1503 ел**

3 рәс. **Иске Мәңгәр авылының борынгы зиратындагы кабер ташы. 1531 ел**

шул заман ташъязмаларына хас булганча, «морза» мәгънәсен белдерергә дә, Ябынчының атасы исеме булырга да мөмкин. Бу ташъязма турында моңарчы басылган бер мәгълүмат та тапмадык. Әлеге истәлекнең язулы өслеге өчтән үрелгән тасма сыман бизәк белән каймаланган. Ә бишенче һәм җиденче юллар астына ясалган бизәкләре Югары Сәрдәнең 1476 елгы ташындагы юл арасы бизәкләренә бик охшаш.

Иске Мәңгәр авылының борынгы зираты – Казан ханлыгы чорыннан калган каберлекләрнең иң зурларыннан берсе. Биредә XVI гасырга караган, түзек хәлендәге яки ватылган өлешләр рәвешендәге 14 данә борынгы ташбилге теркәлде. Аларның иң элеккесе 1495, соңгысы 1543 ел белән даталана. Гали Рәхим үзе өйрәнгән вакытта биредә 15 кабер ташы булганлыгын язган. Гәрчә хәзерге вакытта ташлардагы язулар шактый җуелган булса да, берничәсенең текстларына безнең тарафтан өстәмәләр һәм ачыклыклар кертелде. 1495 һәм 1531 елларда куелган ташъязмалар турында мәгълүмат һәм аларның текстлары Гали Рәхимдә юк, гомумән, алар – татар эпиграфикасында әһәмиятле (һәм тарихи җәһәттән, һәм сәнгати бизәлеше ягыннан) өр-яңа табышлар. *(3 нче рәсем.)* Г.Рәхим күреп өйрәнгән, 1594 елда вафат булган Җәнәйсолтан Чапкын хатынына бу зиратта куелган ташъязма бүген Татарстан Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана. Хәзергәчә сакланмаган тагын бер таш 1920 нче еллар ахырында ук ватылып яткан, Г.Рәхим аның кисәкләрен җыеп укыган мәгълүматлардан күренгәнчә, мәрхүм «кяфер кулындин шәһид» булган. Яхшырак сакланган арткы өслегендә ташбилгене анасы Күрекле бикә куйдырганлыгы бик үзенчәлекле матур бизәк эченә язылган. Шуңа охшаш штамп-бизәкләрне без Олы Бәрәзә һәм Комыргуҗа

зиратларындагы борынгы ташларда да күрдек. Аларның беренчесе 1520 елга, икенчесе 1541 елга карый. Димәк, Иске Мәңгәрнең борынгы зиратында без тапмаган ташны да якынча 1520-1541 елларда куелган дип санарга мөмкин.

4 рәс. **Кече Әтнә авылының борынгы зиратындагы ташъязма истәлек. 1598 ел**

Иске Мәңгәрнең борынгы зиратыннан ерак түгел, аның көнбатыш тарафында чардуган белән әйләндереп алынган, ике зур агач үсеп утырган аерым каберлек бар. Халык телендә ул «Әүлия кабере» дип йөртелә. Гали Рәхим андагы ялгыз ташның текстын тулаем һәм төгәл итеп укый алмаган, датасын да танымыйча, XVI гасырның беренче яртысына нисбәт итү белән чикләнгән. Безнең тарафтан ташъязманың елы (927 һиҗри = 1521 милади) укылды, Г.Рәхим «Әҗем угылы Бикбау» дип күрсәткән исемнең дөресе «Хаҗим угылы Баубик» икәнлеге тәгаенләнде. Ә шушы исемнән соң язылган хатын-кыз исемен «Кичәш бикәч» дип укыйбыз. Алга таба шушы хатын-кызга караган «Аккына бикәч» дигән сыйфатлама танылa. Ташның артындагы текстның укылышын да Г.Рәхим тулаем биреп бетермәгән. Безнең укылыш мондый: «Бу ләүхне атасы Хаҗим белә валидәсе ... бина кыйлды». Димәк, Баубикнең атасы Хаҗим белән анасы яшь киленнәре Кичәшкә шушы ядкәрне куйдырганнар.

Кече Әтнә авылының борынгы зираты шактый мәйданны били. Анда сакланып калган җиде кабер ташы шулай ук XVI гасырга нисбәтле, арада 1507, 1524, 1540, 1543, 1598 еллар белән даталанганнары бар. Болардан 1598 елгысы, гомумән, беренче тапкыр укылды. *(4 нче рәсем.)* Г.Рәхимнең 1524 елгы ташъязма текстындагы кеше исемнәре арасында бер сүзне ялгыш укуы аннан соңгы буын белгечләренең кайберләре тарафыннан хаталы фикер-нәтиҗәләр ясауга сәбәп булган. Дөреслектә «Ябынчы ибне Акбулад» дигән исемне ул «Ябынчы табын Акбулад» һәм «Ябынчы Ак табын Булад» вариантларында тәкъдим иткән. Монда бөтен хикмәт таштагы «ибне» сүзен ялгыш тануга бәйле. Беренче карашка, «ибне» сүзен «табын» дип тә уку ихтималы бар кебек, әмма «ибне»дәге «әлиф» хәрефе астына куелган, «и» сузыгын белдерә торган «кәсрә» хәрәкәсе «әлиф»кә тоташмаган, ә бу хәрәкә өстендәге ике нокта – «Ябынчы» исеменең соңгы хәрефе «йа» астына куелган нокталар. Һарун Йосыпов исә, Гали Рәхимнең ялгыш укылышына нигезләнеп, шушы «табын» сүзен башкортларның ыру-кабилә атамасы дип карый һәм татар халкының этник тарихына үзенчә берникадәр ачыклык кертергә омтыла[9]. Югыйсә, Г.Рәхим әлеге сүзне кеше исеменең бер өлеше буларак кына китергән, кабилә-ыруларга бәйле бернинди гөман-фаразлар әйтмәгән. Шуңа карамастан, Марсель Әхмәтҗанов бер

[9] Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.–Л.: изд-во АН СССР, 1960. – С.156-157.

Безнең мирас №9 сентябрь 2017

5 рәс. **Иске Өҗем авылы зиратының XVI-XVII гасыр ташлары сакланган өлеше**

хезмәтендә, «табын» кабиләсе турында Һ.Йосыпов фикерләрен телгә алмыйча, Г.Рәхим мәкаләсенә генә сылтама ясап: «...Кече Әтнә авылы янындагы XVI гасырдан калган кабер ташында күренекле язучы һәм галим Ак Табын кабиләсе этнонимын саклаган эпитафик язма таба», – дип белдерде[10]. Ул үзе дә, Яшел Үзән районының Олы Җәке авылындагы борынгы кабер ташын ялгыш укып, «Ике Дабын» терминын «эзләп тапты», бу очракта, имеш, ике саны «Ак Табын» һәм «Кара Табын» этнонимнарын берләштерә икән[11]. М.Әхмәтҗановның «...тарих тукуз йөз иллик тукызда һиҗри Ики Дабын Йәкимезди Суфый углы Харакай...» дип укыган тексты безнең укылышта (2013 елда Олы Җәке зиратында булып, ташъязманы җентекләп өйрәндек) бүтәнчә: «...тарих тукуз йөз иллик түртдә мөхәррәм аенда ирдекем Суфый угылы Хамбар...». 954 елның мөхәррәм ае 1547 елның мартына туры килә. Күренгәнчә, текстта «дабын» дип укырлык сүз вариантлары бөтенләй юк. Өстәвенә, М.Әхмәтҗанов тарафыннан таштагы дата да дөрес укылмаган. Аның укылышындагы 959 ел 1552 елга туры килә, ләкин татар тарихының иң фаҗигале ул елында (һәм аннан соңгы елларда да) бу төбәктә мөселман кабер ташлары ясап куя мөмкин булмаган. Ташъязмадагы «мөхәррәм» сүзен М.Әхмәтҗановның «һиҗри» дип укуы да дөрес түгел, чөнки ул чорда кабер ташларында мөселманча дата гына күрсәтелгән, шунлыктан, «һиҗри» дигән сүзне ую ихтыяҗы булмаган һәм, табигый, бу сүз таш текстларында юк та.

Иске Өҗем авылы зиратындагы борынгы җиде ташның бишесе XVI гасырныкы, аларның өчесе 1508 (яки 1513), 1528 һәм 1548 елларга караганлыгы ачыкланды, икесенең язулары бик аз сакланган. *(5 нче рәсем.)* Бу зираттан көнбатышка таба чакрым ярым ераклыктагы аерым каберлектә 1540 елда шәһит булган һәм 1542 елда дөнья куйган ике кешегә затлы-нәфис ташбилгеләр куелган. «Шәһитләр

[10] Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – Б.160-161.

[11] Әхмәтҗанов М. Олы Җәке ташъязмасы тарих сөйли // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 1998. – №3/4. – 4 т.б.; Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – Б.105, 161.

(Әүлия) кабере» дип йөртелгән бу урын һәм андагы кабер ташлары турында Ш.Мәрҗани һәм С.М.Шпилевский кыскача язып калдырганнар. Г.Рәхим исә аларны тулырак тасвирлаган. Ике ташның да текстларына карата ул шактый әтрафлы аңлатмалар биргән.

Олы Бәрәзә авылы зиратындагы өч борынгы ташъязма турында моңарчы фәнни хезмәтләрдә мәгълүмат бар иде. Без шул ташларның икесен күреп укыдык. Берсен 1520 елда вафат булган кешегә улы Төнләче ясатып куйган. Икенчесенең дә куйдырган кешесе – хаҗи Рамазан – исеме язылган юллары укыла, елы һәм мәрхүмнең исеме уелган өлеше юкка чыккан.

Казан арты төбәгенең танылган мәгърифәт үзәкләреннән берсе Бәрәскә авылында өч зират бар. Шуларның «Каенлык зираты» дип аталганында Казан ханлыгы чорына караган дүрт кабер ташы сакланган. Өчесендә күрсәтелгән һиҗри даталар милади белән 1537, 1539, 1543 елларга туры килә. Эпиграфист галим Һарун Йосыпов бу зиратта XVI гасырга караган 5-6 (башка бер чыганак буенча – 7) истәлек табуын язган. Ул 1956-1959 елларда икенче һәм өченче тапкыр килүендә 3 кенә таш калганын белдергән. Югарыда әйтелгәнчә, безнең тарафтан әлеге зиратта Казан ханлыгы чорына караган дүрт ядкәр табылды һәм өйрәнелде. Һарун Йосыпов мәгълүматларына өстәмә рәвештә кабер ташларының ян-якларындагы язулар, бер таштагы кеше исеме, укылып бетмәгән сүзләр һәм аерым юллар, дүртенче ташның сакланган кадәр тексты укылды.

Казан ханлыгы чоры кабер ташларын Комыргуҗа авылы зиратында да укып өйрәндек. Алар дүртәү, икесе 1541 һәм 1545 елларга нисбәтле, тагын икесендә даталар язылган урыннары ватылган, әмма XVI гасырга караганлыклары шиксез. Әлеге ташъязмаларның моңарчы текстлары һәм фотолары басылганы булмады. Без укып ачыклаганча, аларның берсе 1541 елда вафат булган Җияш улы Иләман исемле кешегә, икенчесе 1545 елда Харамыш улына (исеме язылган өлеше уалган) куелган. Ә бер кисәге генә сакланган ядкәрдә фәкать датасы өлешчә таныла – ул 1515-1523 еллар аралыгына туры килә. Дүртенче ташның да текстын тулаем уку мөмкин түгел, бары тик XVI гасырның беренче яртысына караганлыгын язу стиленә, бизәк элементларына һәм «тарих тукуз йөз...» сүзләренә нигезләнеп билгеләдек. Болар арасыннан 1515-1523 елларга караганы – нәкъ менә моңарчы телгә алынмаганы инде. Ул без күргән вакытта да җиргә авып, яртылаш күмелгән ватык бер кисәк хәлендә иде.

Исәнбахты улы Тәнибәк исемле кешегә 1544 елда Төрекләр авылы зиратында куелган кабер ташының тексты да моңарчы басылмаган. Ташның арткы ягында аны Коңырҗа (Куңырча) исемле кеше ясатканлыгы күрсәтелгән, бу исем күрше Комыргуҗа авылының халык телендәге Комыгырҗа аталышына авазадш булуы белән кызыклы.

Кабакса дигән авыл хәзерге вакытта юк инде, аның зираты гына калган. Андагы ташъязмалар арасында иң борынгысы шулай ук XVI гасырның беренче яртысына карый. Кызганыч ки, ул ватылган һәм кыйшаеп җиргә баткан. Алгы һәм уң ягындагы берәр сүздән башка мәгълүматын уку мөмкин түгел.

Югарыда язып үтелгән, XV һәм XVI гасырларга нисбәтле 61 эпиграфик истәлекнең 51 данәсе турында фәндә төрле дәрәҗәдәге мәгълүмат һәм кыскача хәбәрләр очрый. Ләкин унысы турында мәгълүмат бөтенләй юк иде. Шушы 61 ташның 38е – Казан ханлыгы чорында куелганлыгы төгәл билгеле истәлекләр.

Әтнә төбәгендәге зират-каберлекләрдә XVII гасырга караган 4 данә ташъязма истәлек табылды. Болар – Иске Өҗем авылы зиратында 1610 һәм 1611 елларда, Олы Мәңгәр зиратында 1689 елда, Күшәр зиратында 1693 елда куелган кабер ташлары. Иске Өҗемдәге 1610 елгы кабер ташы текстының хәзерге вакытта өстәге дүрт юлы гына укыла, калган өлеше җиргә баткан. 1611 елгы истәлектә язылган кеше исемен без, Г.Рәхимнең һәм Һ.Йосыповның «Мөэминхуҗа» дигән якынча укылышыннан аермалы буларак, «Мәрдехуҗа» дип тәгаенләдек.

6 рәс. Түбән Бәрәскә авылының «Югары авыл зираты»нда Ибраһим бине Йосыф Бәрәскәигә куелган кабер ташы. 1784 ел

XVI һәм XVII гасыр ташларына уелган кеше исемнәре арасында төрки-татар исемнәрен дә (Айбикәч, Бознак, Татлыби, Төнләче, Үлмәс, Чапкын, Чирүче, Чынбулат, Ябынчы, Баубик һ.б.), гарәп-фарсы (Габдулла, Гөлбәһар, Мәрдехуҗа, Муса, Рамазан, Сәедгали, Шәехдәрвиш һ.б.) һәм катнаш кушма исемнәрне дә (Акбулад, Җәнәйсолтан, Иләман, Уразддәүләт һ.б.) күрәбез.

Әтнә районында XVIII гасырдан калган бары тик бер генә кабер ташы саклланган, ул Бәрәскә авылының «Югары авыл зираты»нда. Истәлек мәшһүр сәүдәгәр, мәчетләр, шул исәптән Түбән Бәрәскә авылындагы тарихи мәчетне дә төзеткән, 1784 елда вафат булган Ибраһим бине Йосыф Бәрәскәигә куелган. *(6 нчы рәсем)*. Әлеге эпиграфик истәлек 2 метр биеклектәге, 70 см калынлыгындагы диварлары кызыл кирпечтән корылган, буе 16 метр 80 см, иңе 12 метр 25 см үлчәмнәрендәге зур төрбә эчендә урнашкан. Монысының көньяк тарафында шундый ук тагын бер зур (буе – 15 метр 70 см, иңе – 12 метр 25 см, диварының биеклеге – 2 метр, калынлыгы – 75 см) төрбә бар, тик анысында кабер ташлары юк. Гомумән, мондый зур төрбәләр татар зират-каберлекләрендә сирәк очрый.

* * *

Әтнә төбәгендәге иске эпиграфик истәлекләрнең зур күпчелеге – XIX гасырның һәм XX гасыр башының төрле еллары белән даталанган ядкәрләр. Алар арасында төбәкнең зыялы һәм мәшһүр шәхесләренә, укымышлы затларына куелганнары шактый.

Дәвамы бар ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2017

«Әй, кырылды адәмнәр...»

(Спас районының Көек авылында 1921 елгы ачлык вакыйгалары[1])

Айдар Казаков[2]

1918-1920 еллардагы Гражданнар сугышы вакытында, авыл агаен икмәксез калдырган продразверстка сәясәте Спасс районының Көек авылына да кагыла. Продотряд җитәкчесенең кем булуын, кадерле укучым, ТР Милли архивыннан алынган шушы таныкнамәдән белерсең: ***«Предьявителю сего, члена Спасского Уездного Исполкома товарищ Хуснатдинов делегируется во Временную комиссию по реквизиции имущества найденного в деревне Каюки. Все учреждения и организации должны оказать тов. Хуснатдинову законное содействие для скорейшего выполнения поручения»****. Әлеге отрядның киң вәкаләтләргә ия булганлыгы хакында онытырга ярамый. Кулак буларак сөрелгән кешеләрнең эшләре белән танышканда, җирле түрәләр продразверстка түләүдән баш тарткан авыл агайларын һич кенә дә кызганып тормаган. Әйтик, Борһан Хәйбулла улы Шәһиев, 1918 елда продразверстка түләүдән баш тартуы сәбәпле, алты айга мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән.*

[1] Мәкалә **Шәмсетдинова Рәхимә Мөхәммәтвәли кызы**, **Сибгатуллина Миңҗамал Лотфулла кызы** һәм башка кешеләрдән (күбесе инде бакый дөньяда) язып алынган истәлекләр, авылдашыбыз Абдулла Алиш мәкаләләре, ТР Милли архивында сакланган документлар нигезендә язылды.

[2] Айдар Казаков – Спас районы Көек авылы мәктәбенең тарих укытучысы.

Икмәкне тартып алу нәтиҗәсендә килеп чыккан ачлык фаҗигасе авылдашыбыз Абдулла Алишның иң беренче язмаларында да чагылыш тапкан. Аның «Ачлык елы» дигән мәкаләсеннән бер өзек китерик: *«1921 елда яңгыр булмау сәбәпле, иген уңмады. Ачлык булды. Иген бик кыйбатланды. Кешеләр кайсы игеннәрне җыеп алды, кайберләре читкә китте, кайсылары авылда калдылар. Иген булмагач, алабута бик уңды, хәтта ишекгалларында да урып алырлык булды. Кешеләр алабутаны азапланып җыйдылар. Ялкаулар: «Аңа кушарга он юк, коры алабутаны ашап булмый, оны булса, алабутасы табылыр әле», – диделәр. Иген үзе булмаса да, эше күп булды. Игенне күтәреп кенә йолкыдылар. Урак алып уракка йөреп азапланасы булмады. Үзләренең куллары урак булды. Игенне йолкып, көндәгесен көн дә алып кайта бардылар, чөнки кырда калган көлтәләр «аякланалар» иде. Атлы кешеләр ат белән, атсызлар башларына күтәреп яисә кечкенә арба белән көлтәләрне алып кайта иде. Алып кайткач, ул көлтәләрне мич башына куеп киптереп, тукмаклап, җил булса, җил тегерменәнә, җил булмаса, ат тегерменәнә алып барып тарттыралар иде. Көннәр үтә-үтә кыш килде. Ашарга бернәрсә юк. Халык тәмам аптырады. Без 60 потлап алабута әзерләдек. Бөтен келәт буралары тулды. Бик чиста иде. Әти, Мансыр дигән авылдан, яхшы киемнәргә алмаштырып, 3-4 пот он алып кайтты».*

Ә хәзер бер истәлек белән танышыйк: *«Эшти Хәятләренең өстенә кемнәрдер яла яга. «Карак» дип.... Халык, аны-моны уйлап тормый, ни бар шуның белән коралланып, йортына бәреп керәләр, тентү уздыралар. Совет кешеләре бу хакта белми дә кала. Кемдер үзенең май чүлмәген таный, кемдер тагын нииндидер искесен чыгарылган мал-мөлкәт арасында күрә. Шуннан соң китә дә инде... Башта өйләрендә кыйнадылар, ә аннары, ат арбасына гаиләләрен җигеп, мәчет каршысына китерделәр, кыйный-кыйный урам буенча табалар кагып йөрттеләр... Әткәй чыгып якламакчы иде, әнкәй аның аяк астына егылды: «Балаларыбыз хакына, зинһар, чыкма!». Урамнан узганда: «Хәмәтвәли! Коткар безне!» – дип җан авазы белән кычкырганнарын әле дә хәтерлим. Аннан соң ачлыктан акылдан язган халык төркеме аларны гаиләләре белән җәзалап үтерде. Бер Салман кешесе әлеге төркемнең корбаны булган, дигәннәрен әз генә ишетеп беләм... Сәүдә эше белән килгән туганнары булган, дип тә әйттеләр. Халык йортны камап алгач, ян тәрәзәдән оекчан чыгып качкан. Әмма, Сабанча урманына җитәрәк, тотып алганнар һәм авылга алып кайтып, Хәятләрнең язмышына дучар иткәннәр.*

Әткәй әлеге хәлдән соң озак яши алмады, үлде. Үги әниебез апам Әкрәмәнисәне, абыем Йосыфны приютка тапшырды. Бер приют Ямбактыда иде. Мине дә алып китмәкчеләр иде, әмма мин читәнгә җан ачысы белән чытырдап ябыштым да озак кына, «китмим», дип еладым... Шулай итеп авылда калдым. Абыем шул кышны приютта үлде... Әни, никадәр авыр булса да, сыерны бетермәде. Ул мескен ничек безне туендырырлык сөт биргәндер, белмим. Әнкәй, сыерны савып кергәч, сай гына итеп агач табакка сөт сала да өстәл уртасына куя. Без 7 бала кашыкның төбен сөткә тидерәбез дә ялап алабыз. Имеш, сөткә экономия. Әкрәмәнисә апамны исә Ленинградка алып китәләр. Детдомга урнаштыргач, аңа дуңгыз итеннән пешерелгән ашны ашата алмыйча аптырыйлар. Мөгаен, бу кызык риваять кендер. Әмма балалар янына беркөнне Ленин килә. Тәрбиячеләр: «Вот эту татарочку очень жалко, ничегошеньки не ест...» – дип әйткәч, Ленин боерыгы буенча, аңа нииндидер кош ите бирә башлыйлар».

Ачлык авыл халкының фикерләвен һәм психикасын тамырдан үзгәртә. Мөгаен, ачлык кешеләрдәге туганлык хисен дә үтергәндер. Моңа бер мисал итеп шушы

истәлекне китерәсем килә: *«Әткәйнең туганнары бик бай тормышта яшәгән. Күрше урамда торучы ерак кардәшләре үлә. Биш бала тома ятим кала. Кече сеңелләре, ачыгудан тыш, кызамык белән чирләп китә һәм апаларына тары боткасы алып кайтуны сорый. Болар үзләренең бабаларына баргач, бабалары өстендә бер-ике бөртек тары ярмасы йөзеп йөргән бер җамаяк өйрә биреп җибәрә. Теге бала: «Мин бит бер генә кашык тары боткасы сораган идем», – дип әйтә дә апаларының кулында җан бирә».*

Бу фаҗига моның белән генә тәмамланганмы соң? Әлеге сорауга төгәл җавапны тагын бер истәлектән табарга мөмкин: *«Авылдагы тегермәнче йортыннан күрше кызы бер кисәк икмәк урлап чыга. Әлеге кисәк икмәк өчен тегермәнче хатыны әлеге баланы тимер тырма белән кыйнап имгәтеп бетерә. Өйдә исә әнисе, үзләренең йорт капкасының баганасына, газапланмасын, тизрәк үлсен, дип асып куя...»*

Әлеге фаҗигаләр хакындагы истәлекләрне тетрәнмичә укырга мөмкин түгел. Ачлыктан интегүче балаларны тукландыру, өлкән яшьтәге ачларга ярдәм итү өчен, АРА һәм Помгол оешмалары тарафыннан ашханәләр ачыла, анда йөри алмаучыларга паёклар өләшенә. Бу турыда бер документ: *«1921 елның 7 октябреннән протокол. Рәис: Ананьев. Әгъзалар: Чугунова, Москвичев. 350 паёкны волостьнең ашханәләре буйлап пропорциональ рәвештә бүләргә. Паёклар бүленелде: Пичкасска – 109, Бураковога – 53, Көеккә – 86, Базяковога – 60, Долгоруковога – 35 паек. Помголның өстәмә 18 паёгын Көек белән Базяковога бирергә карар кылынылды, чөнки бу авыллар халкы ачлыктан аеруча зур зыян күргән. 1921 елның октябренә ачтан үлүчеләр саны: Көектә – 90 кеше, Базяковода – 72».*

Документлар картинаны тагын да ачыграк күз алдына китерергә ярдәм итәләр, дип уйларга нигез бар. Алар ачыгучылар өчен ачылган ашханәләрдә кемнәрнең мөдир булуы турында сөйли: *«Спас кантон комитеты тарафыннан ачылган ашханәләрне әлеге елның 14 ноябреннән эшли башлады, дип санарга. Мөмкинлек булганда әлеге ашханәләрне авыл уртасында яисә мәктәп бинасында ачарга кирәк. Персонал җыю эшен мөдирләргә йөкләргә. Яңа ачылган ашханәләргә мөдирләр итеп түбәндәге кешеләрне билгеләргә: Кожаевкадагы ашханәгә – И.К.Копайчев, Бураководагы ашханәгә – Г.Н.Ермошин, Пановкадагы ашханәгә – А.С.Дементьева, Буиновкадагы ашханәгә – А.Ф.Лисичкина, Екатериновкадагы ашханәгә – Пичкас волисполкомының элеккеге переписчицасы З.И.Леонованы, Әҗмәрдәге ашханәгә мөдир итеп Таһировны билгеләргә. Элегрәк ачылганнарында баштарак билгеләнгән мөдирләрне калдырырга. Волисполком әгъзалары Чугунова – хуҗалык эшләре өчен, Ананьев – финанс эшләре өчен, Москвичев азык-төлекне алып кайту, үлчәү, саклау һәм өләшү эшләре өчен җаваплы».*

Туган авылыбыз Көектә әлеге ахшанә кайда урнашкан була соң? Бу сорауга шушы истәлек җавап бирә: *«Хәзерге клуб янәшәсендәге мазанкада аш пешерәләр. Миңнегайшә әби Яхинаның әнисе аш пешерүче булып эшли. Казаннарны кырып югач та, олылар, әлеге казаннар кырыенаябышып калган ризык калдыкларын да чыгарып түкмәвен сорыйлар: «Таһирә апа, шул казаннарыңны юган суны булса да түкмә инде, зинһар», – дип ялваралар».*

Көектәге ашханә мөдирләренең кемнәр булганлыгы да билгеле. 1921 елның 18 декабрендә имзаланган беркетмә бу сорауга да җавап табарга ярдәм итте: *«Көек авылы балаларының күпчелегенең өс киемнәре булмау сәбәпле, ашханә мөдире итеп Акашев Ибнине билгеләргә. Көектәге ашханәләрнең эшчеләре һәм мөдирләре: Сәлимов Вафа – мөдир, Акашев Ибни – мөдир, Камалов Хәбибрахман – аш пешерүче».*

АРА күрсәткән ярдәм дә аз булгандыр, дип уйларга нигез туа. «1922 елның 26 гыйнварыннан» дип аталган бер беркетмәдән өземтә фикеребезнең дөреслеген

дәлилли: *«Әлеге документны күрсәтүче Көек авылы гражданины Латыйпов Якубка ачыгучыларга өләшер өчен түбәндә күрсәтелгән күләмдәге азык-төлек биреп җибәрергә: 4 (дүрт) пот кукуруз оны, 1 (бер) пот азык суррогатлары, 3 (өч) пот бәрәңге, 2 (ике) пот ит».*

Тагын бер ишле гаиләнең фаҗигасе белән таныштырасым килә: *«Әтиләре үлгәч, әниләре башка кешегә чыгарга уйлый. Мичкә каты гына итеп яккач: «Болай ачтан кырылганчы, бу биш бала ис тиеп үлсә яхшырак, дип, мичне кисәү башлары белән томалап куя. Әмма, бәхеткә каршы, эткәй карындык тәрәзәне ертып чыга да күршеләргә кереп егыла. Халыкта мәрхәмәтлелек хисе бетмәгән була, балаларны коткаралар. Әниләре исә, исән калулары хакында ишеткәч, соңгы кәҗәне суйдыра да, биш баланы асрамага бирә. Авылда ачылган АРА ашханәсендә туклану мулрак булган. Әмма эткәйне аңа кертмәгәннәр, ә бәлки Помгол ашханәсенә билгеләгәннәр. Әбкәй бик отчаянный кеше булган: «Бу бит ятим бала, ник аны кире кагасыз?» – дип әйткәч кенә АРА ашханәсенә билгелиләр. Әбкәй һәм бабакайда тәрбияләнгән вакытта боларның сарыклары була. Чырагачка төне буенча утырганда, чиратлашып, янып беткәне урынына яңа чыра куялар. Бабакай эткәйне бик каты кызгана һәм иртәрәк йокларга яткыза. Бабакай тире эшкәртә һәм иярләр, камытлар ясый. Хәерчегә җил каршы, дигән әйтем гел туры килә. Бер төнне әче салкында сарыкларны бүре баса. Бабакай, тимер сәнәк күтәреп, эчке кием белән генә курага йөгереп чыга һәм каты салкын тидерә. Бүре тешләгән бер сарыкны гына суеп калалар. «Тиреләрен тунагач, эч маен эретеп керосин урынына кулланырга мөмкинме, хәрәм түгелме?» – дип, мулладан дәресләр алучы балага сорарга куша. Малай баргач, иптәшләре белән шаярышып, сорарга оныта һәм кайткач: «Хәзрәттән сорадым, ярый, хәләл», – дип әйтә. Яз көнне инде каты авыру бабакай урамга чыккач, хәзрәтне күрә дә: «Хәзрәт, минем бүре ботарлаган сарык маен куллану турындагы соравыма Сез уңай җавап биргәнсез икән, иншаллаһ, инде кышны шул майны яндырып чыктык», – ди. Хәзрәт исә: «Малаең миңа андый сорауны биргәне юк!» – дип җавап бирә. Ялган сөйләгәне өчен, икенче көнне остабикә эткәйне уклау белән кыйнап җибәрә. Шул көннән башлап, эткәй мәдрәсәгә бүтән бармый».*

Безнең мирас №9 сентябрь 2017

Торак пунктының исеме	Йортлар саны	Ничәсендә кеше яши	Ничәсе буш	Ир-ат	Хатын-кыз	Балалар (16 яшькә кадәрге)
1нче Пичкас	501	477	24	626	891	929
2 нче Пичкас	24	22	2	46	57	46
Долгоруково	114	107	7	99	127	273
Вожи	230	183	47	309	371	570
Буиновка	35	33	2	260	61	120
Екатериновка	71	61	10	120	141	192
Ямбакты	522	237	285	334	481	621
Танино	74	42	32	43	74	116
1нче Кожаевка	163	149	14	277	244	292
2 нче Кожаевка	12	11	1	20	16	23
Бураково	246	230	16	216	329	670
Каюки	425	383	42	700	619	781
Базяково	160	114	41	272	342	566
Пановка	65	59	6	103	141	149
Бер.Грива	276	267	9	450	510	857
Старообр.хутор	4	4	–	45	43	47
Измери	167	151	16	176	200	609
Малиновка	54	54	–	71	81	152
Христофоровка	96	92	4	144	135	242

Бу елда авылларның бушап калу тәртибен саннарда күрсәтсәк, беренче урында, мөгаен, Николо-Пичкас волостендагы иң зур татар авылы булган Ямбакты торыр иде. Ачлык тудырган фаҗигаләр әле моның белән генә бетми. Һарун Казаковның сөйләве буенча, Баҗакта (Базяково) яшәгән Шуран исемле кешенең гаиләсен ачлык вакытында этиләре Хәбибулла коткарган. «*Ризык эзләп чыккач, кыш көнне буранда болар адашалар. Очраклы рәвештәме, могҗиза беләнме, болар Кыркапка рәтендә яшәүче этиләрнең капкаларын кагалар. Эти икенче көнне аларга ипи, бәрәңге биреп җибәрә. Шуранның, үлгәнче: «Отец Ваш нас от голодной смерти спас», – дип сөйләвен хәтерлим*». Абдулла Алишның «Якты күл буе» дип аталган повестенда да туган авылыбыз Көектән алынган образлар булгандыр, дип уйларга ныклы нигез бар. Әлеге фикернең дөреслеген дәлилләүче өзекне дә китерәсем килә: «*Көтүче карт авылдан беренче булып ачыга башлый. Аның ике баласы мич башында, иске чүпрәкләргә төренгән килеш, җылылык эзли, ә җылы юк. Ул ачлыкка бирешә башлый. Чыдый алмыйча, азак чиккә җитә. Күршеләр Чыгыш тавыннан майлы кара балчык алып кайталар. Үзалдына майланып торган үзле әлеге кара балчык эти кешенең соңгы азыгы була. Иртәгесен балалар, мич башыннан гына, юкә чыптага төрелгән мәетне кемнәрнеңдер алып чыгуларын күреп калалар. Күп тә узмый, ана да ахыргы чиккә җитә*».

Авыл зиратында ачлык корбаннары җирләнгән, убылган зур баз кебек кабер эзләре бар. Әби-бабайлар Коръән багышлаганда еш кына Аллаһ Тәгаләдән гөнаһларыбызны ярлыкауны гына түгел, ә ачлык афәтен беркемгә дә күрсәтмәвен сорыйлар. Мин дә бу мәкаләне, аларның әлеге изге теләкләре кабул булсын иде, дигән юллар белән тәмамлыйм. ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2017

ЭДУАРД ГАНИЕВ: «ҮРНӘК КҮРСӘТҮ – БЕЗНЕҢ БУРЫЧ»

*Бөтендөнья татар конгрессының VI корылтае алдыннан, баш мөхәррир **Ләбиб Лерон** һәм бүлек мөхәррире **Ленар Гобәйдуллин**, «ГЭКСАР» электротехника заводы генераль директоры, Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районы башлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы Бюросы әгъзасы, академик **Эдуард Әнвәр улы Ганиев**, районның мөхтәрәм шәхесләре **Рамазан хәзрәт Юмангулов**, **Рәшит Аввясов**, **Кадыйр Әхмәров**, **Рушан Ягудин** катнашында җылы сөйләшү булды. Район җитәкчесе Э.Ә.Ганиевның кайбер фикерләрне сезнең игътибарга да тәкъдим итәбез.*

СУФИЧЫЛЫК – ТАТАРНЫҢ КАНЫНДА

Соңгы елларда җәмгыятебездәге рухи тормышның җанлануы сәбәпле, заманында халык мәгарифенә зур өлеш кертеп, хаксызга онытттырылган шәхесләребезнең исемнәрен кире кайтару, аларның кылган изге гамәлләрен халыкка пропагандалау күренеше бара. Без дә Кулаткы төбәгендә тирән ихтирамга лаек шундый шәхесләребезне барлап, аларның каберләрен төзекләндерәбез, ташларын яңартабыз, истәлек билгеләрен куябыз.

Хәбибулла ишан Хансөяров – шундый бөекләребезнең берсе. Аның кабере янына барып дога укысам, җаныма тынычлык табам, рухи чистарынып калам. Ул – XIX гасырның иң белемле, затлы, зыялы шәхесләреннән берсе. Туган авылы Яңа Зимничәдәге Салих муллада, аннары Муса авылындагы Габбас хәзрәт Рәфиковта белем ала. Соңрак укуын суфичылыкның үзәге булган Чистайда, дамелла Габделгафур мәдрәсәсендә дәвам итә. Билгеле ки, Чистай – Әмирханнарның бабасы Нәҗип бабай да яшәгән, мөгаллимлек иткән шәһәр.

Хәбибулла ишан 80 ел дәвамында Яңа Зимничәдә яшәп, Самара, Саратов, Сем-

бер губерналарына йөзләгән имам-ишан әзерләгән. Алар арасында күренекле язучылар, җәмәгать эшлеклеләре Вафа Бәхтияров, Кәшшаф Патии, Хөсәен Әбүзәров кебекләр дә бар. Аның улы Габделвахид бине Хәбибулла атаклы мулла Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗанидә гыйлем эсти, соңрак, атасына ярдәмче имам булып, милләткә хезмәт итә, шәкертләр укыта. Хансөярләр суфи булып, Коръән, намаз гына укып утырмаган, бер үк вакытта иген дә иккән, мал-туар да асраган, умарта да тоткан. Ишанның җир биләмәләре Зимничәдән Терешка, Кулаткыга кадәр җәелгән. Остаз булачак муллаларны берничә һөнәргә өйрәткән, укып бетергәч тә, имам гына булып эшләмәсеннәр, тормышны алып барырга башка мөмкинлекләре дә булсын, дигән.

2005 елда Яңа Зимничә авылында Хәбибулла Хансөяровның 200 еллыгын зурлап билгелеп үттек. Ә аның исемендәге укуларны оештырып җибәрүнең авырлыгын үзем генә беләм. Бу вакытта террор, экстремизмнан да куркучылар, мине суфичылыкны пропагандалауда гаепләүчеләр дә булды. Шөкер, үземне аңлый торган кешеләрне таптым. Суфичылык – ул татарның канында, безнең тамырларда, туган туфракта...

Кулаткы районы заманында суфичылыкның үзәге булган. Татар халкы бүген дә суфичылыкны саклый. Мисал өчен, безнең Иске Кулаткы районындагы бер авылда кеше вафат булгач, аның бурычларын кемдер үз өстенә ала. Хәзерге атаклы муллаларыбызның да кылган гамәлләре, сөйләгән сүзләре һәм вәгазьләрендә элеккеге суфичылыкның чагылышы бар. Ш.Мәрҗани әйткәнчә, милләт ул – тел, гореф-гадәт һәм киемнәр. Әмма безнең Хансөяр укулары аша суфизмны күтәрү нияте юк иде... Дөрес, укуларда без Хәбибулла ишанны суфи буларак танытсак та, мәдрәсәсе, мөридләре турында халыкка җиткерсәк тә, суфичылык яки исламның башка агымнары хакында сөйләүне анда максат итеп куймадык.

Соңрак Кулаткы укуларын оештыра башладык. Ни өчен, дигәндә, районыбызда башка атаклы ишаннар да яшәгән. Муса авылында – Габбас хәзрәт, Атлашта – Камил Ягъфәров. Урта Терешка, Керюшки, Иске Зеленай, Вязовый Гай – барысы да ишан авыллары. Алар да тарихта тирән эз калдырган шәхесләр. Районыбызда җиде ишанның кабере билгеле. Болар барысы да суфи булган, мәдрәсә тотып, шәкерт-мөридләр тәрбияләгән. Шуның өстенә, Гражданнар сугышы чорында канкойгыч вакыйга була – Атлаш янында унике имамны атып үтерәләр. Аларның берсе – Явлейка имамы, яраланып, икенче көнне Урта Азиягә качып котыла. Миңа аның оныгы белән аралышрга туры килде.

Хәбибулла ишан кабере янына мосафирлар төрле тарафлардан килә. Сәфәр чыгучылар арасында үлеп калучыларның каберләре дә билгеле. Без аларны әүлиялар, дибез, догадан калдырмыйбыз. Муса белән Явлейка авыллары арасында бер кыз бала вафат булган. Мин ул җирләнгән урынга чардуган куйдырттым. Техникум каршында да шундый бер юлчының кабере бар.

Нәзер әйтү – бик борынгы гадәт. Теге яки бу теләгем кабул булса, хафалар бетсә, ишан каберенә барып садака бирер, Коръән-хәтем чыгар идем, дип нәзер әйткән мосафирлар, әүлиялар каберләренә, Хәбибулла ишан җирләнгән зиратка ерак җирләрдән җәяү килүне саваплы гамәлдән саный, андыйлар Әстерхан тарафыннан аеруча күп. Совет чорында да бирегә нәзерле юлчылар гел килеп торды.

Хәбибулла ишан Хансөяров турында татар һәм рус телләрендә китап басылып чыкты. Аның авторы – якташыбыз, Самара имамы, галим Иршад Сафин. Хәзер «Иске Кулаткы ишаннары» дигән китап басмага әзерләнә. Алла насыйп итсә, районның мәчет һәм мәдрәсәләре, алардагы атаклы мулла-мөдәррисләр турында да китаплар махсус серия булып чыгар, дип уйлыйм.

Лябиб Лерон

Рушан Яһудин

ӘМИРХАННАР – БОРЫНГЫ ИШАН НӘСЕЛЕ

Әтием Әнвәр – математика укытучысы. Атаклы педагог Госман Әмирханов белән безнең йортлар янәшә булды. Алар ун бала үстерде. Хатыны, мәрхүмә, Атлашныкы иде. Икесенең дә урыны җәннәттә булсын. Госман абый гаять тыныч холыклы укытучы, белемле, затлы, зыялы шәхес иде.

Өйдә тәрбия бик көчле булды. Үзара мөнәсәбәт, күршеләр, авылдашлар белән мөгамәлә югары әхлакка корылган, гаять культуралы, тәртипле, күркәм гаилә иде. Безне әти-әниләр ничек тә дөрес юлга бастырырга тырышты, әмма аларда тәрбия бөтенләй башкача иде. Гаилә эчендә Госман абый моны ничек башкарды? Белмим.

Мин бу гаиләнең балалары белән уйнап үстем. Уйнаган вакытта да алар үзләрен башкача тотты. Бу, һичшиксез, Госман абыйның йогынтысы иде. Госман абый туган телгә, кием-салымга гаять игътибарлы булды. Аның мулла улы икәнен без бик яхшы белдек, атаклы совет укытучысы булса да, ул безгә – балаларга дин, Коръән, хәдис, намаз һәм тәһарәт турында сөйли иде. Намаз вакыты җитү белән, аның өенә кеше керми, чөнки бар да белә – Госман абый намазда... Дөрес, динилеге өчен аның шактый кыйналганлыгы мәгълүм булды. Ни дисәң дә совет укытучысы, совет пропагандасы, атеизм дигән нәрсә бар бит. Без – балалар моны аңлап бетермәгәнбез.

Ул вакытта Атлашта динне тыю булмады. Авылыбыз, мәчетләр булмаса да, шартлы рәвештә биш мәхәлләгә бүленде. Аларда Шакир, Зариф, Ахун һәм тагын атаклы ике мулла имамлык иттте. Гаетләрне кышын зиратта салам җәеп укыдылар. Әтием, мәктәп директоры булса да, балаларны гаеткә барудан тыймады. Мәктәптә рамазан ае вакытында, башка авыллардагы кебек, син уразада түгелме икән, дип балаларга су эчертү кебек начар гадәтләр булмады. Чөнки Атлаш мәктәбенә килгән укытучыларның күбесе Чардаклы районындагы Калмаюр авылыннан, аларның исә үзләрендә дә дин электән үк көчле булган.

«БАЛАЧАК» МУЗЕЕ – КЫЗЫКЛЫ ПРОЕКТ

Һәр эшне эшләгәндә үрнәк күрсәтү – безнең бурыч. Башкалар да шундый изге гамәлләргә тартылсын иде, дибез. Районда мәчет картлары, мәктәп балалары, урта буын вәкилләре катнашында зиратларны төзекләндерү эше актив бара. 23 авылның берсендә генә дә ташландык зират юк. Халык аек. 2000 нче елларда эчеп яки үзенә кул салып вафат булган кешеләрне зират тышына күмәргә, дигән карар чыгардык.

Районыбызда 26 мәчетнең 4ендә «Җомга көн» мәктәпләренең бинасы аерым, 8ендә мәчеткә ялганып төзелгән. Бүген 26 мәчетнең һәрберсендә дә мөгаллим-мөгаллимәләр бар, мәктәпләр техник чаралар белән тәэмин ителгән. Аларда төрле буын вәкилләре бик теләп белем ала, Коръән уку конкурслары үткәрәбез. Дөньяви мәктәптә дә «Әхлак һәм дин» дәресләре укытыла, мәчетләр каршында дини лагерь-лар эшли.

Район үзәгендә – 5 мәхәллә. «Гани» мәчете борынгы бабамның исемен йөртә. «Әнвәр» мәчетен 1850 елда төзелгән мәчет урынында 70 көндә, ике гает арасында төзеттем, өстеннән китмичә, бөтен эшне үзем «бәрдем». Аны ачарга губернатор, ТР Президенты Р.Н.Миңнеханов үзе килде. «Сафия» мәчете – әниемнең исеме белән бәйле.

Әмма бер «авыру» бар: абыстайларыбыз күбәйде. Алар үзара лидерлык өчен «кыйнаша». Дөрес, конкурентлык булырга тиеш, әмма һәр мәхәллә халкы иң белем-ле абыстай, иң укымышлы мулла артына басарга тиеш.

Иске Мостякта Сүнчәләйнең йорты бар. Ул шагыйрь Сәгыйтьнеке түгел, ә бөтенләй башка, сәүдәгәр Сөләйман Абдулла улы Сүнчәләевнең йорты. Алар фамилиядәшләр генә. Бүген миңа шул «таш ызба»да Сәгыйть Сүнчәләй музееен ясыйк, диләр. Миңа, бер яктан, уңайсыз да: ничек инде шагыйрьнең үзенә катнашы булмаган йортта аның музеен ачасың? Ә икенче яктан, яшь буынны тәрбияләргә, балаларга шагыйрьнең, аның даирәсенең, Тукайларның иҗатын сеңдерергә менә дигән мөмкинлек. Г.Тукай да Иске Мостяк авылында булган, диләр.

Сез әйткән «Балачак музее» да кызыклы проект. *(Бу проект турында журналның баш мөхәррире Ләбиб Лерон сөйләде. –* **Ред.***)* Узган ел Иске Кулаткыда Бөтенрәсәй авыл Сабан туе кысасында беренче төбәкара балалар Сабан туе да оештырдык, хәтта аны, төп мәйданнан ихласрак, самимирәк һәм матуррак узды, диючеләр дә булды. Бәлки киләчәктә «Балачак музее» Иске Кулаткының брендына әверелер. Ул татар дөньясында беренче һәм бердәнбер булырга тиеш.

БЕЗГӘ СЕЗГӘ КАРАГАНДА АВЫРРАК

Кулаткы төбәге сезнең республикага ике зур җитәкчене биргән. Берсе – Иске Зеленай авылыннан, мулла Хөснетдиннең улы Борһан Мансуров. Ул – ТАССР ҮБК Президиумының беренче рәисе, газета-журналларда мөхәррир булып эшләгән. Икенче шәхес – Иске Кулаткы авылы егете Габделхак Әбдерәзәков. Габделхак Әсвәнович 1959-1966 елларда ТАССР Министрлар Советының рәисе булып эшли. Бүгенге Татарстан Республикасындагы күп кенә сәнагать объектларының тарихы аның исеме белән бәйле. Хакимияткә Фикърәт Табиев килгәч, ике мишәр бер казанга сыймый, Габделхак Әсвәнович Мәскәүгә китәргә мәҗбүр була. Якташыбыз анда да югалып калмый, РСФСР авыл хуҗалыгы министрының беренче урынбасары була.

Кулаткы төбәгендәге икътисади, мәдәни вазгыять Татарстан белән чагыштыр-ганда күпкә авыррак, әмма сез телне, гореф-гадәтләрне безгә караганда тизрәк югалтып барасыз. Рухи мәркәзебез Казаннан читтә булсак та, рус арасында утрау булып яшәсәк тә, Аллага шөкер, балаларыбыз татарча сөйләшә. Кызганыч, Казанда гына түгел, ә Татарстанның район үзәкләрендә дә балаларның татарча аралашканы ишетелми.

Татар Казан, Татарстан белән генә чикләнми. Россия Президенты В.В.Путин, 80 яшьлек юбилее уңаеннан, М.Шәймиевкә «Тартарика» картасын бүләк итте. Анда, Аляскадан алып, хәзерге Мәскәү, Рязань җирләренә кадәрге зур мәйдан татарны-

Рәшит Аввясов һәм Кадыйр Әхмәров

кы, дип күрсәтелгән. Кайчандыр дөнья татар кулында булган. Финнарның да моңы татарныкына охшаш, чукот, ямалларныкы да безнеке кебек. Милли моң – гасырлар буе сакланып килгән нәрсә.

Бүгенге хәлләр – патша хакимиятеннән килгән руслаштыру сәясәтенең дәвамы. Дөрес, без инде руслар белән «тел,ләгать вә гадәт алмашып» яшәргә күнеккән, әмма бүген бөтенләй башка әйбердән куркырга кирәк: Россияне акрынлап кытайлар басып бара. Күптән түгел илнең төрле шәһәрләрендә электромоторларны төзәтү буенча эшләүче бер хезмәттәшем Кытай чигендәге Благовещенскта булып, гарьләнеп кайтты. Анда бар хуҗалык, элек гөрләп эшләгән завод кытайлар кулында. Менә кайда ул фаҗига!

Без, татарлар – бәхетле халык. Дөнья буйлап сибелсәк тә, бер рух, бербөтен, бер милләт булып яшибез. Милләт, рухи яшәешебез турында сөйлибез икән, халкыбызны берләштереп торучы Бөтендөнья татар конгрессын да әйтми мөмкин түгел. Милләтебезнең телен, тарихын, динен, мәгарифен, мәдәниятен саклап һәм яклап, киләчәк буыннарга тапшырырга мөмкинлек тудыручы әлеге иҗтимагый оешмага быел 25 ел тулды. Шулвакытта татарны татар итеп саклап калуны максат итеп куйган Татар конгрессы еллар дәвамында башкарган эшләре белән бурычын тагын да баетып, киләчәккә горур атлый. Безнең татарлар өчен таяныч та, булышчы да, киңәшче дә булган Бөтендөнья татар конгрессының, аның җитәкчелегенең алдагы зур эшләре дә уңышлы булачагына шигебез юк. Бу оешмада булдыклы, милләтпәрвәр егетләр һәм кызлар халыкка хезмәт итә.

«Безнең мирас» журналы татар мәдәниятен, тормышын, гореф-гадәтләрен саклауда зур көч куя. Мирасның исеме үк безгә зур бурычлар өсти. Аны ачып укысак, үзгә территорияләрдәге материаллар белән танышсак, күп әйберләргә башкача бәя бирер идек. Ходай халкыбызны сәламәтлектән һәм тәвәккәллектән генә аермасын!

Иске Кулаткы, 2017 ел, 20 июль. ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2017

ТУГАН ЯК *елъязмасы*

Мансур Хәсәнов

Татар Толлысы авылы күренеше. 1950 нче еллар

Мансур абый – күршем.

Туган нигезенә кайткан саен калын-калын дәфтәрләрен алдыма чыгарып сала ул: бусы – тормышы, бусы – чит җирләргә бәхет эзләп киткән һәм (бәхетен тапкандырмы?) шахтада басылып йә башкача бакыйлыкка кичкән авылдашлар турында, бусы – авылдашларның шәҗәрәсе, авыл тарихы...

Үз күлмәгең үзеңә якын. Билгеле, мин аларны йотлыгып укыйм: таныш һәм (ни гаҗәп!) таныш түгел исемнәр, таныш һәм (ни гаҗәп!) таныш түгел атамалар...

Татарстанның атказанган икътисадчысы Мансур абый – туган як елъязмачысы. Авыл һәм төбәк тарихын барлауда төп чыганагы – Хәтер аның...

Язмаларының бер өлешен «Безнең мирас» аша авылдашларга, якташларга һәм, гомумән, кызыксынган һәркемгә тәкъдим итәсе килә.

Рүзәл Мөхәммәтшин

РИВАЯТЬ

Татар Толлысы – Нократ елгасы буенда урнашкан татар авылы. Ул XVII гасырда барлыкка килгәнгә охшый, чөнки Явыз Иван Казанны яулаганнан соң (ягъни XVI гасырда), зур сулар тирәсендә татар авыллары калмаган. Булганнарын юк иткәннәр яки башка җиргә күчергәннәр. Безнең тирәдә елга ярына сыенган тагын бер татар саласы – Киров өлкәсенә кергән Түбән Шөн генә бар.

Шулай да, авылыбыз ничек барлыкка килгән соң? Бүген халык телендә йөргән риваятьне беренче мәртәбә Сәлах абый Фәсхетдинов авызыннан ишеттем. Ул хәтерле, фикерле кеше иде. Сүзен ачык итеп, кистереп әйтә. Бәхәсләшергә урын калдырмый.

Димәк, элек безнең тирәне урман каплаган булган. Шунда бер аланлыкка тол кеше килеп урнашкан, эш башы итеп Нократка койган инеш буенда бал корты

үрчетергә керешкән. Тора-бара тормыш итәргә пар тапкан, алар иген игә, кош-корт асрый башлаганнар. Балык тотканнар, су тегермәне корганнар. Алга таба монда байтак кына йортлар барлыкка килгән.

Бервакыт инештән йомычка агып төшүен күргән болар. Урманны ерып су агымына каршы менә торгач, инеш буенда тагын бер авылга тап булганнар. Анда яшәүчеләр урыс икән. Шулай итеп, үз авылларына Татар Толлысы, тегесенә Урыс Толлысы атамасы биргәннәр. Соңгысы, күп еллар узгач, ни рәвешледер, Чарлыга үзгәргән.

Өстәп шуны да әйтим. Безнең авылга чирмешләр нигез салган, дигән фараз да бар. Тора-бара авылда татарлар артып, ут күршеләрне Нократның аръягына куганнар, имеш. Бу риваятьтә беркадәр хаклык та бардыр. Чөнки сабый чакта Югары очлар безне – чирмешләр, урамыбызны Чирмеш очы дип йөрде. Бу милләт вәкилләре Әлмиев Нурый абыйлардан астарак (зират ягыннан өченче тыкрыкка кадәр) яшәгән, дигәнне ишетеп үстек. Безнең чорда алар юк иде инде.

Клуб мөдире (һәм язма авторы) Мансур Хәсәнов хезмәт халкы арасында агарту эше алып бара. 1960 нчы еллар

ТАБИГАТЬ

Татар Толлысы авылы, Сөрән тау башыннан караганда, зур аланда утырган кебек. Көнчыгышта Нократ елгасы ага. Аръягында – тайгага барып тоташа торган урман. Көньяк-көнбатышын да урман каплаган. Төньякта тау тезмәләре сузылган. Һәрберсенең исеме бар. Төбәк, яисә Чарлы тавы. Аннан көнбатышка таба олы юл сузыла, ул Кукмарага, Мамадышка, Сабага илтә. Каршы таудан төшкән юл Түбән Шөн авылына, аның аркылы Нократ Аланы шәһәренә илтә. Сөрән тау башы һәм Зират каршы тавы Нократ елгасына кадәр сузыла. Көньякка – урман юнәлешенә өч юл китә: Олы юл, Туры юл һәм Иске утын юлы. Алардан Тугыз авылы аша Мамадышка, Чаллыга барырга мөмкин.

Безнең якын-тирәдә коры һәм сулы елгалар күп. Татар Толлысы белән Түбән Шөн арасында Кәҗә үзәне һәм Аю елгалары (ерымнар) ята. Таулар тезмәсе ягында Чыршылы елга, Акбур елгасы, Төбәк елгасы бар. Урман ягында – сулы Янык, Зират, Ушланчы, Шикәр елгалары. Көнбатыштан Нократка бая телгә алынган инеш агып төшә.

Коры елгаларда җиләк-җимеш һәм төрле-төрле дару үләннәре, гөмбәләр үсә. Ачлык заманнарында авыл халкы җәен-көзен шундагы үләннәр, җиләк-җимеш һәм, билгеле, балык белән тукланып исән калган.

ХАЛЫК

Безнең авыл динле, иманлы булган, дип ышанып әйтергә мөмкин. Моны пәйгамбәребез исеме кушылган кешеләрнең күплеге дә дәлиллидер: Мөхәммәт, Мөхәммәтдин, Мөхәммәтнур, Мөхәммәтша, Шәмсемөхәммәт, Нурмөхәммәт, Динмөхәммәт һ.б. Хатын-кызларга Бибирәхимә, Бибирәхилә, Бибисара, Бибинур, Кәримә, Хәдичә, Мәймүнә, Галимә, Нәгыймә, Камилә кебек исемнәр кушылган. Авылыбызда кушамат белән йөрүчеләр бик аз. Балалар ата-анага әтәй, әнәй дип дәшә. Ир-атлар туганнарга абый, абзый, бабай, кордаш, энекәш, кода, җизни диләр. Хатын-кыз туганнар – тетү, апа, җиңги, олы тетү, май тетү, туган апа, бәләкәй тетү, кодагый, кодача һ.б.

Татар Толлысы халкы гомер буе юаш, тыңлаучан, эшчән һәм кыюсыз булды. Һәр эшен җиренә җиткереп башкарды, ил-көн кушкан эштән ары да тик утырмады: итек басты, чабата үрде, кисмәк-сандык ясады, кирпеч сукты, балта остасы булды. Хатын-кызлар оек яисә шәл бәйләде.

КОЛХОЗ ОЕШУ

Авылда 1930 елда күмәк хуҗалык төзелгән. Аңа «Кызыл таң» исеме бирелгән. Атлар, арба-чана, сука-тырма ише кораллар, сбруйлар гомуми милеккә әверелгән. Шушы вакыттан алып авыл халкы кол рәвешендә яшәде. Көне-төне җирдә тырмашуларына карамастан, рәисләр аларны тәмсез сүзләр белән сүгеп, аз гына кимчелекләре өчен дә штраф салып азаплады.

1955 елда колхозларны эреләндерү китте. Шул елны ук «Кызыл таң» белән «Новая жизнь» (үзгәртеп кору елларыннан алып аны «Яңа тормыш» дип тә йөрттеләр) хуҗалыклары кушылды. Шушы вакыйгадан авыл тарихында яңа чор – Чарлы авылы һәм анда яшәгән урыс халкы белән иңгә-иң, бер гаилә, бер йорт булып яшәү башланды. Берләшкән колхозның рәисе булып Чарлы кешесе Иван Карлушин калды. Татар Толлысы «Бригада №2» исемен алды. Бу вакытта безнең авылда «ГАЗ-51» автомашинасы һәм «СХТЗ-Нати» тракторлары бар иде. 1959 елда Плаксиха авылы, ягъни «Революция 1905 года» колхозы, «Новая жизнь»гә кушылды. Плаксиха икенче бригада составына керде. Бригаданың өч автомашинасы – «ЗИЛ» үзбушаткычы, «ЗИС-5», «ГАЗ-51» булды. Аларда Шамил Дәүләтшин, Гыйльметдин Ризванов һәм Шәмсемөхәммәт Нуриев йөрде.

1960 елдан И.Н.Карлушин лаеклы ялга китте. Рәис итеп Мисбах Якупов сайланды, ләкин озак эшләмәде, аны тиз арада Габделхак Мәүлин алыштырды. Бу чорда күмәк хуҗалык бик күп терлек үрчетте: ат, сыер, дуңгыз, сарык, куян, каз, үрдәк, тавык. Колхозның алты умарталыгында 800 оя умарта бар иде.

Г.М.Мәүлин хуҗалыкта зур үзгәрешләр башлады: мөгезле эре терлек тулысынча Татар Толлысына, дуңгызлар – Чарлыга, сарык-бозаулар – Плаксихага тупланды. Рентабельле булмаган куянчылык, сарыкчылык һәм кош-кортчылык озакламый, гомумән, бетерелде. Шул рәвешле специальләштерү азык культураларын бер урында туплап, эшне механиклаштырырга һәм комплекслы алып барырга ярдәм итте. Ферма мөдире булып Плаксихада Анна Гурьянова, Татар Толлысында Шәйдулла Миңнеханов, Чарлыда Елизавета Столяровалар эшләде.

Икенче бригадага кергән Татар Толлысы җире Чарлы басуыннан алып Нократ елгасына кадәр иде. Сөзәк тау битләре сукаланып, анда җитен, ясмык, тары чәчелде.

«ТАЯК»ТАН КИТҮ

1965 елда Габделхак Мәүлинны Саба авыл хуҗалыгы идарәсенең башлыгы итеп чакырдылар. Колхоз рәисе булып Хәким Мәүләвиев калды. Хәким абый эшләгәндә

күмәк хуҗалык «таяк» системасыннан китеп, колхозчыларга хезмәт хакы түләнә башлады. Бу бик катлаулы эш иде. Һәр башкарган эшкә бәя исәпләп, шуның буенча түлисе иде. Тариф ставкалары гел үзгәреп, артып торганга, яңа түләү тәртибенә халык бик кыенлык белән төшенде, колхозчыларга аның асылын аңлату берничә елга сузылды. Җитәкчеләр дә гарантияле түләүне авыр үзләштерде. Финанс-икътисад институтында курслар бетереп, күмәк хуҗалыкка беренче икътисадчы булып кайткач, минем өчен, шәхсән, бик мәшәкатьле вакытлар башланды.

БРЕЖНЕВ ЧОРЫ

1967 елдан хуҗалыкка яңа рәис – Мәсләви Галиев килде. Ул эшләгән чорда Новотроицкидан Чарлыга кадәр, Чарлыдан Татар Толлысына кадәр юл күтәрелде. Ялгыз хатын-кызларга йортлар, мәктәп бинасы, клуб, автомашиналар һәм тракторлар өчен парклар, заправка пунктлары төзелде. Кадрлар хәзерләү беренче урынга куелды.

Төзүчеләр. Сулдан уңга: утырганнар – Гәрәев Миңнегали, Мөхәммәтшин Нурмөхәммәт, Нәбиуллин Кәримулла, Шәвәлиев Билал, Хәйруллин Рәүф, Гобәйдуллин Мирзахмәт; басканнар – Хәсәнова Вәзирә, Зарипова Сания, Гаянова Зиләрә, Баһманов Сәлимгәрәй, Хәйруллина Наилә, Хуҗахмәтов Миңнәхмәт, Хөсәенов Муса. 1970 нче еллар

Эш планлы рәвештә алып барылды: биш елга план төзелде, ул арада бәяләр үзгәрешсез калды, инфляциянең ни икәнен белмәдек. Шуның ярдәмендә ел ахырына күпме саф табыш аласын билгеләү мөмкин иде. Җитештерү үсә барганлыктан, колхозчыларның эш хакы елдан-ел арта торды.

Мәсләви Галиевтән соң колхозны авыл хуҗалыгы буенча гаять тәҗрибәле кеше – Гыйльфан Сәхәбиев җитәкләде. Гыйльфан абый ындыр табакларына асфальт салдыра башлады. Игенчелек, терлекчелек белән бергә төзелеш эшләрен дә киң планда алып барды. Татар Толлысы авылында инеш аша яхшы күпер, Чарлы авылында идарә йорты, колхозчыларга тораклар, терлекчелек биналары салдырды, буалар будырды.

Колхозчы Николай Богомолов яхшы рәссам иде. Яңа идарә йорты каршына Владимир Ильич Ленин сурәтен ясап элде ул. Бер интеллигент кешенең: «Кем ясады?» – дип сораганы булды. Без дөресен әйткәч: «Алыгыз сез аны, дипломсыз кешегә Ленинны ясарга рөхсәт ителми», – диде. Ләкин юлбашчы барыбер алынмады – идарәгә килгән кешеләрне каршылап, озатып торды.

Гыйльфан Сәхәбиев 1978 елга кадәр эшләде. Шушы елдан колхозны Рәфикъ

Безнең мирас №9 сентябрь 2017

Рәүфов җитәкләде. Бу вакытта юлга һәм авыл урамнарына асфальт түшәлеп бетте. Авылны газлаштыру тәмамланды. Ялгыз кешеләргә торак төзү дәвам итте. Чарлы авылында административ бина, унъеллык мәктәп һәм җитештерү корылмалары, тирес җыю урыннары төзелде.

ЯНГЫН

1991 елның 31 маенда Татар Толлысы ут эчендә калды.

Республика семинары үткәрелгән көн иде. Җыелыш тәмамлангач, машиналарга утырып, төшке ашка – Нократ буена кузгалдык. Алдан барган «УАЗ-66» машинасына мин утырдым. Рульдә колхоз рәисе үзе иде. Кинәт авыл өстендә төтен күренде. Рәфикъ Рәүфов: «Юкка түгел бу», – дип шөбһәләнеп, зур тизлектә авылга «очты». Фатыйма апа йорты яна иде. Рәис бар көчкә барган машинадан сикереп төшәргә кушты. Каушаудан, ишекне ачып җибәргәнемне сизмәдем дә. Кая ул сикерү!

Авыл яшьләре. 1979 ел

Сикерсәм, чәчелеп китәчәкмен. Рәфикъ һаман: «Сикер, сикер!..» – дип кычкыра. Машина туктагач кына төшеп чаптым. Түбән очка җиткәндә ике-өч йорт яна иде инде. Сарайдан бозауны алып чыгып, бакча артына бәйләп куйдым. Өй кирәк-ярагын да бакчага күчерергә булдым. Ләкин ни күрим: кулымда сөлге генә калган, шуннан ары һәммәсе дә юлда чәчелеп беткән иде. Булдыра алмавымны аңлап, урамга ыргылдым. Үзем көчкә сулыйм. Республика, район һәм хуҗалык җитәкчеләре – барысы да йөгерешеп йөри иде инде. Отыры җил туктагандай булды, янгын сүндерү техникалары активлашты һәм ялкынга ян-яктагы йортларга үрелергә бирмәде. Ут күрүгә, беркемнең боерыгын көтмичә, Шөн тавыннан бульдозер белән төшеп, күршебез Сәлим инешне тиз генә буып куйды. Су җыела башлады. Машина шлангаларын инешкә үк сузып сиптерә башладылар.

Кичкә таба янгын сүрелде. Нәтиҗәдә, ике-өч сәгать эчендә уналты йорт һәм кура-каралтыдан күмер-кисәү генә өелеп калды. Бу коточкыч афәттән соң йорт-кураларны төзүдә районыбызның барлык хуҗалыклары ярдәмгә килде. Алар тырышлыгы белән шул ук елда һәр гаиләгә җыелма (каркаслы) йорт төзелде, авылдашлар кышка өй туе уздырып керде.

Күпме кешенең бер мизгелдә чәче агарды, күпме кеше йөрәк чирлегә әйләнде... Раббым! Берүк мондый фаҗигаләрне яңадан күрсәтә күрмә!

ҮЗГӘРЕШ ЧОРЫ

Сиксәненче еллар азагында цех структурасы нигезендә кооперативлар төзи башладык. Бу – ил белән Михаил Горбачев идарә иткән чор иде. Хуҗалыгыбыз буенча өчәр-унар кешедән торган 38 коллектив барлыкка килде. Шушы берәмлекләр мөгезле эре терлек, дуңгызчылык, игенчелек, механизация (тракторлар һәм автомашиналар), мәдәният-көнкүреш һәм төзелеш-ремонт эшләре буенча кооперативларга берләште. Хуҗалыкның белгечләре (специалистлар) алар белән җитәкчелек итте, кооперативлар исә, үз чиратында, гомуми идарә аппаратына (хуҗалык рәисе һәм аның идеология буенча ярдәмчесе, икътисадчы һәм аның ярдәмчесе, исәп-хисап аппараты һәм кадрлар буенча белгеч – җәмгысе унбер кеше) буйсынды. Оешманың уставы, башка юридик кәгазьләре язылды, тиешле урыннарда теркәлде. Кооператив системасы белән эшләү чорында җитештерү һәм сату күрсәткечләре сизелерлек артты. Планны 98%тан киметмәгән өчен бозау һәм дуңгыз караучыларга натуралата түләү кертелде.

Соңыннан кооперативны арендачылар берлеге итеп үзгәрттек. Бу система 2008 елга кадәр эшләде. Эшләрен үрнәк төстә алып баручы арендачыларыбыз күп иде: терлекчелектә – Рәсүл Сабиров, Әминә Шәвәлиева, Равил Кавиев, Мәхтүмә Зарипова, Рәсимә Шәвәлиева, Нәзирә Мөхәммәтдинова, Сәхәбетдин Шиһабетдинов, Иван Котов, Виктор Котов, Виктор Харжавин, Владимир Григорьев, Василий Щербаков; игенчелектә – Галимҗан Хәлимов, Михаил Шахмаев; механизациядә – Рафаэль Ибраһимов, Илфат Мәүләвиев, Юрий Столяров; төзелеш һәм төзекләндерүдә – Фәиз Мөхәммәтшин һәм Илсур Хәсәнов шундыйлардан булды.

ДИН КАЙТУ

Үзгәреш җилләре авылга динне кайтарды. Татар Толлысында Хәниф хәзрәт Галләмов күзәтүендә мәчетебез яңартылды. Балта остасы Билал Шәвәлиев Аллаһ йортын төрле бизәкле такталар белән тышлады. Зиратыбызны авыл халкы һәрдаим чистартып, карап тора. Аллага шөкер!

ИНВЕСТОР

Рәфикъ Рәүфов лаеклы ялга киткәннән соң, «Яңа тормыш» хуҗалыгында берничә рәис алышынды, ахыр чиктә, хуҗалык «Вамин» карамагына күчте. Буталчык, мәшәкатьле еллар башланды. Хуҗалыкның эше бөлгенлеккә китте. Тәртип начарланды. Продукция җитештерү кимеде. Хуҗалыкның төп яшәү чыганагы булган Чарлы дуңгызчылыгы, «дуңгыз чире» таралмасын дигән сылтау белән, юкка чыгарылды (ягъни инвесторның бурычын каплар өчен сатылып бетте). Хезмәт хакы өзеклек белән түләнүгә күчте. Яшьләр авылдан китү ягын карый башлады. Егерменче гасыр буе шаулап-гөрләп торган, Россиянең һәм Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре, күп кенә хөкүмәт орденнары кавалерлары эшләгән бик күп фермалар урынында хәзер – буш сарайлар.

Уртак хуҗалыгыбызны саклап кала алмадык. Бу эштә кемне дә булса гаепли алмыйм. Мин кечкенә кеше.

PS. Туган төбәгем тарихын нидән башларга, ничек язарга, дип уйлап йөрдем. Кайсы яктан алынасы, нәрсә язасы? Республика архивларында утырыр өчен ни мөмкинлегем, ни сәламәтлегем юк. Өлкәннәрдән сорашыр идең... соңгарылган. Үзебез карт-коры исәбендә йөрибез. Шуңа күрә, һичьюгы, үзем хәтерләгәнне, үзем белгәнне ташка басып калыйм, дидем. Яңа буын тамырларын, кем булуын, кайдан килүен онытмасын иде. ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2017

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ АСЫЛ УЛЫ

Рафаил Шәйдуллин

Йегет булсаң, йегетлек күргәз илгә...
Габдерәхим Утыз Имәни

Тарихны кешеләр яза. Үткәннәребез аларның уңыш-казанышларыннан һәм тайпылыш-хаталарыннан торганга күрә, ул катлаулы һәм гыйбрәтле. Аннан сабак алу фарыз, чөнки тарих галиҗәнаплары – кырыс хөкемдар, үзе белән исәпләшмәүне кичерми. Кешелек гасырлар дәвамында гаять күп сынауларга дучар ителә, әледән-әле дөньяның төрле почмакларында сугышлар кабына, яңа калалар һәм салалар барлыкка килә, күп кенә авыллар җир йөзеннән юкка чыга, туган-үскән йортларның да еш кына урыннары гына кала. Ә хәтер буыннардан-буыннарга күчә. Әгәр дә аны сакламасак, аерым бер нәселне генә түгел, тора-бара бөтен бер милләтне дә инкыйраз көтәчәк. Хәтер бетсә – үткәннәр җуела, ә инде үткәне юкның киләчәге дә булмый. Шуңа күрә үткәннәребезне, татар халкының һәм Татарстанның иҗтимагый-сәяси һәм этномәдәни тарихын өйрәнеп, аны халкыбызга кайтаручы һәм шул рәвешле тарихи хәтерне яңартучы галимнәребезнең, аерым алганда, Казан федераль университеты тарихчыларының нинди фидакарь һәм изге эш башкаруы ачык аңлашыла. Язмабыз – аларның берсе – татар милли-демократик хәрәкәте тарихыннан саллы хезмәтләре белән танылган галим, тарих фәннәре докторы профессор Рәмзи Вәлиев хакында.

Тарих фәне аңа тәкъдире тарафыннан тәгаенләнгән. Хәер, балалык еллары сугыш чоры белән өтелгән малайга фән дөньясы баштарак нининдидер сихри, романтик һәм шул ук вакытта буй җитмәслек өлкә булып тоела. Ни дисәң дә, ул чакта аның гаиләсендә дә, туган-тумачасы һәм таныш-белешләре арасында да бер генә гыйлем әһеле дә булмый бит. (Хәзерге вакытта Р.К.Вәлиевнең кызы Эмилия – медицина фәннәре докторы, бертуганы Хәмитнең улы Дамир – юридик фәннәр докторы). Шуңа да карамастан, әти-әнисе уллары сайлаган юнәлешкә дә, аның теләк-омтылышларына да тирән ихтирам белән карый, аңа һәрьяклап булы-

шырга тырыша. Баксаң, үсеп җиткән егетнең һөнәр сайлавына мөнәсәбәттә авыл хуҗалыгына өстенлек биреп, шул өлкәгә караган белгечлек (агроном, бухгалтер, инженер һ.б.) алырга тәкъдим иткән дә булырлар иде.

Төрле чорларда (студентлык елларында, соңрак фән дөньясына кереп киткәч тә) аның белән аралашкан кешеләр күңелендә Рәмзи Вәлиев шәхесе күпкырлы, тынгысыз һәм шул ук вакытта гаять ярдәмчел образ буларак урын ала, чөнки аның фәнни һәм педагогик эшчәнлегенең һәр буыны кызыксыну һәм соклану уята. Р.К.Вәлиевнең тарих фәне үсешенә, белгечләр әзерләүгә һәм тәрбияләүгә керткән зур өлешен күз алдына китерү өчен, аның тормыш юлының аерым бер чорлары белән танышып чыгу да җитә. Һичшиксез, бу феномен җентекләп өйрәнелүгә лаек, чөнки аның фәнни-педагогик эшчәнлеге гаять тирән мәгънәгә ия һәм бай иҗади потенциалны чагылдыра. Галимнең фәнни һәм фәнни-методик хезмәтләре Россиядә һәм Татарстанда тарих фәне нигезләренең киләчәктә дә ныгуын тәэмин итте, аларның теоретик җирлегендә илебез югары уку йортлары тарихчы-тикшеренүчеләренең берничә буыны үсеп җитлекте. Рәмзи Кәлимовичның исеме тарих елъязмасына керде, хаклы рәвештә Россия Федерациясендә, Татарстан Республикасында һәм Казан федераль университетында тарих фәне казанышларының лаеклы рәвештә үзенчәлекле чагылышына әверелде.

Хәер, аның тормыш юлы да һәрьяктан үрнәк һәм гыйбрәт алырлык.

Ул 1937 елның 7 маенда Яшел Үзән районының Карашәм авылында Кәлимулла агай гаиләсендә дөньяга килә. Малайга Рәмзи исемен кушалар.

Татар халкында элек-электән инсан затына биреләчәк ат-исем билгеле бер дәрәҗәдә аның тәкъдирен тәгаенли дигән ышану таралган. Булачак галим исеменең сыйфатламалары арасында «үрнәк» дигән мәгънәсе дә бар. Аңа яшәеше дәвамында шул мәгънәгә тугры һәм лаеклы булырга туры килә – ул гомерлек имтихан тота.

Рәмзи Вәлиев сынаулар белән гомер юлының һәр чатында очраша. Сугыш чоры баласы буларак, бик иртә кул арасына керә – тормыш-ормыш арбасына җигелә.

Сугыштан соңгы ачлы-туклы елларда авыр крестьян тормышының, исәпсез салым газапларының барлык авырлыкларын үз җилкәсендә татый. Шуңа да карамастан, кечкенәдән килгән белемгә омтылуданмы, әллә табигый кызыксыну хикмәтеме – мәктәпне яхшы билгеләргә генә тәмамлый. Совет Армиясендә хәрби хезмәтен тутырып кайтканнан соң, атаклы Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына юл тота. Ул заманда идеологик асылы көчәя барган әлеге факультетка керү җиңел булмый, әмма үҗәтлеге, белемгә омтылышы һәм Ходай биргән сәләте үзенекен итә – кичәге солдат студент була, уку йортын 1963 елда уңышлы тәмамлый. Һәм шундук аны университеттагы иҗтимагый вазгыять һәм фәнни-педагогик тормыш үзенә бөтереп ала – университетның ВЛКСМ комитеты секретаре вазыйфасына тәкъдим ителә, бер үк вакытта ул философия кафедрасы ассистенты итеп тә тәгаенләнә. 1970 елда аны СССР тарихы кафедрасының өлкән укытучысы итеп раслыйлар, тагын биш елдан ул доцент вазифаларын башкара башлый. Галим һәм педагог 1992 елдан бүгенгәчә – хәзерге заман Ватан тарихы кафедрасы профессоры.

Баксаң, шаккатырлык – яңарак кына 80 яшьлек юбилеен билгеләп узган галимебезнең хезмәт биографиясенең биш дистә ярым еллар чамасы өлеше фәнни эзләнүләргә, укыту-педагогик эшчәнлеккә багышланган икән бит! Шул чорда ул дистәләрчә ачышлар ясаган һәм китаплар бастырган, профессорның лекцияләрен меңнәрчә студент – булачак галимнәрнең, укытучыларның һәм башка өлкәләрдә хезмәт куячак белгечләрнең берничә буыны тыңлаган. Ирексездән, юбилярның гыйльми җәһәттә озын гомерле булуы феноменының асылы һәм сәбәпләре нидән гыйбарәт соң, дигән сорау туа. Бер караганда, җавап гади дә кебек. Р.К.Вәлиев яшьлек елларында ук даими рәвештә һәм максатчан юнәлештә үзенең белемнәрен баету һәм камилләштерү өстендә эшли, аның бу сыйфаты гомер юлы буйлап яңа кимәлләрдә көчәеп үсә бара. Нинди генә вазифа башкарса да, ул һәрвакыт үзен кызыксындырган мәсьәләнең төбенә төшәргә, аны һәрьяклап һәм җентекләп өйрәнергә, ачыкларга омтыла. Рәмзи Кәлимович, укыту процессыннан аерылмыйча гына, күпсанлы хезмәтләр язды, монографияләр дөньяга чыгарды. Киң күләмдә танылган абруйлы галим буларак, 1990 елда Россиядәге 1917 елгы гомуммилли кризисны этрафлы ачкан һәм анализлаган докторлык диссертациясе яклады, соңрак ул, баетылып, аерым монография рәвешендә дөнья күрде («Назревание общенационального кризиса и его проявление в Поволжье и на Урале в 1917 году», Казан, 1979). Бүгенге көндә без аны ике дистәгә якын монография һәм 300дән артык фәнни, фәнни-популяр мәкалә авторы буларак беләбез. Әлеге сыйфаты – даими рәвештә үзенең профессиональ дәрәҗәсен күтәрүгә омтылышы галимнең сыгылмалы, иң катлаулы фәнни һәм дөньяви мәсьәләләрне киң колачлы хәл итүгә сәләтле фикерләү көченең нигезен хасил итте.

Рәмзи Кәлимовичның төрле вазыйфалар башкарганда этрафлы һәм гаять нәтиҗәле фәнни-педагогик эшчәнлеге факультет җитәкчелегенең дә игътибарын җәлеп итте. 1981 елда ул тарих факультеты деканы урынбасары итеп билгеләнде, 1995 һәм 1998 елларда ике тапкыр әлеге факультетның деканы булып сайланды. Казан университетының иң абруйлы факультетларының берсен очраклы рәвештә, кемнеңдер күңеленә хуш килеп кенә җитәкләү мөмкин түгел.

Р.К.Вәлиевнең декан буларак эшчәнлеге катлаулы һәм каршылыклар чиктән ашкан елларга туры килә. Укыту процессында 1991 елда СССР таркалганнан соң башланган демократик үзгәртеп корулар, акрынлап булса да, тизләнешле үсеш алалар. Татарстанда актив рәвештә республикадагы төп халыкларның милли





яңарыш процессы бара, яңа партияләр һәм иҗтимагый хәрәкәтләр барлыкка килә. Соңгылары Россия һәм Татарстанның хакимияттәге югары даирәләренекен генә түгел, укытучылардан башлап вазифаи затларга кадәр югары уку йортлары мәгариф системасы вәкилләренең мәнфәгатьләрен дә алга сөрәләр. Тарих факультетының төрле фәнни, этносәяси һәм идеологик карашлы кешеләрне берләштергән коллективы объектив рәвештә илдә һәм республикада барган иҗтимагый, социаль, милли характердагы вакыйгаларның һәм күренешләрнең тулы бер җыелмасын чагылдыра һәм үзенчәлекле «идеяләр кайнаган казан»ны хәтерләтә. Әлеге шартларда факультет деканаты алдына катгый рәвештә университетның нәтиҗәле эшләүче укыту һәм фәнни бүлекчәсе буларак сакланып калу һәм бәхәс клубы түбәнлегенә тәгәрәмәү бурычы килеп баса. Ул чакта һәр җитәкче дә гыйльми җәмәгатьчелекнең аңында барган үзгәрешләрне һәм шуларның нәтиҗәсе булган гамәлләрне тиешенчә кабул итәргә, югары уку йортлары структураларына үзләрен каршы куйган затлар белән ачыктан-ачык фикер алышуга сәләтле түгел иде. Кемнәргәдер фәнни эшчәнлектәге һәм укыту процессындагы иске калыплар юл куймады, кемдер исә университетта тамырдан үзгәргән вазгыять белән санлашмады. Әмма иң зур бәла аларның күбесенең либераль-демократик система шартларында яшәргә теләгән кешеләрнең тормыш-психологик менталитеты үзгәрүен кабул итәргә әзер булмавыннан гыйбарәт иде. Әйе, үтә четерекле хәлләр хөкем сөрде ул заманда. Әлеге шартларда тарих факультетының җитәкчесеннән аңа ышанып тапшырылган структурада тискәре күренешләргә юл куймау, фәнни җәмәгатьчелекне тиешле юнәлешкә кертеп җибәрү өчен бик күп нәрсә таләп ителде һәм Рәмзи Кәлимович үзенең барлык тәҗрибәсен, зирәклеген һәм акылын шул максатларда эшкә җикте. Нәтиҗәдә, факультеттагы укыту һәм фәнни-тикшеренү процессы аның демократик контролендә калды, күп кенә профессорлар һәм доцентлар аның йөзендә яңа шартларда тыныч һәм уңышлы эшләргә сәләтле җитәкче, ә студентлар исә зирәк һәм ышанычлы остаз күрделәр. Моңа ирешү, абруй казану асыл лидерлык сыйфатлары нигезендә мөмкин булды. Р.К.Вәлиевнең уртак фикергә килүгә омтылышы, чиктән тыш катгый, ара-тирә хәтта мәгънәсез таләпләр куючы оппонентларын да тыңлый белүе, фикер каршылыклары булуга карамастан, деканатның үзара килешенгән карарлар чыгаруы, факультетның профессорлар-укытучылар составы, ректорат белән тыгыз бәйләнештә эшчәнлек алып баруы аның җитәкчесенә карата тирән ихтирам уятты һәм аңа ышанычны

ныгытты. Һичшиксез, Рәмзи Кәлимович Казан федераль университеты Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Шәрыкне өйрәнү институтында бүген тарихчы галимнәр даирәсендә хөкем сөргән демократиянең чишмә башында торды.

Ул декан вазыйфаларын башкарган чорда тарих факультеты гаять зур уңай үзгәрешләр кичерде, аның яңа сәясәте нәтиҗәсендә факультетның мөмкинлекләре, илнең төрле уку йортлары һәм кайбер чит илләрдәге университетлар белән багланышлары киңәйде.

Моннан тыш, Р.К.Вәлиев тарафыннан фәнни кадрларны саклау һәм яңадан әзерләү, укытучылар даирәсен яшәртү юнәлешендә максатчан эш алып барылды. Факультетны тәмамлаучылар арасыннан ел саен кандидатлык диссертацияләре якланды, тарих фәннәре докторлары саны эзлекле рәвештә арта барды – факультетта көчле фәнни потенциалга ия яңа гыйльми-педагогик алмаш барлыкка килде. Аның чагыштырмача кыска деканлык эшчәнлеге чорында ул җитәкләгән факультет Казан дәүләт университетының иң нәтиҗәле һәм уңышлы эшләүче бүлекчәләренең берсенә әверелде, анда бер төркем студентлар өчен тарих татар телендә укытыла башлады.

Тарихчы галим буларак, Рәмзи Кәлимович этрафлы фәнни-тикшеренү эшчәнлеге алып бара. Яшь чагында археологик казу эшләрендә катнашты, аны Лаеш районының Рождествено авылы янындагы археологик комплексны өйрәнү нәтиҗәләренә багышланган «Рождествено авылы янындагы археологик истәлекләр» («Археологические памятники у села Рождествено». Казан, 1962) дигән хезмәт авторларының берсе буларак та беләбез.

Галимнең төп эзләнүләре Урта Идел буе төбәгенең XX гасырның 1 нче чирегендәге иҗтимагый-сәяси тарихы, татар зыялылары, шул исәптән Борһанетдин, Гыйльметдин, Галимҗан һәм Шәһретдин Шәрәфләр язмышы, Татарстанда Сталин чоры репрессияләре мәсьәләләренә багышлана. Шуларның нәтиҗәсе рәвешендә, «Фаҗига» китабы дөнья күрә (Казан, 1996). Ул, ана телебездә басылган фундаменталь монография буларак, фәнни даирәләрдә зур яңгыраш ала, җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итә. Р.К.Вәлиев бу юнәлештә әлеге хезмәт белән генә чикләнеп калмый, үзенең ачышлары белән бертуган Шәрәфләрнең аклануына хәлиткеч өлеш кертә, аларның кече ватанында – Буа районының Аксу авылында фәнни конференция, авыл укытучылары белән очрашу оештыра һәм уздыра, Казан урамнарының берсендәге (Жуковский урамы) бер йортка мемориаль такта урнаштырырга һәм Галимҗан Шәрәф каберенә таш куярга ярдәм итә. Ул, беренчеләрдән булып, Вәисиләр хәрәкәте тарихын, Борһанетдин һәм Гайнетдин Вәисовларның иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген өйрәнә, Г.Вәисовның рус әдәбияты классигы Л.Н.Толстой белән дусларча мөнәсәбәтен бәян итә. Әлеге мәсьәләләр буенча татар телендә аның тирәнтен дәлилләнгән «Өзелгән дога» (2007) дип аталган саллы китабы дөнья күрде.

Рәмзи Кәлимовичның гыйльми эшчәнлегенең тагын бер мөһим тармагы – Россиядә 1917-1918 еллардагы татар милли-азатлык хәрәкәтен яңача фикерләп өйрәнү нигезләрен булдыру юнәлешендә фәнни тикшеренүләр алып бару. Аерым алганда, «Болак арты республикасы» хезмәтендә (Казан, 1999) аның тарафыннан комплекслы рәвештә татар милли-демократик хәрәкәтендәге кризис һәм татар милли дәүләтчелек төзелешендә институциональ процессларның сүнүе сәбәпләре анализлана.

Галимнең фәнни тикшеренүләре арасында татар халкының милли мәнфәгатьләре суверенлашуы этапларына багышланган «Соңгы халык дошманы» («Последний враг народа». Казан, 2013) монографиясе аерым урын алып тора. Анда тәүге

тапкыр Татарстанның беренче суверенлыгы тарихы бәян ителә. Нәтиҗәдә автор, беренчеләрдән булып, «ике суверенлык» теориясен нигезләп үстерә, әлеге теория аның тарафыннан Татарстанның сәяси һәм икътисади мөстәкыйльлеген, шулай ук татар халкының этномәдәни мәнфәгатьләрен киңәйтү яссылыгында карала.

Р.К.Вәлиевнең «милли тайпылыш» мәсьәләләре яктыртылган хезмәтләрендә (Милли тайпылыш, «Мирас», 2004), тарих фәнендә беренче тапкыр, татар интеллигенциясенең татар милли дәүләтчелеге, Идел-Урал Штатын һәм Татарстан Республикасын төзү өчен көрәш манзарасын тергезү омтылышы ясала. Аерым игътибар Татарстан партия оешмасындагы төркемнәр көрәшенә юнәлтелә. Мөселман халкының милли-демократик хәрәкәтендә актив катнашкан татарларның язмышына кагылышлы материаллар зур урын били. Моннан тыш, татар халкының милли мәнфәгатьләре кысаларында «уңнар»ның Татарстан республикасының суверенлыгы өчен көрәш процессы һәрьяклап тикшерелә. Галимнең 1920нче елларда Татарстан сәяси җитәкчелегендә «уңнар» һәм «суллар» арасында барган көрәшкә карата үзенчәлекле мөнәсәбәте һәм фикерләре дә игътибарга лаек.

Р.К.Вәлиев һәм Г.Ә.Фәттахованың Татарстан АССРның Мәгариф халык комиссариаты каршындагы академик үзәк эшчәнлегенә багышланган уртак монографиясендә («Академический центр Татарии. 1920-е годы», Казан, 2002), төбәкне өйрәнү белән шөгыльләнгән төрле структуралар (җәмгыятьләр, түгәрәкләр һ.б.) эшчәнлеген анализлау белән бергә, татар халкының милли мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру белән бәйләнешле мәсьәләләр дә яктыртыла.

Бүгенге көндә күпләр Р.К.Вәлиевнең үзләренең остазы булуы белән хаклы рәвештә горурлана. Чирек гасыр чамасы чорда аның тарафыннан тарих фәне өлкәсендә 2 фәннәр докторы (Р.В.Шәйдуллин, И.А.Чуканов), 10нан артык фәннәр кандидаты (А.М.Вәлиев, Ә.А.Гатин, А.И.Диндаров, Л.М.Җаббарова, Г.Р.Кәримова, Л.О.Сулима, О.Н.Тихонов, Г.А.Фәттахова, К.Р.Шәкүров һ.б.) әзерләнде. Юбилярның шәкертләре Татарстанның, Марий Элның, Ульяновск өлкәсенең һәм башка төбәкләрнең төрле югары уку йортларында һәм тармак фәнни-тикшеренү институтларында эшлиләр.

Р.К.Вәлиев тарих фәнендә югары үрләр яулады – Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (1994), Россия Федерациясенең атказанган югары мәктәп хезмәткәре (2006), Казан дәүләт университетының атказанган профессоры (2007) исемнәренә, Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләгенә (2011) һ.б. дәрәҗә-бүләкләргә лаек булды. Аның сикәлтәле тормыш юлы һәм фәнни эшчәнлеге фидакарьлек, кешелеклелек, башкаларны ихтирам итү, тырышлык, намуслылык, тугрылык кебек гүзәл үрнәкләр белән бизәлгән. Халкыбызның асыл улына, галимнәрнең укытучысына, остазыбызга ныклы саулык, озын гомер, фәнни эшчәнлегендә яңа казанышлар телибез. Афәрин, Рәмзи ага!

РЕДАКЦИЯДӘН: Күренекле галим һәм педагог, журналыбызның даими авторы Рәмзи Кәлим улы Вәлиев күптән түгел гомер бәйрәмен билгеләп үтте. Без аны юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек һәм игелекле хезмәтендә уңышлар теләп калабыз! ■

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Уфадан Чиләбегә кадәр

Габдерәшит Ибраһимов

Тимер юл вокзалы. Уфа

БЕР ФРАНЦУЗ КЕШЕСЕ БЕЛӘН ШӘРЫК МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ ХАКЫНДА ӘҢГӘМӘ

Мин Уфадан тимер юл станциясенә килеп, поездга өске каттан урын алдым. Кереп, әйберләремне урнаштырып бетергәч, каршымда торган кешедән, купега кереп, мин килгәнгә кадәр әйберләремне карап, саклап торуын үтендем. Берни димәде, бары тик башын гына какты. Мин тиз генә барасы җиремә барып килдем. Урыныма килеп җитүгә, поезд кузгалып та китте. Юлдашыма русча: «Рәхмәт!» – дидем. Ул русча белмәгәнлеген аңлатырга тырышты. «Gran mersi», – дидем. Ул француз икән, бик канәгать калып, үз телендә: «Рәхмәт әйтерлек урын юк», – дип җавап бирде. Шуннан соң ук кем икәнемне һәм кайдан килүемне, кая баруымны сорады. Инде мин французча белмәвемне әйттем. Безнең мөхтәрәм юлдаш өметсезлеккә төшмәде: «Сез

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

татармы?» – дип сорады. Мин дә русча-французча «Әйе», – дидем.

Юлдаш кесәсеннән кечкенә генә дәфтәр чыгарды. «Французча-русча тәрҗемә сүзлеге» икән. Аның берничә русча сүзе белән минем ике-өч сүз французчамны бергә кушып, сүзлекне исә тәрҗемәче итеп, француз юлдашым белән әңгәмәгә керештек.

– Татарларда ник фәкыйрьлек бик күп? – дип сорады.

– Әсир милләт фәкыйрь дә була, хур һәм түбән дә була. Чөнки үз малына үзе хуҗа түгел, – дип җавап кайтардым.

– Татар-төрек бер үк ырудан килә, тик төрекләр арулыкка бик игътибарлы. Биредә сезнең татар милләтенең арулыкка, чисталыкка да артык игътибары юк, ахры, – диде.

– Госманлы төрекләре арулыкка, чисталыкка игътибарлы булырга тиешләр, чөнки арулык – Исламият таянган алтын баганаларның берсе. Биредә исә, христианлык һөҗүм иткән көннән башлап, без һаман да аларның буяулары белән буяла барганбыз, – дидем.

– Урал кайдан башлана? – дип сорады.

– Бу җирләр Урал инде, Уфаны үтеп китүгә, Урал башлана, – дип җавап бирдем.

– Алайса Уралны бик күреп булмас микәнни, кич җитеп килә. Ә кайда бетә? Иртән бер өлешен генә булса да күрергә өлгерербез микән?

– Мияс дигән җирләрдә бетә. Иртән Уралның иң матур җирләрен үтәчәкбез, – дидем.

Юлдаш кабат сәясәт турында сүз башлады:

– Төрекләр турында без инде беткән, таркалган милләт, дип уйлый идек. Тиздән аврупалылар тарафыннан бүлгәләнеп бетәчәк кебек тоела иде. Хәтта: «Кешелек дөньясының тынычлыгы хакына Госманлы дәүләтен юк итәргә кирәк», – диючеләр дә аз булмады. Матбугат битләре мондый фикерләр белән чуарланып беткән иде. Тик бу юлы Госманлы яшьләре бердәм хәрәкәт башладылар һәм һич кан түкмичә генә тиранлыкны тамырыннан йолкып аттылар. Алдан күз алдына китерүе дә мөмкин булмаган зур роль башкардылар. Браво! Мондый инкыйлаб-революциянең булганы да юк иде!

– Төрекләр Абдулхамитне тәхеттән төшерсәләр дә, барыбер шәрык мәсьәләсен юкка чыгара алмаслар. Госманлы дәүләте өчен төп мөһим мәсьәлә нәкъ менә бу шәрык мәсьәләсенең нәтиҗәсе булачак, – дидем.

– Инде шәрык мәсьәләсенең җеназасын кылырга вакыт, – диде.

– Зур кан күле ясалмыйча торып, шәрык мәсьәләсе һичбервакыт юкка чыкмаячак, – дидем.

– Русиядә ни өчен үзгәрешләр булмады? – дип сорады.

– Русиядә үзгәрешләр булды: Дума оешты, Конституция кабул ителде, – дип җавап бирдем.

– Юк ла! Боларның берсе дә булмады, – диде.

Юлдашым бик күп итеп, бик киң итеп сөйләшергә тели, тик теләгән фикерен әйтеп бирер өчен сүзлек актарырга кирәк, ә бу бик күп вакытны ала.

Безнең Русиядә поездлар һәр станциядә 10-12-15 минут торганнан соң өч тапкыр чаң кагыла, ике тапкыр сыбызгы сызгыртыла. Безнең француз юлдашыбыз моны ишетеп кычкырып көлә.

– Безнең руслар сак милләт, юлчы калмасын дип тырышалар, – дим.

– Сезнең руслар мәрткә китеп йоклаганнар, чаң кагып, сыбызгы сызгыртып, кыямәт кубарып, аларны торгызырга тырышу бу... – дип көлемсерәп утыра.

Шул арада, ничек булса, шулай булган, бер юлчы поездан калган булып чыкты. Моны ишетеп, француз эче катып көлде.

Шул рәвешле бер француз белән бер татар, бер-беребезнең телен яхшылап

белмәсәк тә, французның аз-маз русчасы булганга, арабызда менә шундый самимимлек барлыкка килде. Купеда бездән башка кеше булмавы да ярдәм итте булса кирәк. Төн җитте, йокладык.

Иртәгесе көн иртән иртүк күршем күзен ачкан, яткан җиреннән миңа карап көлеп: «Өч мәртәбә чаң кактылар, тор!» – диде.

Поезд Златоуст станциясенә җитеп килә иде. Биредә нәкъ бер сәгать торачак, шуңа күрә без француз юлдашым белән бергә чыктык, якында гына иртәнге чәебезне эчеп кире килдек. Купега тагын бер юлчы килеп урнашкан иде. Яшь кенә кеше, рус түгеллеге йөзеннән аңлашылып тора.

Яңа юлдашыбыз, француз юлдаш белән безнең әңгәмәне бераз тыңлап торганнан соң, инде өченче тел белән ирекле тәрҗемәче булып арага керде. Бу яшь кеше немец булып чыкты, русчасы бик әйбәт, француз юлдашымның берничә аврупа телен, шул исәптән немецчаны да белгәнлеген аңлаган идем инде.

Шулай итеп, инде без өч тел кулланып сөйләшә башладык.

– Рус мәктәпләрендә татар балалары күпме? – дип сорады француз.

– Миллионнан бер, – дип җавап бирдем.

– Бик гаҗәп! Ник бу кадәр аз? – дип сорады.

– Рус булырга теләмибез һәм булмаячакбыз да. Рус мәктәпләрендәге программаның максаты кешене укытып тәрбияләү түгел, христианлыкны җәелдерү, – дип җавап кайтардым.

– Үз мәктәпләрегез күпме? – дип сорады.

– Башлангыч мәктәпләребез күп, аннан соңгылары юк, – дип җавап кайтардым.

– Милләтегезнең күпмесе укый-яза белә?

– 55-60 %ы, – дидем.

– Браво! Руслардан күпкә алда икәнсез. Шулай булгач, ни өчен лицейлар, югары уку йортлары ачмыйсыз? – диде.

– Хөкүмәт рөхсәт итми. Шулай да, соңгы елларда ихтыяҗыбызны тәмин итәрлек мәктәпләр ачылды, – дидем.

– Думада сездән ничә әгъза бар?

– Сигез, – дип җавап бирдем.

– Бик гаҗәп, ике миллионга бер кеше. Искиткеч хаксызлык! – диде.

Мин, форсаттан файдаланып, француз юлдашка болай дидем:

– Көч булганда хаклык кирәкми шул. Сезнең французлар да Алжир мөселманнарын әнә хайван урынында тоталар, диннәрен хурлыйлар, кешелек хокукларын аяк астына салып таптадылар. Французлар кебек мәдәни милләткә әгәр бу дәрәҗәдә хаксызлык, бу кадәр вөҗдансызлык рөхсәт ителә икән, русларга инде бик әйтер сүз калмый.

Безнең юлдашның йөзе караңгыланып китте. Мин дәвам иттем:

– Аврупа милләтләренең мәдәният, алдынгылык дигән нәрсәләре – битлек кенә. Мәдәният – ул золым коралы. Хөкем-фәрман көч-куәт кулында булганда, көчсезләр тыныч яши алмаячак.

Шул арада поезд Чиләбегә килеп җиткән. Мин әйберләремне җыйдым, юлдашларым белән бик самими саубуллашып, поездан төштем.

ЧИЛӘБЕ

Чиләбе кечкенә генә бер шәһәр, ләкин Себер тимер юлларының башланган урыны булып тора. Бер яктан Мәскәүдән, икенче яктан Петербургтан килгән тимер юлларның берләшкән ноктасы булганга, ул көннән-көн үсә, үзгәрә һәм якын киләчәктә зур шәһәргә әвереләчәге көн кебек ачык.

Биредә әлегә мөселманнар бик аз булса да, моннан соң, һичшиксез, мөселманнары да күбәячәк, инде күбәя дә бара.

Безнең мирас №9 сентябрь 2017

Чиләбе

МӘКТӘПЛӘР

Мөселманнарның бер мәчетләре, бик матур, төзек бер мәктәпләре дә бар. Мәктәп хәзергә урта сыйныфларга кадәр генә оешкан, ел үткән саен, әлбәттә, югары сыйныфлары да булачак. Мәктәпнең идарәсе Закир һәм Ибраһим әфәнделәр исемле ике бертуганның ислам диненә булган тугрылыклары нигезендә хәерхаһлыклары белән тәэмин ителә.

КИТАПХАНӘ

Мәдрәсә бинасына кушып салынган бик матур китапханәләре дә бар. Биредә, шактый санда дәрәҗәле гыйльми һәм әдәби китаплар белән бергә, гарәп, төрек, рус, француз телләрендә газета-журналлар да бар. Бу китапханә – оештыручылары мөселманнар булса да – руслар өчен дә ачык.

Көндез көне буе ачык була, хәтта кичке сәгать уннарга кадәр эшли икән. Чиләбе яшьләре кичләрен бу китапханәгә килеп, вакытларын шунда китап укып үткәрәләр икән. Дөресе генә: мондый кеп-кечкенә шәһәрдә шундый мәдәният йортлары булганга шөкер итәргә кирәк!

СӘҮДӘ

Шәһәр кечкенә генә булса да, биредә сәүдә бик алга киткән. Сәүдәгәрләрнең бер өлеше – мөселманнар һәм алар арасында зур капиталга ия шәхесләр дә бар.

Сәүдәнең күп өлеше Уралда табыла торган матдәләргә нигезләнгән. Күп микъдарда файдалы казылмалар табылу белән бергә, биредә иген дә мул уңыш бирә, зур-зур фабрикалар эшли. Чиләбе киләчәктә гаять зур сәүдә үзәге була алачак, дигән сүзләр дә йөри.

Мин, Чиләбедә бер кич кунганнан соң, Себер тимер юллары белән Петропавловск (Кызылъяр), Омск, Томск шәһәрләренә юл тотарга уйлыйм, бу якынча 1700 километр ара.

Зур Себер тимер юлларының башлангыч ноктасы булган Чиләбе станциясенә килдем. Биредә һәрвакыт өч тарафка транзит булганга күрә, юлчыларның саны бихисап. Станция үзе кечкенә генә бер җир, күзгә ташланырлык үзгә бары бернәрсә бар – бу Русиянең эчке төбәкләреннән Себергә күчеп килүче мөһаҗир төркемнәре. Боларны күреп тә берни әйтми калу мөмкин түгел.

Бу мөһаҗир поездлары пассажир

Безнең мирас №9 сентябрь 2017

Златоуст вокзалы

поездларыннан шактый аерылып торса да, станциядә болардан меңләп кеше һәрвакыт бар һәм, гомумән, Себер чигендә болар булмаган җир бик сирәк. Ә инде Чиләбе – үзәк булганга күрә, мөһаҗир ташучы поездлар биредә чират көтеп атналар буе торырга да мөмкин. Ул кышкы суыкларда, һәр вагонда 40ар кеше, сасы, пычрак. Мондый җирдә әллә нинди авырулар барлыкка килүе бар.

Мин биредә Ярослав губернасыннан килүче бер кеше белән сөйләшеп тордым, хәл-әхвәл сораштым:

– Быел 250000 кеше Себернең Тобольск губернасына күчәргә тиеш дип билгеләнгән. Без менә 3000 йорт килергә чыктык. Чиләбегә кадәр – бер ай эчендә – юлда 200дән артык үле калдырдык, авыруларыбыз да бик күп.

– Күчеп китүегезгә канәгатьме соң сез? – дип сорадывм.

Әңгәмәдәшем, еларлык булып:

– Кеше туган җирен калдырып китүенә канәгать була аламы?! Кеше ватанын үз теләге белән ташлап китәме?! Ләкин чара юк, хөкүмәт безне мәҗбүр итте, китеп барабыз менә, кая баруыбызны да белмибез. Әле бит киткәннәрнең дә яртысы кире кайта. Менә бу поезд кире кайтучыларныкы, – дип, якынрак торган бер поездны күрсәтте.

– Безнең Тобольск – бик матур җир,– дидем. – Мин шунда туып үстем. Килеп урнашсагыз, рәхәтләнеп яшәрсез. Арагызда байлар бармы соң?

– Байлар чарасын да, юлын да табалар. Фәкыйрьләребез күп, – диде.

Шулвакыт чаң кактылар, мөһаҗирне калдырып китәргә мәҗбүр булдым. Вагонга кереп урыныма барып утырдым, юлчы бик күп. Купеда без дүрт кеше.

Поезд кузгалып китте, юлдашларымның барысы да рус. Сәүдәгәр икәнлекләре сөйләшкән сүзләреннән аңлашыла.

Рус сәүдәгәре үз эшенә артыгы белән бирелгән һәм күбесенчә надан була. Шул сәбәпле, мин Кызылъярга кадәр сүзсез генә уйларыма талып баруны кирәк дип таптым.

Төрекчәдән
***Асия Рәхимова** тәрҗемәсе.* ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2017

ОНЫТЫЛГАН БАРУДИЛАР

Хәнәфи Бәдигый

Күренекле галим, мәгърифәтче-педагог, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, XX йөз башланган чорда милләтебезнең рухи, мәдәни, дини, дөньяви, икъти-садий, матди тормышында гаять зур борылыш ясаган, шуны эстәп гамәл кылган, соңра Русия, Аурупа, гомумән, бөтен дөньяда мәшһүр мөфти сый-фатында танылган, аннары халкыбыз хәтереннән онытылырга мәҗбүр ителгән Галимҗан Баруди – эзәрлекләүләр, бар булганнарының һәммәсеннән мәхрүм итүләр, яла ягулар ачысын татыган асыл шәхесләребезнең иң күренеклеләреннән берсе.

Галимҗан Мөхәммәтҗан улы Галиев 1857 елның 17 февралендә Татарстанның хәзерге Биектау районы Кече Кавал авылында сәүдәгәр гаиләсендә дөньяга килә. 1860 елда әтисе гаиләсен Казанның үзе яшәгән Дары бистәсенә күчерә.

1869 елда рәсми рәвештә сәүдәгәрләр катламына кушылып киткәч, әтисе Мөхәммәтҗан Галиев, уртакул эшмәкәрдән башлап, бай сәүдәгәр-иганәче һәм сәнәгатьче дәрәҗәсенә ирешә. Озакламыйча үз иганәсенә Иске Татар бистәсе үзәгендәге Тихвин урамында зур бер таш йорт (Тукай урамы, 38 нче йорт) һәм шуның янәшәсендәге биш гөмбәзле мәчетне (Тукай урамы, 40 нчы йорт) киңәйтеп төзетеп куя.

Гыйлемле, дәрт-дәрманы ташып торган җәмәгать эшлеклесе әвәслегенә ия булган бу эшкуар губерна үзәгендәге йогынтылы кешеләр арасында кайнаша башлый. Мөхәммәтҗан Галиев үтәп барган вазифаларны санап бетерерлек түгел: 1875 елдан башлап өч дистә ел дәвамында ул даими рәвештә Шәһәр Думасы гласные булып тора, шәһәр Управасы әгъзасы итеп сайлана (1875-1880), Казан ятимнәр мәхкәмәсе, сәүдә вәкилләре әгъзасы (1880-1890), сәүдәгәрләр старостасы... Җәмәгатьчелек аны берничә тапкыр Санкт-Петербургка – Николай IIне тәхеткә утырту, Россия императоры таҗын кидерү кебек тантаналарда катнашу өчен вәкил итеп җибәрә. Аның төрле финанс тармакларындагы эшчәнлеге аеруча сокландыра. Бу – патша Россиясендә, ихтимал, мөселман эре сәүдәгәренең барчасы биш – Идел-Кама, Казан сәүдәгәрләре, Казан шәһәр җәмәгатьчелеге, Түбән Новгород ярминкәсе банкларында һәм Дәүләт банкының Минзәлә бүлекләрендә исәп-хисап комитеты әгъзасы вазифасын башкаруы кабатланмас очрактыр. Мөхәммәтҗан Галиевнең хезмәт дәфтәренә фидакяр вазифаи һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен монарх тарафыннан өч алтын, ике көмеш, бер бронза медаль белән бүләкләнүе теркәлә.

ОЛЫ ЮЛ БАШЫ

Әлеге күренекле шәхесләрнең кылган гамәлләре, бер рәхәтле, мең михнәтле язмышлары турында сокланып та, горурланып та, ачынып та язарга туры килә. Чөнки тарихыбыз сәхифәләрен ача башлауга күңелдә ихтыярсыздан: «Татарларның шушы сыйфаттагы асыл затларының нәсел-нәсәбәсендә кемнәр булган икән дә, алар кайларда дөньяга килеп, нинди әхвәлдә шундый дан-шөһрәткә ирештеләр икән?» – дигән сорау уяна. Бу нисбәттән, әлбәттә, аларның шәҗәрәсенә илтифат итү муафыйктыр.

Галимҗанның этисе Мөхәммәтҗан Галиев 1832 елның 13 сентябрендә Казанның Дары бистәсендә яшәгән отставкадагы солдат – гади хезмәткәр гаиләсендә дөньяга килә. Шул замандагы гореф-гадәт тәртибенчә, малай тиз арада әти-әнисе Ибнеәмин белән Хөснелхәят карамагыннан азат ителә. Берничә ел буена башлангыч мәдрәсәдә сабак алганнан соң, ул үз һәвәслеге белән көн күрергә өйрәнә башлый. Ата-анасы аны Казан тарафындагы киң танылган мәшһүр сәүдәгәр Мостафа Фәйзуллинга өйрәнчек итеп тапшыра. Тиз арада бу үсмер үзенең табигый сәләте, хезмәт сөючәнлеге белән сәүдәгәрнең алыштыргысыз ярдәмчесенә әверелә.

Озак та үтмәстән, Мостафа Фәйзуллин вафат була да, һич көтмәгәндә Мөхәммәтҗан Галиев эше гөрләп торган зур бер фирманың хуҗасына әйләнә дә куя. Шуннан соңра тырышлыгы аңа зур уңышлар, дан-шөһрәт китерә: тора-бара ул уртакул эшмәкәрдән бай сәүдәгәр, Русиянең атаклы сәнәгатьчесе булып танылa.

Менә шундый гаиләдә дөньяга килгән, тәрбия алган өлкән угыл Галимҗанга нәселләренең исемен мәңгеләштерү насыйп була.

1862 елда 5 яшьлек Галимҗанны Казанның ике манаралы мәчете каршындагы абруйлы «Кәрмия» – Икенче «Апанай» мәчете мәдрәсәсенә Нургали хәлфәгә сабакка бирәләр. Монда Бохара, Кабул, Гарәбстан, Мисырда укып, дини тәгълиматны тирәнтен үзләштергән, шул заманның атаклы теологлары дәресләр биргән. Шулардан берсе – шәригать кануннары һәм көнчыгыш телләре белгече, өендә бай дини китапханәсе булган Сәлахетдин Исхаков Галимҗан Галиевнең асыл остазы булган. Галимҗан мәдрәсәдә гарәп һәм төрек телләрен, мантыйк, ислам тарихы һ.б. фәннәрне өйрәнә.

Болак артында үзенең йогынтысын ныгытуга ирешкән этисе киләчәктә малаен биш гөмбәзле зур һәм бай мәчетнең имамы сыйфатында күрергә тели. Шуны күздә тотып, 1875 елда, энесе Газизҗан белән бергә, Галимҗанны дин гыйлеменнән югары белем алу өчен шул замандагы иң данлыклы мәдрәсәгә ия булган Бохара каласына укырга җибәрә.

Галимҗан җиде ел дәвамында атаклы Бохара мөдәррисләреннән сабак ала, көннәр буена, Әбүгалисина белән Әбелхарис шикелле, көтепханәләрдә борынгы кулъязмалар укый, шул ук вакытта шәрык мөселманнарының мәдәниятен һәм тормыш-көнкүрешен дә өйрәнә. Соңыннан ул бу чор турында: *«Тормышымдагы иң бәхетле еллар булды»*, – дип яза.

1882 елда Казанга зур белем һәм 5-6 мең тәңкәлек китап туплап кайткан Галимҗан Барудины биш гөмбәзле мәчетнең икенче мулласы итеп билгелиләр, шуның белән ул солдат хезмәтеннән дә котылып кала. Ә үзалдына зур максатлар куйган яшь хәзрәтне кечкенә мәхәллә мәдрәсәсендә укыту гына канәгатьләндереп җиткерми. Биредә ул бөтен мөселман мәгарифенә хас бер зур кимчелек – схоластика, ягъни ятлатып укыту ысулы белән килешә алмый. Шәкертләр сәгатьләр буена шәригать кануннары хакында бәхәсләшә алсалар да, бүтән фәннәрне, шул җөмләдән арифметикадан гади исәп-хисап ясауны йомшак белгән. Мәдрәсәләрдә белем бирүнең мондый торышы әүвәл нәүбәттән милли буржуазияне борчыган.

Ник дигәндә, рус эшмәкәрләре белән көндәшлектә җиңеп чыгу – яшәүнең төп шарты саналганга күрә, төрле-төрле эшкуарлыкта яхшы әзерлекле белгечләр кирәк була. Шуңа күрә яшь хәзрәтнең мәдрәсәдә хөкем сөргән тәртипләрне яхшы якка үзгәртергә омтылуын Казанның бай сәүдәгәрләре, алардан да бигрәк атасы Мөхәммәтҗан Галиев тә бар ихласы белән яклап чыккан. Ул, булдыклы, игелекле улының киләчәге турында кайгыртып, Галимҗанны тулы хокуклы хуҗага әверелдерү ниятеннән, мәхәлләдә (Сәгыйтовлар мәдрәсәсеннән кала икенче) аңа нигез салучының исеме кушылган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен оештыра. 1883 елда аның өчен биш гөмбәзле мәчетнең ишегалдында бер катлы кирпеч йорт (Тукай урамы, 34) төзетә. Галимҗан Баруди шушында үзенең мөгаллимлек эшчәнлеген башлап җибәрә. Дини фәннәрне яңача укытырга омтылуы гына да берничә ел эчендә яшь мөдәрриснең исемен Казанда гына түгел, тиз арада бөтен губернага танытып өлгерә. Шуңа күрә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укырга теләүче шәкертләр саны арта бара. Бер катлы мәдрәсә укыту таләпләренә җавап бирмәгәнгә, 1885-1886 елларда Казанның Беренче гильдия сәүдәгәре Әхмәтҗан Яхъя улы Сәйдәшев һәм Малмыж сәнәгатьчесе – Галимҗан Барудиның кияве Габдулла Исхак улы Үтәмешев белән бергә, бинаның беренчесенә өстәп, икенче һәм өченче катларын төзиләр. Нәтиҗәдә, «Мөхәммәдия» шәһәрдәге иң бай һәм уңайлы мәдрәсәләрнең берсенә әйләнә. Бүгенге көндә безне сокландырган нәфис архитектура корылмасының төзелеше, шул ук Үтәмешев һәм Ырынбур миллионеры – танылган меценат Әхмәтгали улы Хөсәенов тырышлыгы белән, 1901 елда төгәлләнә.

Әмма яңа алым белән укыту Казанда зур кыенлыклар һәм акрынлык белән генә гамәлгә ашырыла. Барудига хәтта үз мәхәлләсендә дә комачаулыйлар. Биш манаралы мәчетнең өлкән имамы Сәгыйтов, үзенең искелек белән килешмәгән ярдәмчесе белән бергә булмас өчен, асылда, бишенче мәхәлләдәге уку йортын таркатуга йөз тота. Баруди өч катлы заманча уку йортын төзергә ниятләгәндә, ул аңа элеккеге искергән корылмаларны сүтәргә ризалык бирүдән баш тарта. Нәтиҗәдә, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең зур корылмасы, Тихвин урамының кызыл сызыгыннан нык тайпылып, ишегалдының түрендә төзелә.

ГАЛӘМИ, ГАВАМИ УЙ-ГАМӘЛЛӘР

Галимҗан Баруди, юлда мөселман үзәкләре булган Төркия, Мисыр, Гарәбстанда туктап, исламның атаклы хокукчылары һәм фәлсәфәчеләреннән дәресләр тыңларга, Көнчыгыш мирасы һәм хәзерге рухи тормышы белән якыннанрак танышырга теләп, хаҗ кылырга ниятли. Ошбу сәфәреннән ул, мөселман гавамының тәрәккыяте «Ауропа һәм дөнья халыклары казанышларын үзләштергән сурәттә тагын да камилләшер», дигән тирән инану белән, шуңа мәсләк тоткан хәлдә әйләнеп кайта. Галимҗан Баруди милли мәгарифнең урта гасырлардан бирле дәвам итеп килгән кануннарына кыю рәвештә үзгәрешләр кертә башлый: 1891 елда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе аваз өйрәнү ысулы белән яңача укытуга күчә. Галимҗан хәзрәт үзе дә 3-4 ел эчендә 30дан артык дәреслек төзи. Аның беренче китабы «Гыйльме әт-тәүхид» («Аллаһның берлеге турында гыйлем») 1890 елда дөнья күрә һәм ул 1891-1915 елларда 12 тапкыр нәшер ителә. Шул ук елда аның арифметика буенча «Нәмунәи хисаб» («Үрнәк хисап»), ислам нигезе буенча «Китаб әссалават» – «Догалар китабы», «Бәдә әл-мәгариф» («Белемнәрнең нигезе»), «Сад пәнд» («Йөз нәсыйхәт») исемле хезмәтләре басылып чыга. (Әлеге уңайдан шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: башта ул язганнарын «Г.Пороховой» имзасы белән чыгара. Ләкин шул елларда «Пороховой Фатих» дигән җиңелчәрәк җыр һәм «Пороховой Фатыйма» кушамат-

лы бер җилбәзәк хатын булганга, имзаны гарәпчә «Баруди»(дары) дип үзгәртә.) Соңыннаң ул китапларның күпчелеге мөселман мәктәпләре өчен үрнәк кулланмага әйләнә һәм дистәдән артык тапкыр кабаттан нәшер ителә. Шул ук вакытта, тарихта беренче мәртәбә буларак, Галимҗан хәзрәт, традицион дини фәннәрне укыту белән бергә, үз мәдрәсәсенең программасына Аурупа уку йортлары дәрәҗәсенә якынайтып төзелгән дөньяви фәннәрне укытуны да кертә. Аның мәдрәсәсендәге шәкертләр 14 ел дәвамында укып гыйлем туплаган, дини белем белән бергә, гарәп, төрек һәм рус телләрен, арифметика, физика, геометрия, психология, география, педагогика, Русия тарихы, төрки халыклар тарихы һ. б. фәннәрне үзләштергән. Укулар расписание нигезендә алып барылган.

Нәкъ менә шушы мәдрәсәдә Идел буе татарларының бөтен дини-рухани уку йортларын үзгәртеп коруны мәсләк иткән шәкертләрнең ифрат яшерен рәвештә оешкан «Берлек» дип аталган алдынгы, демократик карашларны һәм фикерләрне тормышка ашыруны максат итеп куйган иҗтимагый оешма-хәрәкәт барлыкка килгән. Татар зыялыларының иң алдынгы вәкилләре шушы мәдрәсәдә аеруча төпле, заманча белем алганнар да инде.

Галимҗан Барудиның каһарманлыгы, беренче чиратта, шуннан гыйбарәт: тарихи яктан караганда бик кыска вакыт эчендә ул мөселман мәктәбен яңарыш юлына алып чыга, аны халыкның рухи яңарышын булдыру, милли үзаң тәрбияләү чыганагына әйләндерә.

Хәзер инде хәзрәтне, дини тәгълиматка каршы киләсең, дип гаепләргә батырчылык итүчеләр бик аз кала. Киресенчә, иң абруйлы кешеләр Галимҗан мулла тарафдарына әйләнә. Баруди үз тирәсенә сәүдәгәрләрнең яңа буынын – үзләрен «программистлар» дип атаган җәдитчеләр – Мөхәммәтсадыйк Галикиев, Сөләйман Аитов, Бәдретдин Апанаев, Вафа Гайнуллин, Гайнетдин Мөэминов кебек яңалыкны кабул итәргә әзер торган абруйлы кешеләрне туплый. Хәзрәт аларның капиталын һәм йогынтысын яңача үзгәртеп коруларны тирәнәйтүгә, дәүләт ярдәменнән мәхрүм калган мәктәп һәм мәдрәсәләрнең ныклы матди нигезен булдыруга юнәлтә. Шулай итеп, Шиһабетдин Мәрҗани вафатыннан соң, Казан мөселманнарының абруе гомумруссия күләмендә танылган, әмма әлегә рәсми булмаган яңа җитәкче-лидеры барлыкка килә. Баруди үз заманының башкаларга охшамаган алдынгы фикер иясе, яңа типтагы җәмәгать эшлеклесе була.

Галимҗан Баруди Бишенче елгы революция елларында туып килүче милли-демократик хәрәкәтнең идея ягыннан рухландыручысы буларак таныла. Ул, үзенең иң якын көрәштәшләре И.Гаспринский, Р.Ибраһимов, А.Тупчыбашев, Г.Апанаев, Й.Акчуралар белән бергә, милли мәсьәләне конституцион юл белән хәл итәргә омтылган беренче мөселман сәяси фиркасе «Иттифак әл-Мөслимин»нең башында тора.

КИРТӘЛЕ ЮЛЛАР ДӘВАМЫ

1905 елның октябрь Манифестыннан соң, Г.Барудига мөселманнарның тел, мәгърифәт, мәдәният, сәясәт һәм дини мәсьәләләрдә тигез хокуклылыгын тормышка ашыру өчен зур мөмкинлекләр ачылган кебек тоела. Әмма әлеге өметләрне гамәлгә ашырырга насыйп булмый, чөнки ул патша хөкүмәтенең кискен каршылыгына очрый. Әлеге каршылыклар сүздә генә калмыйча, гамәлдә дә бик ачык чагыла. Мәсәлән, шуның бер гыйбрәтле дәлиле сурәтендә 1907 елда җәдиди мәктәпләрдә укытучылар өчен әзерлек курслары ачарга ниятләнүләрен генә хәтергә төшерик. Аның йомгаклау өлеше сыйфатында халык мәгарифе хезмәткәрләренең Бөтенрусия съездын үткәрү күздә тотыла.

Вәләкин әлеге чараны гамәлгә ашыру өчен зур көч куеп төзелгән планнар бер көн эчендә юкка чыгарыла. «Берлек» программасының берничә данәсен очраклы рәвештә кулга төшергән губерна түрәләре андагы 12 бүлекнең икесенең Русиянең яшәп килүче җәмәгать һәм дәүләт төзелешен үзгәртеп коруга юнәлдерелүен «күреп алалар». Шундый җай чыгуны күптәннән көтеп, күзәтеп йөргән патша чиновниклары әлеге очракны шау-шулы сәяси эш кузгату өчен җитәрлек дәлил дип кабул итә. Жандарм идарәсе, моннан оста файдаланып, күптәннән шик астына алынган ышанычсыз Казан сәүдәгәрләрен һәм имамнарын аз да түгел... революцион фирка төзүдә гаепләп чыга.

1906-1908, 1913-1917 елларда Галимҗан Баруди «Әд-дин вә әл-әдәп» (дин вә әдәп) исемле дини һәм фәнни журнал нәшер итә. Шунда, панисламистик фикерләр таратуда гаепләнеп, 1908 елда җавапка тартыла.

Галимҗан Барудины гаепләрлек фактлар булмаса да, мулла Апанаевны, бертуган Галиевләрне һәм сәүдәгәр улы Казаковны полициянең ачык күзәтүе астында Архангельск губернасына сөргенгә җибәрү турында эш кузгатыла. Соңрак, беркадәр үзгәртүләр белән, җәза вакыты ике елга калдырыла, ә сөрү урынын, үзгәртеп, Вологда губернасына алыштыралар. Юктан гына башланган әлеге вакыйгаларның шул рәвешчә «чишелеше» Казанны гына түгел, Русиядә яшәүче бөтен мөселман, татар җәмәгатьчелеген тирән борчуга сала. Патша хөкүмәтенең Казан мөселман дин әһелләренә карата чыгарылган бу гаделсез карарын үзгәртү максатында, татар зыялылары берничә омтылыш ясап карый, әмма аларның барысы да уңышсыз тәмамлана.

Шулай да патша хөкүмәте кайбер ташламалар ясарга мәҗбүр була: сөргенгә сөрелгәннәргә калган вакытны Русиянең төньягында түгел, чит илдә үткәрергә рөхсәт бирә. Галимҗан мулла да башта Дәмәшкъта, аннан соң тоткынлыктагы калган вакытын Бәйрутта уздыра. 1910 елда сөргенгә сөрелгәннәрнең дүртесе дә – Салихҗан Галиев, Габдулла Апанаев, Әбделхәмид Казаков, Галимҗан Баруди 1911 елда Казанга әйләнеп кайта. Ни аяныч, биредә, шатлыклы очрашу-кавышу урынына, аларны яңа бәла-казалар көтеп торган икән шул.

1911 елда патша хөкүмәте, татар халкының милли аңы үсешен тоткарларга омтылып, яңача эшләүче уку йортларына каршы хәлиткеч һөҗүмгә күчә. Аерым әйтеп үткәндә, шул ук елның гыйнварында атаклы «Буби» мәдрәсәсе тар-мар ителә, аның җитәкчеләре һем мөгаллимнәре кулга алына, шәкертләре исә, куып таратыла.

Вятка губернасыннан килгән тарихи мәгълүм шикаять нигезендә, «Буби» мәдрәсәсен ябу гына түгел, хәтта Казанда яшәүче Г.Баруди, Г.Апанаев, Һ.Максудига да «патшага каршы эш йөртүчеләр» дип яла ягалар. Әлеге хәбәр чип-чи ялган булса да, хөкүмәт, кичекмәстән, тикшерү эшләрен башлап җибәрә. Галимҗан Барудины туктаусыз эзәрлекләүләрдән һәм яла ягулардан 1917 елгы февраль революциясе генә коткарып кала. Хәер, революциядән соңгы елларны да аның барлык хыяллары һәм өметләре тормышка ашкан бәхетле еллар, дип әйтеп булмый шул.

1917 елда Мәскәүдә узган I Бөтенрусия мөселманнар съездында Галимҗан Барудины Үзәк Диния нәзарәтенең мөфтие итеп сайлыйлар һәм ул Уфа шәһәрендәге эшчәнлеген башлап җибәрә. 1920 елда ул кабат мөфти итеп сайлана. Г.Баруди шул ук елны яшь Татарстан Республикасына үзенең иң зур байлыгын – 4288 китаптан торган шәхси китапханәсен бүләк итеп тапшыра. Ул китаплар Н.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең нигезен хасил итә.

Галимҗан мулла соңгы сулышына кадәр Ходай Тәгаләгә тугрылыклы хезмәт итү юлында була. Ул 1921 елның 6 нчы декабрендә, Мәскәүдә – хөкүмәт Идел буеның ачлыктан интегүче халкына ярдәм итүнең гадәттән тыш юлларын тикшергән вакытта вафат була. ■

ӘДИПНЕҢ КАБЕРЕ САКЛАНГАНМЫ?

Лирон Хәмидуллин

Мәгълүм булганча, быелның март аенда мәшһүр әдип, күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм галим Галимҗан Ибраһимовның туына 130 ел тулды. Әдипнең беренче иҗат үрнәкләре дөнья күрә башлауга да 110 ел була. Шул уңайдан матбугат битләрендә олуг әдипне искә алу чаралары да үткәрелеп килә. Аның гомер юлын һәм иҗатын барлауга багышланган киң колачлы бер гыйльми җыелыш исә моннан биш ел элек, Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылган иде. Әйе, элегрәк елларда матбугатта чыккан кайбер мәкаләләрдә дә, әлеге җитди конференция барышында да, Г.Ибраһимовның кабере сакланганмы соң, дигән сорау да булгалады. Аның иҗат биографиясендә бүген дә ачыкланып бетмәгән башка төр ак таплар барлыгы да күпләребезгә мәгълүмдер, мөгаен. Ләкин ул вакытта аларга аерым тукталучылар булмады шикелле.

Әйе, иҗат итә башлавына йөз елдан артык вакыт үтүгә карамастан, аның иҗатына да, җәмәгать эшчәнлеге һәм биографиясенә дә бәйле ак таплар тулаем өйрәнелгән һәм ачыкланган, дип төгәл генә әйтә алмыйбыз әле. Мәсәлән, аның үз мөхәррирлегендә нәшер ителгән «Ирек», «Безнең юл», «Чулпан» газеталарында чыккан, милләтебез язмышына кагылышлы фикерләре өстенлек иткән күпсанлы хезмәтләре бүгенге заман укучысына тулаем мәгълүм түгел дияргә дә була. Чөнки әле санап кителгән газеталар, шул

исәптән Үзәк мөселман комиссариаты нәшер иткән «Чулпан» да башлангыч чорда сул эсерлар йогынтысында булган. Алар милли мәсьәләләргә зур әһәмият биргән татар сул эсерлары газетасы саналган ич. Совет хакимияте елларында эсерлар эшчәнлеген искә алу катгый тыелган темаларның берсе иде. Егерменче елларда Казанда Академик үзәк җитәкчесе булып эшләгәндә дә Галимҗан Ибраһимов элекке милли карашларыннан тайпылмаган. Патша заманнарындагы каләмдәше һәм фикердәше Габделбарый Баттал да 1925 елда Төркиядә басылып чыккан «Казан төркиләре» китабында аның хакында: «Ул милли большевик булды», – дип яза. Үз халкына файда китерәчәгенә, татар милли мәдәниятен төзүгә өлеш кертә алачагына ышанып яшәде, ди. Шул ук елларда Г.Ибраһимов «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» дигән хезмәтен дә яза. Әмма ул хезмәтне һәм аның Академик үзәктәге эшчәнлеген милләтчелеккә бәйле итеп бәяләүчеләр аңа аяк чалырга керешкәндә генә олуг әдип авырып китә. Альберт Мөслимовның 1991 елда «Казан утлары»нда басылган «Рәсми әләк» мәкаләсе шул вакыйгаларга багышланган иде. Һәм егерменче ел урталарында корылган капкын Галимҗан агабызны каһәрле 1938 елда арабыздан алып та китә. Әйе, нәкъ милләт язмышына кагылышлы элекке хезмәтләре һәм шул юнәлештәге эшчәнлеге өчен бит инде олуг әдибебез зинданда җәфалап үтерелә дә. (1950 елларда аның төрмәдәш иптәшләре һәм «Пеләтән» төрмәсе хезмәткәрләре белән аралашкан Афзал ага Шамов шундый бер күренешне сөйләгән иде. Г.Ибраһимовтан сорау алучы берәү, кышкы суык көннәрдә берничә мәртәбә аны бозлы чолан идәненә бастырып, өстенә бозлы су койдыртып җәфалый. Шуннан соң әдип төрмә хастаханәсенә эләгә һәм озакламыйча вафат та була.)

Совет хакимияте чорында әдипнең милләт язмышына кагылышлы эшчәнлеген барлау, аларны тәфсилләп язып чыгу мөмкин түгел иде. Ә 1991 елдан соң, элекке «ябык» архивларның тимер ишекләре бераз ачыла төшкәч исә Галимҗан Ибраһимов шәхесе һәм язмышы белән кызыксыну, нишләптер, кими төште шикелле. Аның иҗатын һәм эшчәнлеген өйрәнүче элекке олпат галимнәр картайды яисә вафат булды. Алар урынына яңалары килмәде шикелле. Дөрес, мәрхүмә Фатыйма Ибраһимова, егерменче еллар вакыйгаларын чагылдырган байтак кына материал туплап, өч калын папканы китап нәшриятына тапшырган иде. Соңрак ул язмалар әдипнең «Сайланма әсәрләре»нең 9 нчы томы буларак басылып та чыктылар. Ләкин ул томда да алдарак искә алынган, милли хәрәкәткә багышланган язмалар тупланмаган иде, чөнки ул папкаларга кергән материаллар да әле Совет хакимияте чорында, архивларның «яшерен»лек билгесен йөрткән бүлекләренең ишекләре ябык чакта тупланганнар иде шул.

Шушы уңайдан бер-ике кечерәк фактка тукталып китәсем килә. Әдипнең иң актив иҗат иткән елларында аның иң якын ярдәмчесе һәм кайбер хезмәтләренең рус теленә тәрҗемәчесе дә булган Өммегөлсем апа Мөхәммәдева 1960-1980 еллар аралыгында иренә багышлап берничә биографик очерк, өч документаль повесть язган иде. 1980-1990 елларда мин аның шундый эчтәлекле, бай мәгълүматлы ике китабын – «Эзләнүләр» белән «Олы юл»ын бастырып чыгаруда катнаштым. Ул китапларның мөхәррире дә, алар турында матбугатта беренче хәбәр бирүче дә булдым.

Шул документаль повестьларын язарга керешкәнче, Өммегөлсем апа Г.Ибраһимовны якыннан белгән кешеләр белән аралаша, хатлар алыша, төрле-төрле документларның күчермәләрен алдыра, әдипкә кагылышы булган фотоларны туплый. Әдипнең 1920-1921 елларда бергә яшәгән беренче «зәүҗаны» Мәчтүрә Фәйзуллина һәм Киевта чакта якыннан аралашкан якташы, Уфа кызы Гөлсем

Әхтәмова-Ордубатская белән дә хатлар алыша. Өммегөлсем апа сөйләвенчә, Уфа-Бәләбәй төбәге морзалары нәселеннән булган Гөлсем туташ белән Галимҗан арасында дуслык мөнәсәбәтләре бөреләнеп килгән бер вакытта Киевта байтак кына татар яшьләрен кулга алалар. Шул исәптән Галимҗан да төрмәгә ябыла. Әдип белән Гөлсем баштарак хат язышып торалар. Аннары аралары өзелә. Әдип төрмәдән чыккан мәлдә Гөлсем каникулда, Уфада була. Г.Ибраһимовның 1914 елда Кавказга ял итәргә барышлый яңадан Киевка «кереп чыгуы»ның бер сәбәпчесе дә әлеге Гөлсем булган, дип сөйләгән иде Ө.Мөхәммәдева. Ләкин инде ул вакытта Гөлсем Әхтәмова Киев университеты студенты Фирүз Ордубатскийга вәгъдә биреп өлгергән икән. Шул сәбәпле, әдипнең Гөлсем белән үзара мөнәсәбәтләре ялганмый кала... Калган гомерен иренең туган илендә – Азәрбайҗанда уздырган Гөлсем 1960нчы елларда Казанга юлланган хатларында шул хакта язган икән...

Әлеге папкада Мәчтүрә Фәйзуллинадан алынган ике-өч хат та бар, дип сөйләгән иде Гөлсем апа. Ул хатынның Галимҗан белән ни сәбәпле аерылганлыгын тәфсилләп язмаган, «туган ягымны сагынып, Уфага чыгып киттем», дип кенә хәбәр иткән бугай. Ө.Мөхәммәдева әсәрләрендә бу хатын образы Хәнифә исеме белән теркәлгән. 1937дә Галимҗан төрмәгә ябылгач, шул Хәнифәнең Казанга килгәнлеге «Олы юл» әсәрендә әйтеп кителә.

Ө.Мөхәммәдева тарафыннан тупланган менә шундый хатлар, фотолар, документ күчермәләре калын-калын папкаларда әдибәнең өстәлендә өелеп тора иде. Ул папкаларның хәзерге язмышы миңа билгесез. Гөлсем апа вафат булгач, бер очрашу вакытында аның кызы Сөмбел дә: «Мин аларның кайда икәнлеген белмим», – дип җавап биргән иде. Әмма ул хатлар, ул документлар бөтенләй үк юкка чыкмагандыр, дип уйлыйм. Гөлсем апа аларны бәлки Дәүләт музее мирасханәсенә тапшырып өлгергән яисә Г.Ибраһимов иҗатын барлау өлкәсендә зур эшләр башкарган олуг галим Мансур Хәсәновка бүләк иткән булгандыр. Афзал ага Шамовның көндәлек язмаларында да шул мирас хакында берәр төрле хәбәр булуы бик ихтимал. Бу ике шәхес Өммегөлсем апаның иң якын киңәшчеләре дә, фикердәшләре дә булды. Гөлсем апа 1988 елның март аенда арабыздан китте. Ул вакытта әле кызы Сөмбел белән кияве Рафил Сафин – КДУ укытучылары – исән иде. Алар Гөлсем ападан аерым тора иде. Әби фатирында исә аларның кызлары, кияүләре һәм яшь баланың яшәгәнен хәтерлим. Ә менә татар халкы өчен бик затлы саналган, «әби өстәлендә сакланган» папкаларның язмышы әлегә билгесез кала.

Шуңа охшаш тагын бер очрак искә төшә. Алтмышынчы елларда Казанда Галимҗан Ибраһимов исемен йөрткән мәктәп бар иде. Ленин районының Восстание урамындагы 89 нчы татар мәктәбе. Урыныннан кузгала алмыйча ятакта яткан булачак халык шагыйре Фәнис Яруллинга урта белем бирүгә үз өлешен керткән мәктәп ул. Аның директоры Вазыйх ага Надриев белән 1960 нчы еллардан бирле ара-тирә аралашып яшәдек. Бер районда туган кешеләр идек. 1990 елларда бугай, мин аны бик тә борчылган кыяфәттә Язучылар берлеге урнашкан бина ишегалдында очраттым. «Галимҗан Ибраһимовка багышлап утыз биш ел дәвамында тупланган истәлек язмаларын һәм фотоларны югалттык. Ике-өч ел элек, илдә зур үзгәрешләр башлангач, аларны без шушында китереп биргән идек. Шуларны хәзер таба алмыйлар. Ул кыйммәтле истәлек язмаларын, фотоларны кем, кая куйган – белмиләр. Анда әдипне соңгы елларда карап, тәрбияләп торган ахыргы хатыны Хәдичә апа Фәтхуллинаның истәлекләре дә бар иде. Ул истәлекләр башка беркайда да басылмады, бездә аның тулы нөсхәсе иде. Мансур Хәсәнович әйтә: «Нигә анда тапшырдыгыз, ул папкаларны Үзәк музейга бирәсе булган, – ди. – Нишләргә инде хәзер?»

Шул тарихи истәлекләрнең язмышын ачыклый алмыйча, якташым тиздән вафат та булды. Берничә «иске» альбомны, кулдан язулы истәлекләр тупланган картон папкаларны кемдер, «кирәкмәс нәрсәләр», дип чүпкә ташлагандырмы яисә «киләчәктә кирәге чыгар әле», дип, ераккарак җыеп куйгандырмы – ни дип фаразларга да белмим. Вазыйх ага әйтүенчә, ул истәлек язмалары бик авырлык белән тупланган булган. «Авыру Хәдичә апа янына күкрәгенә Ленин орденын таккан әдәбият укытучысы үзе барып йөрде. Ул апа укучыларны гына кабул итми иде», – дип тә өстәп куйган иде якташым. Хәер, Афзал ага Шамов та Хәдичә ханымның истәлек сөйләргә ни өчендер авырсынганлыгын искә алгалар иде. Шул сәбәпле, Хәдичә Фәтхуллина язмалары «Г.Ибраһимов турында истәлекләр» (1966) китабына да кермәгән.

* * *

Әйе, Галимҗан Ибраһимовка багышланган язмаларның кайберләрендә «аның кабере билгесез» дигән сүзләр дә еш кына күзгә чалынып киткәли. Ил башы И.Сталин идарә иткән елларда эзсез югалган татар зыялыларының исемлеге бик зур. Алар турында сүз чыкканда бик еш кабатлана торган әйтем инде ул «эзсез югалды, кабере дә билгесез», диюләр. Чынлап та аларның күпчелегенең кайларда үлеп калганлыгы да, җәсәде җирләнгән җире дә билгесез. Әйтик, Казан зинданнарының берсендә атып үтерелгән, дип фаразланган Кәрим Тинчуринның кайсы зиратта җирләнгәне әле дә ачыкланмаган бугай. Совет хакимиятен урнаштыруда актив катнашкан комиссар һәм классик язучы Шамил Усмановның да каберенең кайдалыгы билгесез. Фәтхи Бурнаш соңгы айларын хәзерге Самара шәһәренең Безимянка исемен йөрткән лагеренда үткәргән. Шунда үтерелгән. Ул лагерьда булган тоткыннар зур бер хәрби завод төзелешендә эшлиләр. Шундый заводлар төзелешләрендә төп кул көче саналган һәм вакытсыз вафат булган меңнәрчә тоткыннарның каберләре билгесез кала. Шул исәптән Фәтхи Бурнашның да «асыл сөякләре менә шушында ята», дип, төгәл генә әйтә алмыйбыз. Аларны ачыкларлык мөмкинлекләр дә тудырылмады. Күпчелек тоткыннарның кайсы лагерьда җан биргәнлеге турындагы хәбәрләр дә якыннарына бик соңлап җиткерелде. Кайберәүләргә андый мәгълүматны 1990 нчы еллардан соң гына ачыкларга мөмкинлек тудырылды. Совет хакимиятенең «иң явыз дошманнарын» аклау карары СССР таркалгач кына чыгарылды.

Галимҗан Ибраһимов шәхесенә бәйле вакыйгалар башкачарак тора. Бердән, ул рус телендә «ГУЛаг» дип исемләнгән махсус лагерьларның берсендә үлеп калмаган. Әдип төрмәдә вафат булган. Хокукый яктан – юридик караштан чыгып фикер йөрткәндә беркадәр өстенлеге булган урында, дәүләтнең бер махсус оешмасы карамагында үлә. «ГУЛаг»лар исә – ярым яшерен оешмалар. Алар һәм андагы тоткыннар турында рәсми мәгълүматлар ярым яшерен төстә сакланган. Теге яки бу хәлне ачыкларга теләгән берәр оешма вәкиле яки әрсезрәк кеше төрмәнең кайдалыгын белгән һәм анда керү юлларын ачыклый алган. Шул җәһәттән караганда, Г.Ибраһимовның язмышы күпчелек башка тоткыннар язмышыннан аерылыбрак тора. Икенчедән, И.Сталин вафат булгач ук, күпчелек тоткыннарның аклануы турында карар кабул ителде. 1954 елның ахырларында Казанда Галимҗан Ибраһимовның акланырга тиешлеге турында да уйлана башлыйлар. Шул елның декабрендә «Тел, әдәбият һәм тарих институты»нда үткәрелгән бер җыелышта язучы Афзал Шамов чордашы Шамил Усманов язмышын, Әмирхан Еники исә якташы Галимҗан Ибраһимовка бәйле вакыйгаларны ачыкларга кирәк, дип сүз башлыйлар. Тиздән республика күләмендә гаепләнеп кулга алынучыларның язмышын ачыкларга тиешле комиссия төзелә. Аның җитәкчесе итеп партия өлкә комитетының өченче секретаре Салих

Батыев билгеләнә. Ул комиссиягә Язучылар берлеге идарәсе рәисе Гомәр Бәширов тә керә. 1955 ел башында С.Батыев аңа Мәскәүгә барырга, СССР Язучылар берлеге җитәкчесе Александр Фадеев белән дә киңәшеп кайтырга куша. А.Фадеев аңа, гаепсез дип фаразланган тоткыннарның аклануын үтенеп, дәүләт оешмаларына аерым-аерым хатлар юлларга киңәш итә. Ул хатлар туганнары исеменнән язылса, отышлырак булыр, ди. Шушы уңайдан Гөлсем Мөхәммәдеваның Г.Ибраһимов язмышына багышланган «Олы юл» повестена күз салыйк: «Г.Бәширов, Казанга кайткач, Әмирхан Еникине чакырып ала. (Олуг әдипнең якташын һәм үзен аның рухи шәкерте дип санаган язучыны.) Аңа, Галимҗан Ибраһимовның эшен яңадан карауны үтенеп, Партия Үзәк комитетына гариза язуны тәкъдим итә. Бик хәвефле хәлгә калу ихтималын уйласа да, әдип Еникиев, мондый йөкләмәне үтәү үзенең намус эше, дип, риза була. Озакка кичектермичә гаризаны яза да Гомәр Бәшировның кулына тапшыра». Берничә ай үткәч, 1955 елның 29 октябрендә СССР Прокуратурасы Әмирхан Еникинең өй адресына Г.Ибраһимовның аклануы турында хат юллый. Шуның нигезендә тиздән Татарстан хөкүмәтенең Галимҗан аганың исемен һәм мирасын халкына кайтару турындагы махсус карары чыгарыла.Ул карарда, әдип әсәрләренең күптомлыгы тиз арада нәшер ителергә тиешлеге, аңа багышлап истәлек язмаларын туплау кирәклеге турындагы тәкъдимнәр белән янәшә, каберен барлау бурычы да куелган була. Шул карар җирлегендә оештырылган дәүләт комиссиясенә Язучылар берлегеннән дә берничә кеше керә. Язучылар оешмасы һәм нәшрият вәкилләре төркеменең җитәкчесе итеп сугыш ветераны Афзал Шамов билгеләнә. Әлеге комиссиягә билгеләнүенең сәбәпләрен үзе болайрак дип аңлаткан иде. 1930 елларда китап нәшриятында эшләгәндә ул Г.Ибраһимовның иң соңгы әсәрләрен бастырып чыгарырга әзерләгән, әдип белән хатлар аша аралашкан була. Булачак китапның корректура вариантын редакцияләгәндә бер-ике җөмләне үзенчәрәк төзәткәне өчен, автор бер хатта аңа шелтә дә белдергән була. Дөрес, әдип кулга алынгач, ул китап («Безнең көннәр» романының дәвамы, «Караңгы төн мәңге булмас» романы) чыкмый кала, корректурасы юк ителә. «Шуларны да истә тотып, миңа аның өч томлыгын туплап, бастырып чыгару һәм башка эшләр йөкләтелде», – дигән иде Афзал ага.

А.Шамов шулай ук әдипнең кайчан, кайда җирләнгәнен ачыкларга тиешле булган, хөкүмәт тарафыннан билгеләнгән икенче бер комиссия утырышында да катнашкан. Аның сөйләвенчә, ул комиссия Пелатән төрмәсе эшчәнлегенә бәйле булган дистәләгән кеше белән әңгәмә оештыра. Әлеге кешеләр арасында әдип белән бер вакыттарак төрмәдә утыручылар да, төрле дәрәҗәдәге төрмә хезмәткәрләре дә була. Шулар арасында Г.Ибраһимовка карата яхшы мөнәсәбәттә булган бер татар хатынын да искә ала иде Афзал ага. Нишләптер, минем хәтердә ул табибә буларак истә калган. Исемен инде онытканмын. «Олы юл» повестенда исә автор аны «санитарка Фатыйма» дип телгә ала. Болар икесе ике кеше булгандырмы – әйтә алмыйм. Шул ук Афзал ага сөйләвенчә, комиссия эшләгән вакытта төрмәдән мәетләрне зиратка илтүче олаучы да, шул вакыйгада катнашкан тагын берничә кеше, шул исәптән Казанның Архангел бистәсе зираты хезмәткәре дә әле исән була. Алар сөйләгәнгә нигезләп, комиссия Галимҗан Ибраһимов җәсәденең кай тирәдә җирләнгәнен ачыклый. Һәм шул хакта махсус акт төзелә. Бүгенге көндә ул комиссия документлары архив киштәләрендә сакланган булырга тиештер, дип уйлыйм.

Хәзер шәһәр уртасында калган Архангел зиратының үзәк аллеясыннан ерак булмаган бер мәйданчыкта олуг әдип истәлегенә куелган затлы кабер ташы бар – татарча язулы зур гранит һәйкәл. Галимҗан аганың җәсәден төрмәдән алып чыккан

төндә күмелгән 4-5 кеше кабере өстенә куелган ул. Алда атап үтелгән комиссия ачыклаган урын шушы була. Шуннан ике-өч метр арырак, агачлык ышыгындарак, икенче бер татарча язулы истәлек ташы да бар иде 1960-1970 елларда. Ул кабердә әдипнең замандашы һәм зиндандашы булган Закир Самитов ята, дип язылган иде таш язмада. Афзал ага белән Зәйнәп апа Самитова сөйләвенчә, бу кабер иясен дә Пеләтән төрмәсеннән бер үк төндә, бер чанада алып чыгалар. Ләкин Зәйнәп апа ул төндә үз ирен читкәрәк алып китеп җирли.

Әлеге комиссия тарафыннан шулар да ачыклана: төрмәдә үлүчеләрне кыш айларында атнага бер мәртәбә генә җыеп җирләгәннәр икән. З.Самитов хатыны Зәйнәп апа бу вакыйгаларны болайрак искә ала иде. Үзе әйтүенчә, төрмә вакыйгаларына кагылышлы комиссия утырышларында ул да катнашкалаган. Шул комиссия төзегән актта аның да култамгасы булырга тиеш икән. Әйе, үзе әйтүенчә, комиссия актларына кул куючылар арасында ул да була. Ире Гражданнар сугышы чорындагы бер гаскәри берәмлекнең комиссары булган. Аннары Закир Самитов 1934 елга чаклы Казанда урнашкан милли укчы дивизиядә хезмәт иткән. Шул елның көзендә аны «Кызылармеец» газетасының элекке мөхәррире, яңарак кына Язучылар берлеге идарәсе рәисе итеп сайланган Кави Нәҗми Татарстан әдәби фондына эшкә чакыра. Ә 1937 елда аларның икесен дә кулга алалар, әлеге Беренче татар укчы дивизиясенең элекке командирларыннан берсе булган Якуб Чанышев белән бергә ниндидер бер «милли хәрәкәттә катнашуда» гаеплиләр. Закир Самитов әлеге «яшерен оешманы» оештыруда ук гаепләнгәндер, мөгаен. Шул сәбәпле, 1938 елның гыйнварында ул төрмәдә атып үтерелә. Аның белән бер вакыттарак кулга алынган К.Нәҗми белән Я.Чанышев бераз соңрак азат ителә.

Шул элекке комиссарның чая хатыны Зәйнәп апа ирен зинданга илтеп япкач та аның белән элемтә урнаштыру мөмкинлекләрен эзли башлый. Һәм төрмә тирәсендәге татар бистәләре кешеләрен якыннан белүе сәбәпле, тиздән үз дигәненә ирешә дә. Ире белән ара-тирә хәбәрләшә башлый. Закир атып үтерелгәч, иренең җәсәден төрмәдән кайчан алып чыгачакларын да алдан белә. Шул төндә эшләүче олаучы белән дә таныша. Ирен башкалардан аерып күмү чарасына керешә. Зират кешеләре төркеменә эләгеп, әлеге олауны каршы алуда катнаша. Төрмә кешеләре киткәч, үз ирен читкәрәк алып чыгып җирли. Шул олаучы аңа: «Болар арасында язучы Галимҗан да бар», – дип әйткән була. Әдипнең каберен ачыклаучы комиссия эшенә дә Зәйнәп Самитова шул төнге олаучы һәм башкаларның күрсәтмәсе буенча эләгә. ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2017

ЙӨРӘКЛӘРДӘ *Имай Насыйри*

Клара Тукаева-Насыйрова үзенең якын туганына багышланган документаль китабын әлеге исем белән атаган. Кем соң ул Имай Насыйри атлы татар каһарманы? Автор, төрле мәкаләләр, язмалар, истәлекләр аша, легендар шәхеснең тормыш юлын яктырта... Таланты ташып торган, ыргылып алга барган шәхеснең гомере көтмәгәндә вәхшиләрчә өзелә! Дөресрәге, ул юк ителә...

Язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Имай Низаметдин улы Насыйров 1898 елның 12 октябрендә Башкортстанның хәзерге Стәрлетамак районы Түбәнге Усылы авылында ярлы крестьян гаиләсендә туса да, аның нәсел җепләре танылган муллалар династиясенә барып тоташа. Башлангыч белемне туган авылында алгач, дүрт ел буена (1910-1914) Стәрлетамакта «Шәргыя» мәдрәсәсендә дә гыйлем туплый. Тукай шигырьләренә гашыйк кеше буларак, аңа ияреп, үзенең әсәрләрен шул йогынтыда яза. 1922 елда, белем эстәгән каласы Эстәрлегә багышлап:

«И Шәһәр! Моңлы шәһәр, серле шәһәр, шанлы шәһәр,
Куркыныч төннәрендә юл ярган маяк – нурлы камәр!
«Хуш, исән бул, мин китәмен!... Китте», – дип, борчылма әле!
«Якты таң аткач, мин ташлый, – дип, күрсенмә әле!»

– ди ул, Уфага киткәндә саубуллашып. Имай Насыйров 1918 елда туган авылы Түбәнге Усылыга кире кайтып, китапханәче булып эшли. 1919 елда Кызыл Армия сафларына алына, Урал фронтындагы Баш бригадада хезмәт итә. Ике айлык әзерлек курсы да үткәч, укып, агитаторга әйләнә. Шул ук чорда партия сафына алына, Күзәй кантонының (хәзерге көндә Нуриман районы) хәрби комиссариатында эшли.

Имай Низаметдин
улы Насыйров

Партиянең кантон комитеты әгъзасы итеп тә сайлана. Ул да түгел, егәре ташып торган, большевиклар идеясенә тулысынча инанган яшь егетне күреп алып, 1920 елның мартында РКП(б)ның Башкортстан өлкә комитеты әгъзалыгына кандидат итеп сайлыйлар. Шул ук елның июлендә ул Күзәй кантон милициясе начальнигы һәм кантон башкарма комитеты әгъзасы итеп тә билгеләнә. Югарыга таба үрмә гөлдәй үрли Имай Насыйри: 1920 елдан Башкортстан Үзәк Башкарма комитеты, 1921-1924 елларда – РКП(б)ның Башкортстан өлкә комитеты әгъзасы да ул. Йөрәгендә исә – ил, халык, ватан, дөнья юксыллары язмышы. Аны ул шигъри ялкын белән дөрләтә.

«Тетри дөнья!
Селкенә җир.
Селкенә, дер селкенә,
Җилкенә зур-зур чүкечләр,
Юлбасарлар милкенә...»,

– ди Имай Насыйри, үз заманына бәя биреп. Аның сәяси хезмәт эшчәнлеге иҗаты белән гомере буе үрелеп бара. Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури иҗатындагы поэтик илаһилыкны иман итеп алырга тырыша. Ошбу китапта филология фәннәре докторы

Суфиян Поварисов язып үткәнчә: «Аның «Хакыйкать чулпаны» («Правда» газетасы чыгарыла башлауга унөч ел тулуга багышланган) шигыре Мәҗит Гафуриның «Кызыл Байрак» әсәрен хәтерләтә. «Кыр казына», «Таң җиле», «Егерме беренче елның егерме икенче елга васыяте» һ.б. шигырьләрендә яңа заман рухы тасвирлана». 1923-1924 елларда Мәскәүдә өяз комитетлары секретарьларының әзерлек курсларын тәмамлагач, Имай Насыйри публицистика белән ныклап шөгыльләнә башлый, «Белем» журналының мөхәррире итеп билгеләнә. Бер үк вакытта «Сәнәк», «Керпе» журналлары да аның җитәкчелегендә чыгарыла. Белеме, табигате, кешелеклелек сыйфатлары белән ул башкаларга фәкать уңай йогынты гына ясый торган шәхес була. Замандашы **Баязит Бикбай** аның хакында менә ничек искә ала: *«Мин һәрвакыт Имай Насыйрины соклану белән күз алдына китерәм. Барыннан да элек, ул эчке һәм тышкы яктан җыйнак, туры сүзле, ягымлы кеше иде. Ун елга якын бергә эшләгән чорда мин аның бервакытта да буш сүз сөйләгәнен, тупас кыланганын күрмәдем! Ул һәрвакыт башы-аягы белән эшкә кереп чумган булыр иде. Бер үк вакытта ике журналның редакторы, җәмәгать эшлеклесе, язучы да иде әле ул! Аның көне, күрәсең, сәгать механизмы кебек, анык режимга куелган булгандыр»*. Әдип хакында **Сәйфи Кудаш** та дулкынланып, җылы итеп язган: *«Эшендә дә, шәхси тормышында да үзеннән пөхтәлек, җыйнаклык, культуралылык һәм интеллигентларга хас төгәллек аңкытып торган Имай Насыйри, җитәкче редактор һәм танылган әдип буларак, яшь язучыларга гына түгел, кайсыбер картларга да гүзәл өлге булырлык кеше. Шуңа күрә дә яшь язучылар аны редактор булганы өчен генә түгел, бәлки менә шушындый чын мәгънәсендә хәстәрлекле кеше булганы өчен дә яраталар һәм ихтирам итәләр иде»*.

Имай Насыйриның публицистик әсәрләрен барлап чыксак та, фикер йөртү офыкларының киң, аң-акылы тирән икәнлеген аңлыйсың: «Культура мәсьәләләренә карата», «Мәдәният йорты турында», «Париж коммунасы», «Онытылмаганнар әле», «Хуҗалык мәгарифенең агымдагы мөһим мәсьәләләре», «Үзең игенче булып, яшелчә чәчәргә онытма!», «Революция һәм мәдәният» һ.б. Әдип, киңкырлы талант буларак, шигырьләрдән – нәсергә, нәсердән хикәягә күчә. Тирән хис-тойгы, уйлану, аң-акыл белән язган нәсер һәм хикәяләрендә дә үзе яшәгән чордагы капма-каршылыкларны, кешеләр күңелендәге тирән психологик катламнарны ачыклап чагылдыру осталыгына ирешә, матурлыкка дан җырлый, искелеккә кабер казый.

Очкыннан – ялкын, ялкыннан зур ут шары барлыкка килгәндәй, Имай Насыйри вак жанрдан зур жанрга күчә бара – повестьлар һәм романнар яза. «Вагонда», «Тереләй кабердә», «Гөлләр» һәм «Һөҗүм» кебек әсәрләре аның югары сәнгатьлелек җәүһәрләре белән коралланa баруын раслый. «Без сул як ярдан», «Күзәй» исемле романнарында инде ул чәчмә әсәрләрдә (прозада) эпик киңлекнең сәнгатьчә чагылышы өлгеләрен оста куллана.

«Имай Насыйриның проза әсәрләренә тукталгач, шуларның берсе булган «Сибай» әсәреннән дә бер өзек китерү урынлы булыр. Әдипнең әсәрләрендә көчле динамика, укучыны тотып тора торган вакыйгалар куерылышы да бар. Иң гаҗәпләндергәне – драма әсәрләре язмаса да, прозасында драматургия көчле». (Рәдиф Сәгъди).

«– Ни сөйлисең син, әти? Нинди ташлар алар?.. Таштан ничек алтын ясап булсын?

– Ни сөйлим?.. Ни сөйләгәнне ишетәсездер бит. Менә бу ташлардан Советка алтын ясап бирергә уйлыйм.

– Саташа башладыңмы әллә, әти?

– Саташа? Ха-ха, ха-ха-ха!

– Соң нигә алай сөйләнәсең?.. Төшеңдә...

– Ни өчен сөйләнәм?.. Иске Сибай булмаганым өчен сөйләнәм... Мин хәзер элеккеге эндәшми торган Сибай түгел, ә товарищ Сибай... Советский Сибай!..

Шул ук вакыт ишек ягына сөялеп шаккатып торган Гөлбану җиңгәй ишек яңагына йөзе белән капланып кычкырып елап җибәрде...

– Ходаем, җен-фәлән сугып куймаса ярар иде!

– Елама, әни, куркынычлы бернәрсә дә юк. Мин хәзер доктор алып киләм.

– Ни тиленәнәсез юкка?.. Бернәрсә дә булганы юк! – дип кычкырып калуына карамыйча, Гөлбану җиңгәй үз артыннан ишекне шап иттереп ябып, элеп тә куйды. Сибай агай:

– Һәй саташканнар! – дип кире эшенә тотынды.

Гөлбану җиңгәй башта кызы Нисаның доктор алып килгәнен көтәргә уйлаган иде дә, ырымчы Гайни әбинең: «Җен кагылса, доктор бернәрсә дә булдыра алмый. Җен кагуның дәвасы миндә инде аның», – дигән сүзләре исенә төшеп, Гайни әбигә үзе дә барырга уйлады. Буш кул белән барганчы, дип, бер тавыгын да тотып алып култыгына кыстырды».

Имай Насыйри үзенең әсәрләрендә әнә шулай кызыклы мизгелләрне тотып алып тормыштагыча чагылдыра белә.

Имай Насыйриның иманы кешелеклелегендә була. Шушы сыйфат аның әсәрләрендә көзгедәй ачык чагыла. Әсәрне авырлаштырып, гавам халкы аңламаслык итеп язарга тырышучылар да бар... Ә аның әсәрләре кеше күңеленә ятардай, кызыклы, мавыктыргыч итеп язылган... Кеше күңеленә зәвык, рухи азык, илаһилык бирергә тырыша ул. Шигырь, нәсер, хикәя, повесть һәм романнарында без аның үз шәүкәтле образын күреп шатланабыз. Бу – чынлыкны язу осталыгы! Бу – сәнгатькә тугрылыклы булу! Бу – эстетик идеалыңа хыянәт итмәү! Бу – иманыңа бирелгән зәвыкны шан-шөһрәтле тота белү!» – дип язып үтә Суфиян ага Поварисов ошбу китапка кереш сүзендә.

Ни кызганыч, ошбу иманлылыгы аның вәхшиләрчә үтерелүенә дә китерә. Каһарман, үзе яшәгән системага чын күңелдән инанган шәхес, әлбәттә, гомеренең юк-бар өчен киселәчәген күз алдына да китерә алмый. Барысын да төптән аңлар өчен, сезгә шушы китапка кертелгән, рәхимсез елларның бер күренеше булган, тора-бара коточкыч үсеш алган репрессиянең аяусызлыгын дәлилләгән ВКП(б)ның Киров район комитеты утырышы беркетмәсенең күчермәсен китерәм:

«17 октябрь 1937 ел.

Эшнең асылы:

1) Насыров Имай Низам улы, «Белем», «Сәнәк» журналларының редакторы буларак, кызыллар тарафыннан атып үтерелгән контрреволюционер Бабичның хезмәтләрен 1929-1934 елларда ике тапкыр басып чыгарырга әзерли һәм шушы ук журналда аны мактап чыга. 1929 елда бөтен журналны Бабичка багышлый.

2) Насыров, «Коммуна» гәзитенең редакторы буларак, аппаратны ят элементлардан тазарту өчен хәстәрлек күрмәү генә түгел (Илкин, Мансуров, Мостеев һ.б.), киресенчә, аппаратны дошман элементлар белән чүпләвен дәвам итә (Нигматуллин һ.б.).

3) Насыров «Коммуна» гәзитен редакторлау дәверендә партия һәм хөкүмәт юлбашчыларының докладларын һәм чыгышларын бозып күрсәтә... Аңлы рәвештә тупланган материаллар белән Совет демократиясен һәм колхоз төзелешен яманлый.

4) Язучыларның «Үсү», «Җидегән» контрреволюцион оешмалары булуын һәм анда катнашуларын белә торып, аларны фаш итү генә түгел, киресенчә, кайберләрен, Ниг-

Клара Тукаева-Насыйрова

матуллин һәм башкаларны, «Коммуна» аппаратына эшкә ала.

Карар ителде:

Кызыллар тарафыннан атып үтерелгән контрреволюционер Бабичны матбугатта мактап чыкканы, аның хезмәтләрен матбугатка әзерләгәне, матбугатта совет демократиясен һәм колхоз төзелешен яманлаганы өчен, аппаратны дошман элементлар белән чүпләгәне, кайбер язучыларның контрреволюцион оешмаларда катнашуын белә торып, фаш итү генә түгел, киресенчә, аларны «Коммуна» аппаратына эшкә алганы өчен, Насыровны, буржуаз контрреволюцион милләтче буларак, ВКП(б) сафларыннан чыгарырга.

ВКП (б)ның Киров районы комитеты секретаре Буренкин».

Татар халкының сөекле улы, 1937 елны кулга алынып, 8 елга хөкем ителә. Үзенең бер гаепсезгә рәнҗетелгәнен тулысынча аңлаган җәмәгать эшлеклесе аңа яла ягылганын аңларлар, дөреслек өскә чыгар, дип өмет итә һәм Мәскәүгә, Сталин исеменә хатлар юллый. Менә шуларның берсеннән өзек:

«...Мин, Совет власте аркасында тормышка путевка алган, бөтен гомеремне, яшьлегемне туган илем өчен биргән ярлы баласы – туган иленә хыянәт итүче булып хәзер төрмәдә утырам. Бу тузга язмаган, колак ишетмәгән хәл! Бу тузга язмаган ялган! Мин бер генә минутка да коммунизмның бөек максатларына хыянәт итмәдем, Гражданнар сугышы окопларында большевик булып тудым. Бу эшемнең азагы ничек кенә бетсә дә, нәрсә генә күрсәм дә, үлгәнче большевик булып калырмын».

Әлбәттә, Имай Насыйри большевиклар алып килгән яңа тормышның якты киләчәгенә инанган, шуның өчен янып-көеп йөргән шәхес була. Аның кайбер шигырьләрендә дә шуңа омтылыш сизелә. «Яңа авыл» дигән әсәрендә:

«Заман яңа, галәм яңа,
Ләкин
Авыл иске.
Кирәк аны яңартырга,
Яңартырга, агартырга,
Дин чүбеннән
Тартып алып,
Таза суда тазартырга»,

– ди.

Алга таба ул колхозларны механикалаштырырга, авылларга электр уты кертергә дә, халыкны мәдәниятле, мәгърифәтле итәргә дә өндәп яза, шул хакта хыяллана.

Ни кызганыч, үзен күпме генә фронтка җибәрүләрен, партиягә, илгә тугрылыгын канын коеп дәлилләячәген сорап хатлар юлласа да, алар игътибарсыз калдырыла. Ә инде 1942 елны яңа карар чыгарылып, И.Насыйри атып үтерелә. Ул 1956 елда гына аклана. Шулай итеп, татарның Имай Насыйри атлы тагын бер затлы улы юкка чыгарыла. Мин файдаланган ошбу китапның авторы, Имай аганың туганнан туган оныгы Клара ханым Тукаева-Насыйрова, үзенең бабасының язмышына сыкрап:

«Гәүдәң калды чит-як туфракларда,
Баралмады беркем янына.
Ак күбәләк булып, канат җилпеп,
Җаның кайтты тугын ягына»,

– ди.

Язманы, Клара Тукаева-Насыйрованың
«Йөрәкләрдә Имай Насыйри» дигән китабын файдаланып,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе
***Рәдиф Сәгъди** әзерләде.*

Имай Насыйри

ЕГЪЛАТА

Анда моңлы яшь сабыйлар бер телем дип җан сата,
Монда шпорлы чибәрләр, «полька» уйнап, таң ката.
Анда назлы саф хатыннар бер телем дип тән сата,
Монда атлас, төлке туннан бай хатыннар ямь сата.
Анда көчле куллы ирне бер телем зар егълата[1],
Монда ирләр пар-пар аттан буш урамны тапата.
Анда мескен, ярлы башкорт бер телемсез ач ята,
Мондагы «уңган» агайлар, көнгә чыксаң, он сата,
«Бу ужас»[2] дип сүз чыгарсаң, кәефе килми бугай,
Кул селти дә «бары да Алла», ди, буш куык һәм сафсата[3].
Кычкыралар, үкерәләр, ил авыр, дип, кайда да,
Юк паек, дисәң, өеннән чыкмыйча хәстә[4] ята.
Монда куйсыннар берәүләр тешләрен алтын белән,
Әмма анда ач халык актык күлмәген сата.
Уйлыйсың әрнеп йөрәктән: «Кем гаепле?» – Баш ката,
Өстәге язган йөрәктә яшь күңелне болгата.
Ни өчен соң ул вечерлар, танцалар, тешләр тагын.
Әйтмим инде, катты башлар, килде яшьләр – егълата.

1922 ■

[1] Егълата – елата.
[2] Ужас – коточкыч, имәнеч хәл.
[3] Сафсата – буш сүз.
[4] Хәстә – авыру.

БЕР БӘЙЛӘМ БЕРКЕТМӘ

«АТАУДАГЫ ХИСЛӘР»

Сулдан уңга: Шәүкәт Галиев, Рафаил Төхфәтуллин, Энҗе Мөэминова, Шамил Бикчурин, Гомәр Бәширов, Зәки Нури, Саҗидә Сөләйманова, Сәет Кальметов, Гариф Ахунов, Әдип Маликов. Әлмәт шәһәре

16 февраль, 1959 ел

Татарстан Совет язучылары союзының шагыйрьләр секциясе.

Катнашалар: *Хәсән Туфан, Афзал Шамов, Гали Хуҗиев, Сибгат Хәким, Зәки Нури, Нури Арсланов, Әхмәт Юныс, Салих Баттал, Әмирхан Еники, Нәби Дәүли, Зыя Мансур һ.б. – барысы 27 кеше.*

Көн тәртибе:

*1. Шагыйрь **Әдип Маликов** иҗаты белән танышу.*

Беренче көн тәртибе буенча сүз шагыйрь **Гали Хуҗиевка** бирелә. Ул шагыйрь Әдип Маликов иҗаты турында сөйли. Гали Хуҗи иптәш Әдип Маликовның тормыш эченнән килүен күрсәтә:

– Иптәш инде өч җыентык чыгарды. Ул бу җыентыкларында үз тавышын сиздерә, үзе күргән, үзе кичергән вакыйгаларны белеп яза. Әдип иптәш үзенчә, халыкча итеп әйтергә тырыша. Ул фикерләр, поэтик хисләр, поэтик бизәкләр табарга омтыла. Ул шигырьләрендә оригинал фикерләр таба белә. Бигрәк тә бу яктан «Әтием итекләре» характерлы. Автор табигать күренешләрен оста сурәтли, алар күңелгә кереп калалар. «Атаудагы хисләр» поэмасында да ул уңышка ирешкән. «Ташчы» поэмасында яңа төзелеп килүче шәһәр һәм аның кешеләре турында матур һәм җылы итеп язылган строфалар бар. Ул укучыны дулкынландыра. Менә бу яклары – аның көчле ягы, шагыйрь шул ягы белән үсәргә тиеш. Иптәшнең ике поэмасы – «Атаудагы хисләр» һәм «Ташчы», беренче вариантларына караганда, яхшы гына төзәтелгәннәр һәм бу аның отышы. Иптәш Маликовның яңа поэмасы – «Гайшә апа» сюжет-композицион яктан яхшырган, диясе килә. Гайшә апаның баласын табу вакыйгасы кыска һәм ышандырырлык итеп бирелгән. Поэмада кимчелекләр дә юк түгел әле. Гомумән, бу поэма турында минем фикерем уңай якта. Тезмә юлларның ритмик чатаклыгы сизелә. Сүз сайланышында кайбер төгәлсезлекләр дә бар әле. Җыеп әйткәндә, Әдип Маликов – үсеп килә торган иптәш. Ул поэзиядә үзенең тавышын тагын да ныграк ишеттерә төшсен. Мин аны Язучылар союзына член итеп алырга кирәк, дип табам.

Сүз **Әдип** иптәш **Маликовка** бирелә. Ул «Гайшә апа» дигән поэмасының ничек язылуы турында сөйли. Аннары поэманы укып чыга.

Фикер алышулар.

Сүз **Сибгат Хәкимгә** бирелә:

– Әдип Маликовны без күптәннән беләбез. Минемчә, «Атаудагы хисләр» поэмасы лирик, җыйнак, матур гына. Аннан соң ул әйбәт шигырьләр дә язды. Әдип иптәш Мәскәүдә укыды һәм әдәбият институтын тәмамлады. Ул чын-чынлап әдәби эшкә тотынды һәм шушы юл белән үсеп килә. Соңгы әйберләре аның яхшы якка үсүен күрсәтәләр, ул бүгенге көннең сулышын бирә белә. «Гайшә апа»да матур урыннар бар. Гайшә апа газ белән өйләрне җылыта, чөнки ул сугышның авырлыкларын үз җилкәсендә татыган, салкын көннәрне күргән. Менә шул салкыннар яңадан кабатланмасын өчен, ул йөрәк җылысы белән эшли, тырыш кешеләрнең йортларын җылыта. Аннан иптәш Маликов Әлмәт шәһәре һәм аның гади кешеләре турында матур итеп язарга омтыла, ул тормышның эченә керә, матур бизәкләр таба. Иптәш Маликов – үсеп килә торган шагыйрьләрнең берсе.

Сүз **Зәки Нурига** бирелә:

– Әдипнең иҗаты зур түгел. Дөрес, аның күп вакыты уку белән бүленде. Җыентыкларын укып чыкканнан соң, миндә җылы фикер калды. Ул тормышны күзәтә һәм үзе күргән вакыйгаларны ачык һәм матур итеп, образлы итеп бирә ала. Шагыйрьнең тырышлыгы нык сизелә, поэтик яктан эшләнгән шигырьләр байтак. Мин аның юмор белән язылган шигырьләрен дә яратып укыдым. Мин Әдип Маликовны шагыйрьләр сафына алырга кирәк, дигән фикергә кушылам.

Сүз **Салих Батталга** бирелә:

– Иптәш Маликовның беренче поэмасы чыгу белән мин аны шагыйрьләр сафына керер, дип уйлаган идем. Ул моны аклады. Әдип иптәш яңа форма табу өстендә дә эшли. Авторның «Ташчы», «Гайшә апа» поэмалары миңа ошады.

Сүз **Хәсән Туфанга** бирелә:

– Мин Әдипнең беренче шигырьләрен укыганда ук кызыксынган идем. Шунда ук аңа карата өмет туган иде. Яңа җыентыгын карап чыктым. Беренче вариантына караганда, китапка кергән шигырьләре нык кына төзәтелгәннәр. Автор җыентыкның сыйфатын яхшыртуда байтак кына эшләгән. Аның «Әтием итекләре» шигыре камилләшкән, матурланган. Безнең алдыбызда әдәбият өлкәсенә карата зур таләпләр куела. Әдип иптәш менә шул теләкләрне аңлый. Без аңа үз тарафыбыздан ярдәм итәргә тиешбез. Аннан соң иптәшнең Әлмәттә әдәбият түгәрәге оештыруын һәм аңа җитәкчелек итүен уңай яктан бәяләп китәргә кирәк.

Сүз **Әхмәт Исхакка** бирелә:

– Әдип Маликовны без яхшы беләбез. Ул яңа әсәрләр язу өстендә эшли, эзләнә. Иптәш оригинал фикерләр әйтергә тели. Монда чыгып сөйләгән иптәшләр үзләренең сүзләрендә моны раслады. Ләкин иптәш Маликов акрынрак эшли. Киләчәктә без аның активрак эшләвен һәм яңадан-яңа матур әсәрләр бирүен телибез. Аны бүген шагыйрьләр секциясе исеменнән Язучылар союзына член итеп алу өчен тәкъдим итәргә кирәк.

Карар: Шагыйрь Әдип Маликов иптәшне Язучылар союзына член итеп алуны секция исеменнән Правлениедән сорарга.

Председатель – Әхмәт Исхак
Секретарь – Самат Шакир

*Беркетмәне **Ләбиб Лерон** укыды.* ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2017

Горурлык

Хикәя

Фәрит Гыйльми*
(1947-1993)

Яшел үлән өстендә, ике-өч көн генә элек дөнья яктысын күргән яшел йонлы каз бәбкәләре аяк терәп чирәм йолкырга азаплана.

Кояш та бераз күтәрелергә өлгергән икән инде. Вак төркемнәргә бүленгән чебен гаскәрләре күренә башлады. Тиздән авыл читендәге яланның аргы башы халык белән тулачак. Тиздән... Бүген бит Сабан туе.

Без чишмә буена килдек. Рафак бәйрәмгә дип тегелгән сатин күлмәген пычратып та өлгергән. Ул, лайга буялган җиңен җилфердәтеп, кул болгады да яр астына төшеп югалды.

Мин дә яр астына төштем. Таҗи бабай, изүләрен ычкындырып, битен, муенын чишмә суы белән чылатып алды. Малайлар аның әйләнәсендә бөтереләләр. Кайсыдыр бабайга сөртенергә дип майкасын сузмакчы була. Рафак кружка белән су алган да, гадәтенчә, әллә нинди сүзләр сөйләп, үзен күрсәтмәкче.

Таҗи бабайның безгә әллә ни исе китми. Түбәтәен киде дә иплән кенә салкын үги ана яфраклары өстенә барып утырды.

– Нәрсә минем тирәдә черкиләр кебек бөтереләсез әле. Мәйданга барыгыз. Сабан туе сездән башка ничек башланыр?!

– Кара әле, Таҗи бабай, әллә нинди матур чәчәк. Яна сорттыр инде бу.

– Һи, сез үзегез яңа сурт. Җиргә лап-лоп басып йөрисез, җимеше белән туенасыз. Ә үзегез, ачуым килмәсә әйтмәс идем, шуның берничә генә чәчәк исемен дә белмисез. Туң йөрәкләр сез.

– Белербез әле, бабай. Әле бит...

Рафак, боргаланып торырга вакыт юк, дигәндәй, сүзне мәсьәләнең асылына күчерде:

– Бабакай, быел ярышка Акбәкәл барамы соң?

– Һе, ансыз безнең авылдашларга җыенның яме буламы соң инде?— Күктә икенче кояш чыктымыни! Бабакаебыз шундук ачылып китте.— Бара, әлбәттә. Малкайны чабышка үзем әзерләдем.

Кәеф күтәрелде. Теләгебезгә ирештек. Хәзер «ат җене кагылган» бабакаебыз кыстатып тормаячак, тик аны бүлдермә генә.

– Нәселләре белән яхшы атлар шул алар. Мин әле аларның әниләренең әнисен — Тамчыны хәтерлим. Шушылай ак кашкалы, сумала кебек елкылдап торган кара бия иде. Ул, сөлек шикелле сузылып, башка атларны җир буе калдырып мәйданга килгәндә, бөтен халык сокланудан «аһ» итә иде. Ә безнең ише ыбыр-чыбыр малай халкы, шатлыгыбыздан кичкә кадәр өйгә кайтып кермичә, кайда туры килә, шунда җил куып йөрибез.

*Язучы-прозаик Фәрит Гыйльми (Фәрит Гыйльметдин улы Гыйльметдинов) 1947 елның 14 апрелендә хәзерге Татарстан Республикасының Мөслим районы Үрәзмәт авылында туа. 1993 елның 16 октябрендә кинәттән вафат була. Кабере – Зәй районының Бигеш авылы зиратында.

Р.Якупов фотосы

Тик бер тапкыр рәнҗеттеләр хайванкайны. Ай, бик каты рәнҗеттеләр, һич күз алдымнан китми. Бүгенге кебек чалт аяз, кояшлы иртә иде. Егетләр-кызлар тезелешеп утырган озын арбаларның тәгәрмәчләре күтәргән тузанны йота-йота, зурлардан калышмаска тырышып, күрше Яңа Сәет авылына җыен карарга киттек. Без мәйданга барып җиткәндә, төрле тамашаларның иң кызган чагы иде. Күрше малае Гайнетдиннең бер бакыр тәңкәсенә читтәрәк тезелешеп утырган түтәйләрнең берсеннән ике калай кружка кәбестә суы эчтек тә, халык төркеменә ияреп, ат чабышы карарга чыктык. Күңелемнән генә бер кызык уйлап чыгармакчымын. Малайларны куып җиткәч, егетләр, Тамчы минеке, калганнарын үзегез бүлешегез, дип кычкырып җибәрдем. Ниятемне аңлатып биргәч, Тамчының үзләренә әләкмәвенә пошынып, борыннарын салындырган малайлар берәм-берәм үзебезнең авыл атларын атый башладылар.

Берникадәр вакыттан дөньяда иң бәхетле кеше мин булачакмын. Минем тәкъдим буенча, без бүлешкән атларның кайсы беренче килә – шул ат иясе җирдәге иң бәхетле кеше булачак.

Кешеләрне этә-төртә үтеп, биегрәк урынга, читән өстенә атланып утырдык. Кемдер шунда: «Кузгалалар!» – дип кычкырып җибәрде. Әйтерсең, йөрәгемнең пәрдәсе өзелеп китте. Чүт егылып төшмәдем.

Еракта, урман ягында, калын булып тузан сызыгы күтәрелде. Капка түбәсенә кунаклаган агай, кулын бинокль итеп карап торган җиреннән, бөтен көченә акырып җибәрде:

— Байсарныкылар алдыра, кара бияләре беренче килә!

Тамчы беренче килә! Юк, Тамчы түгел, атка әверелеп, мин үзем бәхетемә очам! Киң күкрәкләрем белән эссе һаваны ярып, аяк асларымда ут уйната-уйната очам! Ә атлар, бер җепкә тезелеп, яшен утыдай сузылалар. Менә-менә килеп җитәчәкләр. Әмма... нәрсә бу! Гайнетдиннең кечкенә җирән чаптары Тамчыкаемны куып җитте. Янәшә баралар! Узып та китте! Минем атымны ниндидер ак чабышкы да артта

калдырды. Инде Тамчыкаем бөтенләй чапмый. Күз алдымда нәрсәгәдер кул изәп кычкыручы кешеләр дә, тәмам якынайган атлар да буталып бетте. Мәйданның асты-өскә килгәндәй булды. Күкрәгемдә нәрсәдер тартыша. Чигәмне әллә халык кыса, әллә туктап калган бәхетем. Бераз айнып киткәч, авылдашларым артыннан Тамчы янына чаптым. Без барып җиткәндә, җайдак малай Габдулла атыннан төшкән дә колагына җил кертмәс өчен башына ураган ак яулыгы белән ат аягының бәкәленнән югарырак урынын бәйләп маташа. Ак яулык аша кып-кызыл кан саркып тора. Нәрсә булган? Ник туктаган? Бөтен халыкның күзендә шул сораулар. Тамчының коңгырт күзләре нәкъ мөлдерәмә тулган тамчылар инде. Атның борын тишекләре киң ачылган, бөтен гәүдәсе белән көчәнеп сулыш ала. Миңа ул шулай бөтен гәүдәсе белән күзләрен тамызмас өчен тырыша кебек. Габдулла янында булашкан агай кинәт кычкырып җибәрде:

– Җәмәгать! Атның аягын нечкә тимер чыбык белән буып куйганнар бит!

Халык шаулаша, дулый башлады:

– Атка суларга ирек бирегез!

– Мал каргышы төшсен аңа!

– Малай ни караган?!

Габдулла, атны тезгененнән җитәкләп, алдан атлый. Авылдашлар башларын иеп аңа ияргәннәр.

Ул арада, ак сөлгесен болгап, чигүле кәләпүш кигән бер бабай йөгерә-йөгерә безнең төркемгә якынлашты да, Тамчыны сыйпый-сыйпый, аның муенына сөлгесен урап куйды.

– Атны мәйдан эченә алып барыгыз. Да, хайваннардан да түбәнрәк кешеләр бар бит әле дөньяда. Җан кебек атны харап иткәннәр.

Габдулла, бик җиңел генә сикереп, ат өстенә менеп утырды да Тамчыны мәйдан уртасына, башка чабышкылар янына бора башлады.

Тик нихәл бу! Тамчы түгәрәк уртасындагы башка атларны күрүгә туктап калды. Кинәт кенә борылды да, өстендәге малайга игътибар да итмичә, аксаклый-аксаклый, кире кыр ягына таба чабып китте. Минем авылдашлар ат артыннан чапмакчы булып караганнар иде, кәләпүшле бабай, кулын югары күтәреп, аларны туктатты:

– Борчымагыз хайванны, җәмәгать. Сөенегез генә. Горурлыгын югалтмаган ул. Горурлыгын!

Шул урында Таҗи бабай туктап калырга мәҗбүр булды: алар өе янына кайтып җиткәнбез икән ич. Йорт баскычында бабайның килене күренде.

– Әткәй, авыр булмаса, олан янында гына калып тор әле. Мин суга барып килим.

Таҗи бабай, сагышлы елмаеп, безгә таба борылды:

– Йә, оланнар, хәзер мәйданга барыгыз. Соңыннан сөйләп бетерермен. Озакламый үзем дә барып җитәрмен. Соңга кала күрмәгез.

* * *

Без, аның елмаюын күңел түренә бикләгән хәлдә, Сабан туе булачак яланга чаптык. Ә анда халык. Чабыш атлары киткән икән. Яше-карты басу капкасы янына өелгән. Акбәкәлне уйлап, елмаеп куябыз. Тик күңелләргә бераз шом да йөгерә. Кыргыз далаларыннан, күрше башкорт авылларыннан килгән бик көчле толпарлар да ярышачак бит хәзер. Акбәкәл сынатмасмы?

Менә атлар килүгә әзерлек тә башланды. Авыл капкасы каерып ачылган. Ачык авызларга кыр җиле тула. Ә йөрәкләр – йөрәкләр, дулкынланудан, урыннарыннан купкан... ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2017

Сүз һәм сурәт

Наил Таиров

Игътибарыгызга тәкъдим ителә торган фоторәсемгә ошбу елның җәендә йөз ел. Ул Оренбургтан ерак булмаган Кабан авылында төшерелгән. Биредә 1917 елның җәендә мөгаллимәләр курсы оештырылып, анда Россия империясенең төрле төбәкләреннән килгән мөслимәләр педагогика, ислам тәгълиматы, гарәп һәм татар телләренең грамматикасы, география, тарих, математика кебек фәннәр буенча белем алган һәм, әлбәттә, төрле кул эшләренә осталыкларын чарлаган. Курсларның җитәкчесе Багъбостан Вилдан кызы Мөәминова фоторәсемдә – үзәктә, танылган язучы, нашир һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Кәрими янында. Биредә, «Хөсәения» мәдрәсәсе мөгаллимнәре С.Бикбулатов, И.Бикчәнтәев, Ж.Вәлидиләр кебек ир-атлар белән бергә, мәшһүр хатын-кызларыбыз Сара Шакулова, Мәгъфия Латифия һәм Багъбостан ханым үзе дә укыткан.

Курсантларның язмышы ничек булган, алар кайларда мәгърифәт нурын чәчкән? Бәлки журнал укучылар арасында үзләренең туганнарын, якыннарын, укытучыларын табучылар да булыр? 1917 елгы әлеге фоторәсем хатын-кызларыбызның гыйлемгә омтылышын, аларның шундый курслар оештырып, берләшә алуын дәлилли. ■

СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙ
(1889-1937)

Габдулла Тукайның якын дусты Сәгыйть Сүнчәләй. 1915 ел

Шагыйрь һәм тәрҗемәче Сәгыйть Сүнчәләй – татар язучылары арасында совет режимы оештырган тәүге сәяси корбаннарның берсе.*

Бу урында, ни кызганыч, бер фактны искә төшерми мөмкин түгел: Габдулла Тукайның дусты, үзе исән чакта ук җәмәгатьчелек тарафыннан классиклыкка дәгъваланган күренекле каләм иясе илдә совет хакимияте урнашкач... шымчы-сексот («секретный сотрудник»тан кыскартылма) булып эшли. Агентура аңа яңадан-яңа бурычлар йөкли һәм аннан төгәл хисап таләп итә. Шагыйрь исә гомуми сүзләр сөйли, төрле имеш-мимеш, гайбәт белән чикләнә.

Аны беренче тапкыр 1927 елда солтангалиевчелектә гаепләп кулга алалар. Ике атнадан, гаебе исбатланмыйча, иреккә чыгаралар. Шуңа да карамастан, ул даими күзәтү астында яшәргә мәҗбүр була.

Уфа чекистлары (соңгы вакытларда Сүнчәләй белән элемтәне алар тота) шагыйрьгә тынгылык бирми, аны «органнар»дан мөһим фактларны яшереп калырга тырышуда гаеплиләр, җавапка тарталар. Ахыр чиктә, 1929 елның 28 февралендә Уфа ГПУсына чакыртып, «ялган күрсәтмә биргән өчен» (ягъни, «органнар»ны алдарга тырышканы өчен), 95 нче маддә нигезендә кулга алалар.

Сәгыйть Сүнчәләйнең «эше», башка солтангалиевчеләрнеке шикелле үк, ОГПУ суд коллегиясенең ябык утырышында адвокатсыз, шаһитларсыз тыңлана. Шагыйрьне иң югары җәзага – атарга хөкем итәләр.

Ләкин ул чакта мондый карарны ашык-пошык үтәү гадәткә керми әле, апелляция язарга, суд карары белән килешмичә, шикаять белдерергә мөмкин була. Сүнчәләй ярты ел буе үлемгә хөкем ителгән тоткыннар камерасында ята. 1931 елның 13 гыйнварында ОГПУның шул ук коллегиясе, апелляцияне тикшереп, «шәфкать» күрсәтә: атып үтерүне 10 елга концлагерьга ябу җәзасы белән алмаштыра. Каләм иясе Соловкига озатыла. Анда ул алты ел буе совет концлагеренең бөтен авырлыкларын кичерә.

Әмма «эш» моның белән генә чикләнми: дәүләт терророның иң кызган чорында Ленинград өлкәсе УНКВДсының 1937 ел 9 октябрендә Соловкида узган күчмә утырышы, ыгы-зыгысыз гына, гаепләүчеләрнең үзләренә дә хәбәр итмичә, исән калган «солтангалиевчеләр»нең «эш»ләрен тиз-тиз генә карап чыгып, һәммәсен (шул исәптән Сәгыйть Сүнчәләйне дә) атарга хөкем итә.

Карар 27 октябрьдә Соловки концлагере территориясендә гамәлгә ашырыла.

Рүзәл Мөхәммәтша *әзерләде.* ■

*Сәгыйть Сүнчәләй (1889-1937) – элекке Саратов губернасының Хвалын өязендәге Иске Мастак (хәзер Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районына карый) авылында дөньяга килә.

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.406.

2. Рафаэль Мостафин. Һәрберсен исемләп искә алыйк. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014. Б.189-199.

ТАТАР ХӘРБИ разведчиклары

Рәис Зарипов

Тарих фәннәре докторы Яков Гришин белән тарихчы-архивчы Сәйфетдин Мәнди бергәләп язган хезмәттән тагын бер өземтә: «1934 елның апрелендә РККАның Разведка идарәсе башлыгы Я.К.Берзин Һ.Маликовка Кытайда, Шинҗаңда җаваплы бурыч үтәү бурычы куя. Әңгәмә барышында Берзин Маликовка нинди шартларда эшләргә туры киләчәген җентекләп бәян итә. <...> Совет киңәшчеләре төркеменә Һ.Маликов җитәкчелек итә. Ул Көнбатыш Кытайдагы (Шинҗаң провинциясе) гаскәрләрнең башкомандующие Шень Шицайның беренче баш киңәшчесе сыйфатында юлга чыга. Аның белән И.Ф.Куц, П.С.Рыбалко, В.Т.Обухов, М.М.Шәйморатов кебек командир-инструкторлар була.

Төркем Кытайга 1934 елның 9 апрелендә китә. Дубан белән очрашкан вакытта сүз совет белгечләренең эшчәнлеге турында бара. Маликов искә алып китә: «Инструкторларны билгеләүнең элекке тәртибе Берзин күрсәтмәләренә тулысынча диярлек туры килә иде. Мин Шинҗаңда булган беренче елымда инструкторларны тиешле урыннарга куеп чыгуда фәкать кайбер әһәмиятле булмаган үзгәрешләр генә керттем. Мисал өчен, әйтик, минем белән килгән инструкторларның икесе (Рыбалко һәм Куц) фронтта эшләделәр, өченчесе (Обухов) фронтның тылында хезмәт күрсәтте, дүртенчесе (Шәйморатов) – яңа техника белән тәэмин ителгән таркау подразделениеләрдән оешкан уку полкында» (Гришин Я., Сайфутдин М. Маликов Ади Каримович: изломы судьбы // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2011 - №1/2 (62/63). – С. 67-68.). Авторлар Маликов бәян иткәннәрне Россия Федераль иминлек хезмәтенең Үзәк архивыннан (ЦА ФСБ РФ, д. 27516, т. III.) алганнарын ассызыклый.

1918 елдан ук хәрби разведкада хезмәт итә башлаган **Һади** (рус чыганакларында Ади) **Маликовның** тормыш юлы гаять катлаулы һәм фаҗигале вакыйгаларга бай. Кәрим мулла малае, канлы инкыйлаб таңы атмас борын, Тәтеш каласында училище, Казанда сәүдә мәктәбен һәм 1917 елның гыйнварында 2 нче Казан прапорщиклар мәктәбен тәмамлый. Беренче Бөтендөнья һәм Гражданнар сугышында катнаша. Прапорщиклар мәктәбен тәмамлагач, 56 нчы Житомир полкында рота командиры вазыйфасына керешә. 1918 елның 16 ноябренән, соңрак М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академиягә әйләнәчәк Генштабның кыска сроклы курсларында укый. Укуын вакытыннан алда тәмамлаган Һади Маликовны 1919 елның апрелендә Казан ныгытылган районы коменданты идарәсенә штаб башлыгының разведка буенча ярдәмчесе итеп билгелиләр. 1919 елның маеннан – штабның разведка бүлеге башлыгы.

Дәвамы. Башы журналның 7 нче санында.

Миргазиян Крыймов. 1930 нчы еллар

Шул елның декабрь аенда аны Бәләбәй каласында оешып килүче 2 нче аерым Идел буе Татар укчы бригадасы штабы башлыгы вазыйфасына үрләтәләр. Шунысы кызыклы: Маликовның ул чактагы ярдәмчеләренең берсе, киләчәктә хәрби разведка полковнигы званиесенә кадәр «үсәчәк», Чиләбе ныгытылган районы штабы башлыгы **Миргазиян Крыймов** була. Маликов Бәләбәйгә аяк баскан мизгелдә бригаданы 2 нче Төркестан укчы дивизиясе карамагына тапшыралар һәм Кызыл коммунарларның 3 нче Идел буе Татар укчы бригадасы итеп үзгәртәләр. Май аеннан – Кызыл коммунарларның 6 нчы Идел буе Татар укчы, июль аеннан 23 нче укчы дивизия составындагы 68 нче укчы бригада. Җәй буена бригада белән Һади Маликов командалык итә. 22 сентябрьдә, кабат 68 нче укчы бригаданың штаб башлыгы йөген тарткан Маликовны Мәскәүгә, Генштабка чакыртып алалар һәм ул 11 октябрьдә РККА Хәрби академиясенең югары курсына тыңлаучы буларак кабул ителә. Бер елдан биредә беренче мәртәбә тикшерү үтүен дә ассызыкларга кирәктер.

Нәкъ шул мәлне, РСФСР тышкы эшләр Халык комиссариаты Төркиядәге яңа гына оешып килүче совет вәкаләтле вәкиллегендә эшләү өчен, төрек телен белүче берничә тыңлаучы бирүләрен үтенеп, академия җитәкчелегенә мөрәҗәгать итә. Академиядә исә татарлардан башка андый тыңлаучылар табылмый. Чит илдә эшләячәк төркемгә Әпсәләмов, Маликов һәм Рәхимкулов сайлап алына. Һади Кәрим улы, вәкиллек каршындагы хәрби атташеның секретаре һәм ярдәмчесе буларак, 1921-1924 елларда, Төркиягә «командировка»ларга йөри-йөри, РККАның

Хәрби академиясендә укый. 3 нче август көнне дипломын, бер үк вакытта Кызыл Армия штабы һәм РККАның Хәрби академиясе башлыгы булып торган Михаил Фрунзеның үз кулыннан ала. Югары хәрби белемгә ия белгечне РККАның Разведка идарәсе җтиәкчелеге, Кызыл Байраклы Кавказ армиясе штабының Разведка бүлеге башлыгы итеп билгели. Биредә хезмәт иткәндә үткән аттестациясеннән бер өземтә: «Энергияле, инициативалы һәм ихтыяр көченә ия командир. Корычтай характерлы, кискен хәлләрдә югалып калмый, дисциплинага күнеккән. Үз кул астындагылар белән уңай мөгаләмәдә, походларны җиңел кичерә, сәяси әзерлеге яхшы».

Һади Маликов 1927 елның ноябреннән 1931 елның мартына кадәр – СССРның Ирандагы сәяси вәкиллеге каршында хәрби атташе. Шунысы үзенчәлекле: әлеге илдә ул оештырган агентура челтәрен «ачу» очраклары булмый. Ә аңа кадәр хәрби атташе булып торган Ардалион Александрович Бобрищев, нәкъ менә үзе оештырган агентура челтәренең ачылуы сәбәпле, Иранннан китәргә мәҗбүр була да инде. Маликов агентларын исә бер мәртәбә дә ачыклый, фаш итә алмыйлар. Якташыбызның һәм хәрби өлкәдә, һәм разведка белән бәйле эшчәнлегендә бик югары бәяләнүе 1929 елда үткән аттестациясендә кабат тулысынча раслана. Туган илгә әйләнеп кайтуга, Маликовны Белоруссия хәрби округына полк командиры итеп билгелиләр. Моңа гаҗәпләнәсе һәм аптырыйсы юк, чөнки академия тәмамлаган һәр хәрби теоритик белемен практика белән ныгытырга тиеш.

Әмма Һади Маликов туган ягында хезмәт итәргә теләк белдерә. Каршы килмиләр һәм аны Татарстанга җибәрәләр. Ул 1931 елның май аеннан 1933 елның маена кадәр, комдив Якуб Чанышев командалык иткән 1 нче Казан укчы дивизиясендә 190 нчы укчы һәм 1 нче Татар укчы полклары командиры – хәрби комиссары булып хезмәт итә. 1933 елның май ахырында кабат РККАның Разведка идарәсе карамагында: 1934 елның декабренә кадәр – көнчыгыш сектор башлыгы һәм 2 нче бүлек (агентура) башлыгы ярдәмчесе. Бу вазыйфасына керешү белән кабат энә тишегеннән үткәрелгән Маликов 1933-1934 елларда мактаулы аттестациягә лаек дип табыла: «Гомуми сәяси һәм хәрби белем дәрәҗәсе югары... <...> оператив-тактик яктан яхшы әзерлекле. Мөстәкыйль вазыйфалар биләүче һәм күптәннән хезмәттә булган тәҗрибәле разведка хезмәткәре. Агентура эшен белеп һәм яратып башкара. Инглиз, төрек, фарсы телләрен белә. <...> К-11 категориясе биреп, бүлек башлыгы вазыйфасына, мөстәкыйль эшкә үрләтүгә лаек» (Гришин Я., Сайфутдин Г., Маликов Ади. Күрс. хез. 67 б.).

1934 елның апрелендә РККА Разведка идарәсе башлыгы Я.К.Берзин Һади Маликовка җаваплы бурыч үтәү өчен Кытайга, Шинҗаңга барырга тәкъдим итә. 1934-1936 елларда Шинҗаң провинциясе генерал-губернаторы, Кытай генералы Шень Шицайның баш хәрби киңәшчесе булып торган чагында якташыбыз нәтиҗәле эш күрсәтә һәм илгә полковник званиесендә (17.01.1936) кайта. Ике ел буена губернаторның баш хәрби киңәшчесе сыйфатында эшләү чоры югары бәяләнгән Маликов 1937 елда Шинҗаңга оештырылган махсус хәрби экспедицияне җитәкли. Әмма шул елның 17 июлендә ике Кызыл Байрак ордены кавалеры, хәрби разведка полковнигы Һади Маликовны, «1923 елда Троцкий карарын яклап тавыш бирүе сәбәпле, разведка линиясе буенча файдалану мөмкин түгел» дигән үтә сәер һәм ахмак формулировка белән, разведкадан РККАның командирлар һәм начальниклар составы буенча идарәсе карамагына күчерәләр. Күпмедер вакыт ул Рязань пехота училищесында тактикадан өлкән җитәкче вазыйфасын башкара, 1938 елның 3 июнендә исә бөтенләй Кызыл Армиядән сөрелә һәм ярты ай дигәндә, НКВД тарафыннан кулга алына. Мәскәү, Казан, Куйбышев төрмәләрендә һәм Красноярск краендагы лагерьларда җәфа чигә. 1954 елда гына аклана, азат ителгәннән соң хатыны Рабига һәм кызы Зөлфия белән Мәскәүдә яши. Шунысы мөһим: Маликовның үзе кебек үк җыкны күп кичергән, өч еллап НКВД төрмәләрендә чиләнгән һәм Татарстанны икенче Ватаны санаган генерал-лейтенант Якуб Чанышев белән бик еш

Һади Маликов (уңда) һәм Шень Шицай. 1935 нче ел



Казанга кайтып йөрүләрен киләчәк буыннар өчен Татарстан Фәннәр академиясе академигы, профессор, тарих фәннәре докторы Рәфыйкъ Нәфыйгов (1928-2001) саллы мәкаләсендә «ташка басып» калдырган (Нафигов Р.И. Достоин звания Героя Советского Союза // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 1996. – №1/2. – С.238.).

Гаҗәеп үзенчәлекле һәм сирәк очрый торган хәл: 1924 елның, сентябреннән алып 1935 елның маена кадәрге гаять катлаулы чорда Кызыл Байраклы Кавказ армиясе штабының Разведка бүлеген дүрт татар – хәрби разведка генералы Минзакир Әпсәләмов һәм хәрби разведка полковниклары Һади Маликов, Миргазиян Крыймов, **Хөсәен Мәүлетов** җитәкли. Соңгы өч ел ярым буена шул вазыйфаны башкарган ике Кызыл Байрак ордены кавалеры, чыгышы белән Чистайдан булган Хөсәен Баһаветдин улы Мәүлетов – 1935 елның маеннан 1937 елның августына кадәр, яңа оешкан Кавказ арты хәрби округында Разведка бүлегенең беренче башлыгы. Казан педагогы Роман Гузенфельд ассызыклаганча, ул чакта «хәрби разведкадагы сәләтле һәм үрнәк офицерларның берсе, озакламый хәрби званиесе күтәрелүен көткән полковник Хөсәен Мәүлетов Разведка идарәсе җитәкчесе Берзинның уң кулы була» (Гузеньфельд Р.Л. Кем был Хусаин Мавлютов? // Казанские ведомости. – 2016. – №51. – 14 апр.).

Тик шундый фидакарь шәхесне 1937 елның 28 июлендә запаска җибәрәләр, тагын өч көннән кулга алалар һәм 30 октябрьдә үлем җәзасына хөкем итеп, атып үтерәләр. Бу инде илдә Кызыл Армиянең югары чиндагы командирларына каршы канлы репрессияләр котырына башлаган чор. Сталинга ышыкланган палачлар беркемне дә аяп тормый: совет хәрби разведкасын оешт順чыларның һәм җитәкчеләренең берсе, РККАның Разведка идарәсе башлыгы, 2 нче рангтагы армия комиссары Ян Берзинны (чын аты – Петерис Янович Кюзис, латышча – Peteris Kuzis) 1937 елның 1 августында вазыйфасыннан бушаталар һәм шул елның 27 ноябрендә кулга алалар. 8 айлап җәфалаганнан соң, чынбарлыкта совет хәрби разведкасы системасын булдырган һәм Ленин, ике Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнгән шәхесне 1938 елның 29 июлендә атып үтерәләр.

Кавказ арты хәрби округының Разведка бүлеге башлыгы полковник Хөсәен Мәүлетовның ярдәмчеләре булып торган милләттәшләребез – Касыйм каласында дөньяга аваз салган, М.В.Фрунзе исемендәге академиянең көнчыгыш факультетында төрек секторын тәмамлаган майор **Хәлил Таканаев** белән Казан губернасының Тәтеш өязе Исәк авылында (хәзерге Татарстанның Буа районы) туган капитан

Гариф Сабир улы Мәҗитов та шундый ук фаҗигале язмышка дучар була. Шаккатмалы хәл: хәрби разведка энциклопедиясендә урын алуга лаек табылган әлеге ике татар баласының хәтта кайчан бакый дөньяга күчүләре дә билгесез.

Кызыл Байраклы Кавказ армиясенең хәрби разведкасын җитәкләгән дүртенче татар каһарманы – Татарстанның хәзерге Лениногорск районына керүче Мөәмин Каратай авылында туган полковник Миргазиян Галиулла улы Крыймов. Укымышлы гаиләдән. Октябрь инкыйлабына кадәр үк әле укытучылар семинариясендә (1907-1912) һәм Тифлиста прапорщиклар мәктәбендә (1916) укый. М.В.Фрунзе исемендәге академиянең төп курсын (1921-1924) һәм көнчыгыш (1924-1926), оператив (1932-1933) факультетларын тәмамлый. Туган теленннән тыш, инглиз һәм төрек телләрен белә. 1926-1932 елларда РККА Разведка идарәсе карамагында: биш ел буена СССРның Төркиядәге сәяси вәкиллеге каршындагы атташеның аппарат хезмәткәре, 1931 елның мартыннан ноябренә кадәр Кызыл Байраклы Кавказ армиясе Разведка идарәсе башлыгы Минзакир Әпсәләмовның урынбасары. Шул айдан башлап, үз вазыйфасында калган көе, 1932 елның мартына кадәр идарә башлыгы йөген тартканнан соң гына башлык итеп тәгаенлиләр. 1933 елда М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академиянең оператив факультетын тәмамлауга, Татарстан АССР Үзәк Башкарма комитеты исемен йөртүче 1 нче Казан укчы дивизиясенең штаб башлыгы итеп билгеләнә. Ә инде 1935 елның 16 февралендә 19 нчы укчы корпусның штаб башлыгы ярдәмчесе итеп үрләтелә, әмма вазыйфасына керешеп өлгерми – М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академиянең гомуми тактика кафедрасы җитәкчесе итеп расланa. 1938 елның 1 гыйнварында академия буенча чыккан Боерыкка ярашлы рәвештә «Гомуми тактика кафедрасы ассистенты» дигән фәнни дәрәҗә бирелә. Илдә репрессияләр башлангач, әлбәттә инде, үткер һәм сизгер НКВД хезмәткәрләре Миргазиян Крыймовның нинди социаль катламнан икәнен «ачыклыйлар» һәм Кызыл Армиядән сөрәләр. Шул җәһәттән бер өземтә: «1938 елның 1 августында Оборона халык комиссары Боерыгы белән 43нче маддәнең «б» пункты буенча запаска җибәрелә, ә 1939 елда «троцкизм тарафдары булуы һәм үзенең социаль чыгышын яшергәне өчен» партиядән чыгарыла. Хәрби хезмәттән җибәрелгәч, Мәскәү каласының Москворецкий районындагы вузларда хәрби кафедра укытучысы һәм военрук булып эшли. 1939 елда хезмәттән җибәрү турындагы пунктны «43 нче маддәнең «а» пунктына үзгәртәләр» (Великая Отечественная: Комдивы. Военный биографический словарь. Том IV. Командиры стрелковых, горнострелковых дивизий, крымских, полярных, петрозаводских дивизий, дивизий ребольского направления, истребительных дивизий. (Иблянский – Печененко). – М.: Кучково поле, 2015. – С.451.).

Үз хокуклары һәм гаделлекне торгызу өчен көрәшүен туктатмаган милләттәшебез әнә шулай итеп, эштән җибәрү турындагы маддәне, «запаста калдыру» турындагысына үзгәрттерүгә ирешә. 1942 елның 23 февраленнән кабат Кызыл Армия кадрлары исемлегендә: Көньяк, 1 нче һәм 2 нче Украина фронтлары составында Бөек Ватан сугышында катнаша. Полковник Крыймов – 98 нче (1943 елның 16 апреленнән 86 нчы гвардия дивизиясе), 387 нче, 232 нче, 206 нчы укчы дивизияләр командиры урынбасары һәм 387 нче, 127 нче, 38 нче укчы дивизияләр командиры. 1945 елның 15 апрелендә Австриянең Альп тауларында барган сугышлар вакытында һәлак була. Гвардия полковнигы Миргазиян Крыймовның исеме Сербиянең Воеводина автономияле краена керүче Сомбор каласындагы совет офицерларының туганнар каберлегенә куелган обелискка уеп язылган. Якташыбыз яудагы батырлыклары өчен Ленин (1945) һәм ике Кызыл Байрак (1943, 1944) орденнары белән бүләкләнгән.

Татар матбугатында бөтенләй искә алынмый торган тагын бер хәрби разведка полковнигы ул – **Әшрәф Хәкимҗан улы Галимов**. Гәрчә дистә еллар буена

Хөсәен Мәүлетов. 1930 нчы еллар

хәрби архивлар белән эш йөртүче «Энциклопедия военной разведки» авторларының да әлеге каһарманның ни туган җирен, ни кайчан һәм кайда вафат булуын ачыклый алмаганнарын исәпкә алсак, моңа һич тә гаҗәпләнәсе юк. 1934 елда ул Төньяк Кавказ хәрби округының Разведка бүлеге штабы каршындагы махсус курсларны тәмамлый. Төркестан фронтында, Урта Азия һәм Төньяк Кавказ хәрби округларында хезмәт итә, 1941 елның июненнән – Кызыл Армия Генштабы Югары махсус мәктәбе тыңлаучысы. 1943 елның гыйнварыннан – фронтта: Орлов-Курск юнәлешендә барган сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. 1943-1944 елларда 2 нче танк армиясенең Разведка бүлеге башлыгы һәм штаб башлыгының разведка буенча урынбасары. Кызыл Йолдыз һәм I дәрәҗә Ватан сугышы орденнары кавалеры. Энциклопедиядә шул орденнарны бирү турындагы «Бүләкләү документлары»ннан өзекләр китерелә, ләкин шулардан соң каһарман милләттәшебез хакында башкача мәгълүмат юк.

Ә менә хәрби разведка ветераннары фондының сайтында (www.vrazvedka.com) Галимов турында күбрәк мәгълүмат алырга мөмкин. Аннан күренгәнчә, Әшрәф Хәкимҗан улы 1905 елның 10 апрелендә хәзерге Татарстанның Калакар (?) авылында туган. Тик менә энциклопедия авторларыннан аермалы буларак, Галимовның 1934 елда Төньяк Кавказ хәрби округында түгел, ә бәлки Урта Азия хәрби округында махсус курслар тәмамлавын раслау гына бераз күңелне кыра. Хәер, монда аптырарга урын юк та үзе. Кавказ арты хәрби округының Кызыл Байраклы Кавказ армиясе базасында 1935 елның 17 маенда гына оешуын, ә инде Төньяк Кавказ хәрби округының өченче мәртәбә 1921 елның 4 маенда ук оешып, фәкать 1945 елның 9 июлендә генә өч хәрби округка бүленүен исәпкә алсак, энциклопедия авторларының хаклы булуларын танымый чараң юк. 1935 елдан хәрби разведкада хезмәт иткән якташыбызга 1936 елда – капитан, 1939 елда – майор, 1942 елдан – подполковник һәм 1943 елның 15 декабреннән полковник званиеләре бирелә. Генштабның Югары махсус мәктәбен тәмамлагач, 1942 елның июненнән майор Галимов Урта Азия хәрби округы штабының Разведка бүлеге башлыгы урынбасары, шул елның сентябреннән, инде подполковник званиесендә 3 нче Резерв армиясенең Разведка идарәсе башлыгы булып хезмәт итә. 1943 елның гыйнварыннан Брянск, Үзәк, 2 нче Украина һәм 1 нче Белоруссия фронтлары составында сугыш хәрәкәтләрендә катнашкан 2 нче танк армиясенең штаб башлыгы урынбасары – Разведка идарәсе башлыгы. 1944 елның ноябрь аенда полковник Әшрәф Галимов тагын бер Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә һәм Урта Азия хәрби округы штабы Разведка идарәсе башлыгының агентура разведкасы буенча урынбасары итеп үрләтелә. 1945 елның июлендә Урта Азия хәрби округы таратыла һәм аның гаскәрләре Төркестан һәм Дала хәрби округларына күчерелә. ГРУ полковнигы Әшрәф Галимов Төркестан хәрби округында шул ук вазыйфасын башкаруын дәвам итә. 1947 елның маеннан – Генштабның Баш разведка идарәсендә, 1948 елның соңгы аеннан – запаста.

Безнең иң үткен һәм иң көчле корал

Әлфия Шамова

Еллар үтәр, тарихчылар безнең газетабызның саргайган битләрен дулкынланып актарыр һәм хәрби корреспондентларыбызның иң кечкенә генә хәбәрләрен укып та:

– Нинди изге, нинди бөек эш эшләгәннәр! – дип, аларның исемнәрен бик зур хөрмәт белән телгә алыр.

Афзал Шамов

1942 елның 10 июленнән татар телендә фронт газеталары чыга башлый. Татар язучылары һәм журналистлары шул газеталарда әдәби хезмәткәр-тәрҗемәче, хәрби корреспондент-оештыручы, иң кимендә корректор буларак хезмәт итә. Милли телләрдә фронтларда барлыгы 64 исемдә газета басыла, аларның 16сы татар телендә чыга.

Фронт газеталары берничә телдә чыкса да, аларның барысында да рус газетасының редакторы җаваплы мөхәррир булып санала, ә милли газетаның башлыгы – җаваплы мөхәррир урынбасары итеп хисаплана. Штат расписаниесе буенча, татар газеталарын-

Төньяк-Көнбатыш фронт. «Ватан өчен» газетасы хезмәткәрләре. Сулдан уңга: Нәфикъ Яһүдин, Габдулла Әхмәдиев, Хатип Госман, Гани Гыйльманов, Мирсәй Әмир, Шәрәф Мөдәррис. 1943 ел, апрель

Немец оккупантларына үлем!

ВАТАН ӨЧЕН

ТӨНЬЯК-КӨНБАТЫШ ФРОНТЫ КЫЗЫЛАРМЕЕЦЛАР ГАЗЕТАСЫ

№ 16 (66) | 19 февраль 1943 ел. Җомга. | «За Родину» на татарском языке

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ XXV ЕЛЛЫГЫН ДОШМАНГА ҖИМЕРГЕЧ УДАРЛАР БИРЕП КАРШЫЛЫЙК!

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР ХАРЬКОВНЫ АЛДЫЛАР

16 февральдә безнең гаскәрләр, соңгы табә бик каты урам сугышларына күчкән хәл иткеч штурмнан соң, Харьков шәһәрен алдылар.

Харьков өчен сугышларда безнең гаскәрләр «Адольф Гитлер» һәм «Райх» исемле ике танк дивизиясе составындагы немец «СС» корпусын һәм «Бөек Германия» мотодивизияләрен, шулай ук байтак немец пехота дивизияләрен һәм махсус гаскәри бүлекләрен тар-мар иттеләр.

Харьковны азат итү һәм бу районда дошманны тар-мар итү операциясе генерал-полковник иптәш Голиков Ф. И. командалыгындагы гаскәри төркемнәренең көчләре белән эшкә ашырылды.

Харьков өчен сугышларда генерал-лейтенант иптәш Москаленко К. С., генерал-лейтенант иптәш Рыбалко П. С., генерал-лейтенант иптәш Казаков М. И. һәм генерал-майор иптәш Соколов С. В. берләшмәләре үзләрен аеруча күрсәттеләр.

Харьковка, беренче буларак, генерал-майор иптәш Зайцев Г. М., полковник иптәш Костицын А. С., генерал-майор иптәш Мартиросян С. С. гаскәри бүлекләре бәреп керделәр.

СОВИНФОРМБЮРО.

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР СЛАВЯНСК, РОВЕНЬКИ, СВЕРДЛОВСК, БОГОДУХОВ, ЗМИЕВ, ГРАЙВОРОН ШӘҺӘРЛӘРЕН

«Ватан өчен». 1943 ел, 19 февраль (№16)

Фронтыбызның иң батыр сугышчыларына — Советлар Союзы Геройларына — мактау һәм дан!

Немец оккупантларына үлем!

ВАТАН ӨЧЕН

ТӨНЬЯК-КӨНБАТЫШ ФРОНТЫ КЫЗЫЛАРМЕЕЦЛАР ГАЗЕТАСЫ

№ 5 | 24 июль 1942 ел. Җомга. | «За Родину» на татарском языке

Советлар Союзы Герое өлкән лейтенант Д. В. Майский

Советлар Союзы Герое өлкән сержант Ф. К. Чегодаев

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ НАЧАЛЬНИКЛЫК ИТҮЧЕ СОСТАВЫНА СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ ИСЕМНӘРЕН БИРҮ ТУРЫНДА

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫНЫҢ УКАЗЫ

Немец басып алучыларына каршы көрәш фронтында Командованиенең сугышчан заданиеларын үрнәкле итеп үтәгән һәм шул вакытта батыр йөрәклелек һәм геройлык күрсәткән өчен Ленин ордены һәм „Алтын Йолдыз“ медале тапшыру белән Советлар Союзы Герое исемен бирергә:

1. Өлкән лейтенант Беликов Петр Васильевичка.
2. Өлкән лейтенант Бойко Григорий Евдокимовичка.
3. Мичман Васильев Сергей Николаевичка.
4. Кече лейтенант Вилхелмс Янис Индриковичка.
5. Өлкән лейтенант Дехтяренко Андрей Николаевичка.
6. Майор Дзюба Иван Михайловичка.
7. Өлкән лейтенант Майский Дмитрий Васильевичка.
8. Өлкән лейтенант Марютин Петр Матвеевичка.
9. Лейтенант Носов Александр Андреевичка.
10. Капитан Орлов Федот Никитичка.
11. Өлкән лейтенант Плашкин Борис Иосифовичка.
12. Өлкән лейтенант Погорелов Василий Парфировичка.
13. Капитан Романенко Василий Сергеевичка.
14. Өлкән сержант Рябошапка Василий Яковлевичка.
15. Өлкән лейтенант Стружкин Иван Васильевичка.
16. Кече лейтенант Устюжанин Яков Марковичка.
17. Батальонный комиссар Чаплахов Лазарь Сергеевичка.
18. Өлкән сержант Чегодаев Федор Кузьмичка.

СССР Верховный Советы Президиумы председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы секретаре А. ГОРКИН.
Москва, Кремль. 21 июль 1942 ел.

УНСИГЕЗ ГЕРОЙ

БЕЗНЕҢ ФРОНТТА

ДОШМАННЫҢ ЗУР ЮГАЛТУЛАРЫ

ЧИСТЯКОВ БУЛӘКЛӘНДЕ

БЕЗНЕҢ БАТЫРЛАР

Фашистлар өере өстенә
Ут-яшен килә;
Качарга маташа өер
Ава-сөртенә.
Ләкин соң: менә аларны
Бомба каезлый.
Кем кыйный аларны шулай?
—Безнең Майский!
Безнең изге җиргә кереп,
Үрмәли җылан.
Эчкәрәк үтәргә теләп,
Ул кора план.
Ләкин аның маңгаена
Пуля кадала.
Кемгә рәхмәт моның өчен?

Федор агага!
Иркен йөрермен димәсен
Дошман тылларда!
Аңарга шулай ук үлем
Тылда юлларда.
Дошман канннан кызара
Тылда шоссеслар...
Кем эше? Моның да батыры
Устюжанин бар!
Бу безнең халык үстергән
Гайрәтле уллар.
Бөек дан, мактау казанган
Безнең геройлар.

Х. ГОСМАН.

СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЙЛАРЫ

Капитан В. С. Романенко | Өлкән лейтенант П. В. Беликов | Өлкән лейтенант В. П. Погорелов

«Ватан өчен». 1942 ел, 24 июль (№ 5)

да, мөхәррирдән тыш, әдәби хезмәткәр-тәрҗемәче, хәрби корреспондент-оештыручы һәм корректор эшли. 1944 елдан башлап, штатка тагын бер хәрби корреспондент-оештыручы өстәлә.

Хәрби корреспондент – фронт газетасының төп фигурасы, ул редакциядән алгы сафка командировкага бер айга, иң кимендә ике атнага барып йөри. Бөек Ватан сугышының ТАРИХИ ЕЛЪЯЗМАСЫН нәкъ менә шул корреспондентлар яза: дошманга каршы автомат һәм каләм тотып, оборона вакытында да, һөҗүм вакытында да, хәрәкәттәге армия белән бергә сугышлар барган җирдә дошман уты астында фронтның бер очыннан икенче очына һәркөнне чабып, окоптан-окопка шуышып, дошман оборонасын беренче булып өзүче, аңа беренче ударларны ясаучы батырларны күреп, алар белән турыдан-туры таныша, сөйләшә һәм әле генә булып үткән вакыйгалар турында газетаның киләсе саннары өчен яңа хәбәрләр, репортажлар, очерк язарлык материаллар алып кайта. Аның ялкынлы иҗаты ут эчендә туа: күпчелек әсәрләре җилле-яңгырлы окопларда, дошман уты астында языла: сугыш кырыннан хәрби телеграф яисә хәрби телефон буенча якташларыбыз турында газетага кечкенә генә хәбәрләр, сугыш эпизодлары турында хәрби язмалар җибәрә. Ә редакциягә кайткач, төннәрен сукыр лампа яктысында очерк, мәкалә яки шигырьләр яза. Бу язмаларда ул курку белмәс якташларының һәм батыр

сугышчыларның исемнәрен мәңгеләштерә. Әлеге язмалар һәм әсәрләр, газета аркылы фронтның бөтен почмакларына ирешеп, сугышчыларны канатландыра, аларны яңадан-яңа батырлыкларга этәрә.

Кайнар көннәрдә хәрби корреспондентка сугышчы да, оештыручы да, кирәк икән, командир да булып китәргә туры килә. Каләм урынына кулына пистолет яисә автомат алып, ул дошман траншеясына бәреп керә, үлем белән күзгә-күз очраша... Солдатлар белән бергә хәрби тормышның бөтен авырлыкларын кичерә, фронт хәлләрен, чынбарлыкны бозмыйча, сугышчыларга җиткерә, сугыштагы төп авырлыкның гади солдат җилкәсенә төшүен сурәтли, аларның фронттагы уйхисләрен, омтылышларын, рухи дөньясын ачып сала.

Татар телендә беренче газета Төньяк-Көнбатыш фронтта **«Ватан өчен»** исеме белән атнага ике тапкыр дүрт битле булып басыла. Аның җаваплы мөхәррир урынбасары – өлкән батальон комиссары Гани Гыйльманов (күп еллар буе Казанда «Кызылармеец» газетасында эшләгән тәҗрибәле хәрби журналист), әдәби хезмәткәр-тәрҗемәче – кече политрук Хатип Госман, хәрби корреспондент-оештыручы – журналист Габдулла Әхмәдиев, корректор – сержант Нәфыйк Яһүдин (сугыш алдыннан Олы Әтнәдә РОНО инспекторы булган) һәм хәреф җыючы Федора. Газетаның бөтен хуҗалыгы тимер юл эшелонынннан тора. Шул эшелонда барысы да бар: редакция, хәреф җыю, линотип вагоны, цинкография, ротация, электростанция һәм радиостанция.

Редакция данлы юл үтә: Старая Русса – Валдай – Житомир. Газета 1944 елның 8 апреленә кадәр чыгып килә. Барлыгы 164 сан дөнья күрә. Аның һәр саны, андагы хәбәрләр, очерклар һәм әдәби әсәрләр, фельетоннар – барсы да ул чордагы сугыш хәлләрен, сугышчыларның тормышларын ачык итеп күз алдына китерә. Безнең өчен, әлбәттә, татар сугышчылары турындагы язмалар кызыклы.

1942 ел, 21 июль. «Мифтахетдинов юл ачты» исемле хәбәрдән бер өзек: «Дошман каты каршылык күрсәтә. Бер урында ул, тоташ ут стенасы ясап, безнең сугышчыларның юлын кисәргә теләгән иде. Барып чыкмады. Безнең фронттагы сугышчылар арасында атаклы булган батыр пулемётчы Мөбарәк Мифтахетдинов, үрмәләп алга узды да, дошманның ут нокталарын бер-бер артлы басты. Хәтта яралану да батыр татар халкы улының рухын сындыра алмады. Мифтахетдинов юл ачты, дошманның каршылыгы сындырылды. Безнең сугышчылар алга киттеләр».

«Ике көн бер участокта гына немецлар 2500 солдат һәм офицерларын югалтты», – дигән хәбәр дә сугышчыларда яңа көч уяткандыр.

1942 ел, 24 июль. «Совет самолётларының Кёнигсбергка налётлары» дигән язмага күз салыйк: «Безнең самолётларның зур группасы катлаулы метеорологик шартларда Көнчыгыш Пруссиядә Кёнигсберг шәһәренең сугыш һәм промышленность объектларын бомбалады. Нәтиҗәдә, шәһәрдә 38 янгын учагы барлыкка килде, шулардан 17 янгын – шәһәр уртасында, боларның 2се – зур күләмдә... Безнең самолётларның барысы да үз базаларына кайтты».

Гомәр Разин (язучы Гомәр Бәшировның шул вакыттагы әдәби тәхәллүсе) партиянең Өлкә комитеты командировкасы белән бу газетага ике айлык командировкага 1942 елның 25 августында килә һәм редакциянең эшен җайга салуда булыша, татар солдатларының батырлыклары турында очерклар яза, фронт тормышыннан бай материал җыя. Аның газета битләрендә басылып чыккан әсәрләре түбәндәгедән гыйбарәт: «Пулемётчының сугышчан көннәре», «Сугышта чыныккан йөрәк» (автордаш Х.Госман), «Комиссар Шәйхулла Чанбарисов», «Гармоньчы егет», «Бер көнне шулай...», «Сержант Хәйруллин» исемле очерклар, «Черки», «Үлемсез мәхәббәт» дигән хикәяләр.

Кызыл сугышчы Шәрәф Мөдәррис 1942 елның сентябреннән фронтның алгы сызыгыннан газета редакциясенә чакыртыла һәм штаттан тыш шагыйрь буларак (каравыл командасы исәбеннән) хезмәт итә. Ул үзенең ялкынлы шигырьләрен – «Коткар эти», «Атака алдыннан», «Идел өчен», «Минем антым», «Таныш куак», «Туган халык», «Корыч каска», «Гөлбәдәр», «Киңҗәбулат», «Землянкада», «Севастополь», «Азат Ельня!», «Тантана», «Смоленщина»; «Идел-Сылу» нәсерен, «Командир» һәм «Тупчы Ваһап» дигән фронт поэмаларын иҗат итә, аларда Ватан сугышы героикасын, солдатлар тормышын тирән яктыртуга ирешә.

Хатип Госман да көрәшкә рухландыргыч шигырьләр, хикәяләр, очерклар яза. Аның «Безнең батырлар», «Сакта», «Корыч ташкыны», «Элемтәче Ильяс», «Синең бурычың», «Фронт кызы» һәм башка шигырьләрен солдатлар яратып укый. Әдипнең окопта язган хикәяләре, очерклары халыклар дуслыгы идеясе һәм тирән патриотизм хисе белән сугарылган. «Халкыбызның батыр уллары кебек сугышыгыз», «Кеше ашаучылар» кебек хикәяләре, разведчик Заян Хәкимов турындагы «Сугышта чыныккан йөрәк», снайпер Насыйр Юнысовка багышланган «Һәр тамчы кан өчен», «Өлкән кардәшебез»,«Пулемётчы Альбеков», «Яуда танылган егет», «Карт солдат», «Ярсу», «Революция сакчысы», «Гарасат уллары» һ.б. очерклары – әнә шундыйлардан.

1943 ел, 5 январь. И.В.Сталинның телеграммасы басыла:

«Казан. ВКП(б) Татарстан Өлкә комитеты секретаре Колыбановка, ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Динмөхәммәтевкә, ТАССР Совнаркомы Председателе Гафиятуллинга:

«Татарстан колхозчысы» танклар колоннасы төзүгә 100 миллион сум җыйган Автономияле Татарстан Совет Социалистик Республикасының колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына минем туганнарча сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз. И.Сталин».

1943 ел, 16 февраль. Хатип Госманның: «Канатлы батыр» (Капитан Хәсән Минһаҗ улы Ибәтуллин Ватан сугышының ел ярымы эчендә 278 сугышчан очыш ясады. Ялгызы дошманның 8 самолётын, ә иптәшләре белән бергәләп, тагын 3 самолётын бәреп төшерде. Ул, немец-фашист басып алучыларга каршы сугышларда күрсәткән зур батырлыклар өчен, Ленин ордены һәм Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнде)», – дигән очерк басыла.

Язучы Мирсәй Әмир дә бу газета редакциясендә 1943 елның 12 февраленнән 14 апреленә кадәр командировкада була. Ул солдатларның сугыш кырындагы батырлыкларын, тормышка, туган җиргә мәхәббәт хисләрен тасвирлаган «Дошман көтмәгәнчә...», «Агитатор», «Һава батыры», «Коттыбай батыр», «Сыерчык», «Партиянең тугрылыклы улы» исемле очеркларын, «Курай» исемле хикәясен, «Әйдә, шулай булсын!» дигән фельетонын, «Үлемгә бирмәс ул», «Күмәкләшкән – яу кайтарган» дигән хәбәрләр бастыра.

1943 ел, 19 февраль. Совинформбюро сводкасыннан: «16 февральдә безнең гаскәрләр, соңга таба бик каты урам сугышларына күчкән хәлиткеч штурмнан соң, Харьков шәһәрен алды. Харьков өчен сугышларда безнең гаскәрләр «Адольф Гитлер» һәм «Рейх» исемле ике танк дивизиясе кергән «СС» корпусын һәм «Бөек Германия» мотодивизияләрен, шулай ук байтак немец пехота дивизияләрен һәм махсус гаскәри бүлекләрен тар-мар итте».

Шул ук санда Ш.Мөдәрриснең «Армия, алга!» исемле шигыре басыла. Аннан бер өзек:

«Үт син, минут, килер заманнарга
Сөйли-сөйли Ватан кодрәтен!
Үт син, минут, үлмәс каһарманга
Биреп китеп еллар шөһрәтен!

Үт син алга, сугыш мәйданыбыз!
Дөнья йөзен таңга калдырып!
Үт син алга, кызыл байрагыбыз!
Сталиныбыз данын балкытып!

Үт син, фронт, басып, кырып, сытып,
Немец, румын, венгр бандасын!
Үт син, фронт – горур кызыл сызык!
Арчый-арчый илнең картасын!»

Шагыйрьнең «Татарстан чәчәкләре» (шинель кигән совет кызлары турында) исемле очеркы да басыла. Алар Н. гаскәри берләшмәсенең аерым элемтә бүлегендә телефончылар булып хезмәт итәләр: Сәлимә Гыйлаҗетдинова (Әгәрҗе р-ны), Сәрия Низамова (Чүпрәле р-ны), Анастасья Архипова (Чепья р-ны), Фатыйма Таймасова (Башкортстан).

Аның бу газета битләрендә «Онытылмас хәлләр», «Атнагуловлар токымы мәргәне», «Очкыннар», «Безнең Маһирә», «Баһадир егетләр», «Егерме өч ай сугышта», «Мылтык тавышы», «Син шулай чыныктың», «Үч алучы кыз», «Скрипка моңы», «Юлбашчы сүзләре», «Әлмәт егете» исемле очерклары; «Ул үч алыр», «Татарстан чәчәкләре», «Зур һәм данлы юл», «Ватан» дигән мәкаләләре дә басыла.

1943 ел, 29 август. «Яшен» исемле очеркта Ватанның батыр сугышчысы, гайрәтле совет командиры, яшь офицер Ногман Әхмәдиев хакында Шәрәф Мөдәррис болай яза: «Немецлар барлыгы 24 кеше иде. Алдан алты кешелек баш дозор килә иде... Әхмәдиев, юлбарыс шикелле сикереп чыгып, 5 немецның берсен үтереп, 4есен бәйләп алды. Бу вакыт калган сугышчылар арттан килүче дошман өстенә ут ачты һәм 18 немецның юлын юк итте... Ләкин икенче яктан тагын 11 немец килеп чыга. Әхмәдиев үзе бер пулемёт янына ята, юлның икенче ягына тагын бер пулемёт куя. Ике яктан пулемёт тыкылдарга тотынды. Күз ачып йомганчы, 11 немец юк булды.

Ногман Әхмәдиев, 8 пленный һәм үтерелгән фрицларның документларын, коралларын алып, бер генә кешесен дә югалтмыйча, үзенең гаскәри бүлегенә кайтып керде».

1944, 8 апрель. И.В.Сталин Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы Председателе иптәш С.Шәрәфиевкә, ВКП(б)ның Татарстан Өлкә Комитеты Секретаре иптәш В.Никитинга:

«Кызыл Татарстан» танклар колоннасын төзү өчен 62000000 сум акча җыйган Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының хезмәт ияләренә – минем туганлык сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз. И.Сталин».

Х.Госманның «Үч алучылар», Ш.Мөдәрриснең «Комсомолец» исемле мәкаләләре, Ф.Кәримнең «Үлем уены» поэмасыннан өзек һәм П.Сотниковның «Фронтовик шагыйрь Фатих Кәрим сугышчылар белән әңгәмә уздыра» дип аталган фоторепортажы дөнья күрә.

Бу газета битләрендә Әхмәт Ерикәйнең Советлар Союзы Герое Салават Кәримов турындагы «Баһадир» исемле очергы, юстиция өлкән лейтенанты Мостафа Ногманның «Син кайтканда», «Мин – Казаннан», «Таныш булмаган дуска», коман-

Ф.Кәрим сугышчылар белән. 1944 ел, 8 апрель (№164)

дир-зенитчы Нур Гайсинның «Син карт инде, диләр...», «Кызгану юк дошманга», «Без кайтырбыз тиздән», Әхмәт Юнысның «Колхозчылар анты», Кави Нәҗминең «Очучылар җыры», Фатих Кәримнең «Шомырт куагы», Гадел Кутуйның «Ышаныч», Нури Арсланның «Мәхәббәт хаты» дигән патриотик шигырьләре, Идрис Туктарның «Ягымлы сүзләр» исемле хикәясе, Ш.Мөдәрриснең «Шәрәфи һәм Гәрәфи язмалары» басыла. Ш.Мөдәрриснең тагын «Дон буенда», «Сабан туенда», «Әсир иткеч хәл», «Тәре походы» үтте», «Буран», «Берлинда», «Әпипә», «Нәкъ өсте», «Лорд Һауһау» микрофон алдында», «Гитлер һәм агач аяк», «Бу арада Туниста»; «Чебен», «Кызыклы картина», «Геббельска», «Күләгәдән дә курка», «Кёльн мәктәбендә дәрес»; М.Җиргәннең (М.Әмир тәхәллүсе) «Табышмак әйтәм, тап!», «Фриц – фриц сүзеннән чыкмый», «Кем нәрсә күтәрә?», «Урманда»; «Чаянчы»ның «Немецча бишек җыры», «Тотса Мәскәү якаң» язмалары (юмор) да дөнья күрә.

Ногман Әхмәдиев. «Ватан өчен». 1943 ел, 29 август

Дәвамы бар ■

«Курай сызып, гөслә, дутар чыңгылдатып... »

Эльмира Каюмова

Шагыйрь булган бабаларым, чәчән булган,
Шагыйрь җаны аларда хөр, исән булган,
Курай сызып, гөслә, дутар чыңгылдатып,
Алар җирне чиктән-чиккә гизәр булган...

С.Гәрәева. «Шагыйрь халык»

«Түгәрәк уен» фестивалендә музыка кораллары

«Түгәрәк уен» татар фольклоры фестивале. Музыка уен кораллары мәйданчыгы. «Көмеш телле гармун» төркеме. Татарстан, Әгерҗе районы.

Казан Кремле. 2017 ел, 5 август

Татарстан Республикасының традицион мәдәниятне үстерү үзәге татар халкының милли мирасын өйрәнү, саклау һәм яңарту өлкәсендә күпкырлы эш алып бара. Шуларның берсе – музыка коралларын һәм аларда уйнау традицияләрен торгызу. Бу тармак буенча экспедиция, конференция, түгәрәк өстәл, семинар, фестиваль, ярыш, күргәзмәләр оештырыла, китаплар, компакт-дисклар чыгарыла.

«Ләйсән» фольклор ансамбле.
Чиләбе өлкәсе,
Арыслан авылы

2017 елның август аенда Казан Кирмәнендә гөрләп узган «Түгәрәк уен» фестивалендә дә этник уен коралларына аерым мәйданчык багышланган иде. Әлеге чараның оештыручысы һәм алып баручысы буларак, тәэсирләрем, уй-фикерләрем белән уртаклашасым килә.

Башка еллардан аермалы буларак, быел үткәрү тәртибе икенчерәк иде. Бәйгеләр һәм йомгаклау концерты урынына төрле мәйданчыклар (җыр, бию, йола, уен, такмак әйтеш) һәм остаханәләр эшләп килде. Гади концерт форматыннан махсус читләшеп, без фестивальне интерактив рәвешендә уздырырга тырыштык.

Уен кораллары аланы, сан буенча иң беренче булып, Кремльгә керүгә үк урнаштырылган иде. Биредә гармун, курай, тимер кубыз, кыл-кубыз, гөслә, ятаган, думбыра, мандолина, кабал (бубен), давыл (барабан) һ.б. күреп ишетергә мөмкин иде. Билгеле ки, көнкүрештә файдаланылган әйберләрдән дә көй-тавыш чыгарганнар. Шуңа күрә музыка кораллары рәтендә: кырлы бәләк (сырлы бәләк, дип тә йөртәләр), кыскыч, пычкы, шакылдавык, самавыр торбасы яңгыравына бер дә гаҗәпләнәсе түгел.

Татарстанның Әтнә, Әгерҗе, Бөгелмә, Буа, Саба, Сарман, Ютазы якларыннан һәм башкалабыз Казаннан килгән башкаручылар үзләренең осталыкларын күрсәттеләр. Әстерхан, Оренбург, Төмән, Чиләбе өлкәсе; Башкортстан, Мари Иле һәм Удмуртия Республикаларыннан вәкилләр җирле фольклор байлыкларын тамашачы игътибарына тәкъдим иттеләр. Шулай ук Кырым Республикасыннан тугандаш кырым татарлары да чыгыш ясады.

Халык агылды: Бөтендөнья татар конгрессының VI корылтае делегатлары, туристлар, казанлылар, телевидение, журналистлар... Өч сәгать вакыт эчендә моңлы һәм дәртле көйләрне ишетеп, уен кораллары турында кыскача, ләкин файдалы мәгълүмат алып, башкаручылар белән танышып, аралашырга мөмкинчелек тудырылды.

Фестивальгә әзерләнгән чагында күңелне тырный торган мәсьәләләр кабат ачыкланды. Фольклор төркемнәр һәм ялгыз башкаручылар эшчәнлегендә музыка кораллары кытлыгы зур киртә булып тора. Мисал өчен, Татарстанда аларны ясаучы осталар бармак белән генә санарлык. Күрше Башкортстан Республикасы бу юнәлештә күпкә алга киткән. Уенчылар арасында балалар һәм яшьләрнең шактый булуы гына күңелне бераз тынычландырып, традицион инструменталь сәнгатьнең киләчәгенә өмет уята.

Камилә Каюмова фотолары. ■

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

ТИМЕРЛӘНГ МАНАРАСЫ — Чиләбе өлкәсендәге мәшһүр манара. Бу манара турындагы риваятьтә Туктамыш хан улы белән Аксак Тимер кызының аталарыннан качып китүе тасвир ителә. Аксак Тимер кешеләре аларның артыннан барып, хәзерге Тимерләнг станциясе тирәсендә куып җитәләр. Егет сугышта һәлак була, кыз исә үз-үзенә хәнҗәр белән кадый. Шул урынга Аксак Тимер манара салдырган имеш. Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастанында Сөһәйл исемле бер егетнең Аксак Тимергә әсир төшүе һәм шаһ кызы Гөлдерсеннең аңа гашыйк булып, егетне зинданнан коткаруы хикәя ителә. Алар качып китәләр, ләкин сахрада адашып, Гөлдерсен сусызлыктан һәм ачлыктан үлә, ә Сөһәйл үзен-үзе чәнчеп үтерә. Ихтимал, Сәйф Сараи дастанын язганда халыкта йөргән әлеге риваятьтән файдаланган булгандыр. Шуны да әйтик, «Идегәй» дастанының кайбер вариантларында Аксак Тимер кызының бер алып (пәһлеван) тарафыннан урлануы турында әйтелә. Туктамыш яныннан качкан Идегәй бу алыпны үтереп, кызын үзенә хатынлыкка ала. Ләкин бу риваятьләрнең тарихи нигезен ачыклыйсы бар.

Э.Ю.Петри үткәргән археологик казу эшләрендә манара төбенә хатын-кыз күмелгәнлеге билгеле булды. ■

Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

Безнең мирас №9 сентябрь 2017

Тәрбияле кеше туган телен бозмый

Рүзәл Юсупов,
академик

Матбугатта, радио-телевидениедә телебезне бозып куллану хакында язмалар, сөйләшүләр булгалап тора. Ләкин татар теленең сафлыгы, киләчәге өчен җаваплы кешеләрдә, хакимият органнарында, моңа игътибар итеп, туган телебезнең сыйфатын тиешле дәрәҗәдә тоту өчен җитди чаралар күрү омтылышы сизелми диярлек.

Хәлбуки, телебезгә битараф караш, илтифатсызлык, аннан файдаланудагы башбаштаклык күренешләре көчәя бара. Республика күләмендә чыга торган газеталарның һәрбер санында дистәләрчә тупас тел ялгышларына тап буласың. Кайбер журналистларның төп эш кораллары булган телләренә җавапсыз, җиңел карауларына, аны начар белүләренә гаҗәпләнәсең һәм нәфрәтләнәсең. Кайчакта алар нәрсә язганнарына һәм сөйләгәннәренә төшенеп тә җитмиләр, үзләре кулланган аерым сүзләр һәм гыйбарәләрнең мәгънәләрен үзләре дә аңлап бетермиләр, ахры, дип уйлап куясың.

«СССР тарихы кафедрасында чыганакчылык гыйлеме белән махсус шөгыльләнә башлый», – дип язып чыкты шушы көннәрдә абруйлы бер газета хәбәрчесе күренекле галим М.Госманов турында. Бу җөмләдәге **чыганакчылык гыйлеме** дигән гыйбарәне нәрсә

дип аңларга тиеш газета укучы? Моны язган журналист үзе ничек аңлады икән, дөресрәге, аңладымы икән аны?! Аңлаган булса, **«…язма чыганакларны яки язма тарихи истәлекләрне өйрәнү белән шөгыльләнә башлый»**, – дип язган булыр иде ул.

«...балалар бакчаларына 1,5 млн сумнан артык чыгым тотылган», – дип укыйбыз бер газетада. Мондагы **«чыгым тоту»** рус телендәге «масло в масле» дигән әйтемне искә төшерә. **Чыгым** ул үзе – **«берәр максат өчен тотыла, сарыф ителә торган акча, мал-мөлкәт»**. Шулай булгач, **чыгым тотылган түгел, акча тотылган** дип язарга кирәк иде ләбаса!

Синоптикларның газеталарда басылган хәбәрләренә күз салыйк.

«Һава торышы якшәмбедә генә аязачак», – дип ышандырганнар. Кемнәрне ышандырганнардыр һәм ышандыра алганнардырмы, юкмы – монысы билгесез әле. Бу – бер. Икенчедән, **«һава торышы аяза»**, дип сөйләмәс чын татар кешесе, **«көн аяза»**, дияр.

«Бу көнне республикада 3,6 градус җылы һава торышы күзәтелгән». Җылылыкны, салкынлыкны күзәтеп булмый, тоясың аны. Бу җөмләне: «Республикада 3,6 градус җылы булган», – дип, чын татарча әйтергә мөмкиндер бит!

«Җылы һава торышы алдагы тәүлекләрдә дә дәвам итәчәк». Моны да, гади генә итеп, мөгез чыгармыйча: «Алдагы тәүлекләрдә дә җылы булачак», – дип әйтеп булмыймы икән соң?!

Менә бу җөмләгә игътибар итик.

«Алдагы елда бу күрсәткеч 1 миллиард сумнан артып киткән булган». Ничек аңларга икән моны: **артып киткән булган** дигән сүзләргә карагандә, күрсәткечнең артуы үткәндә булган; **алдагы** сүзеннән бу процесс киләсе елда булачак дигән мәгънә аңлашыла. Димәк, журналист **алдагы** сүзен уйлап тормыйча гына кулланган: «Узган елда... артып киткән булган», – диярга кирәк иде.

Бу җөмләдә **балаларга** сүзе дә уйламыйча кулланылган: «Быел ата-аналарның балаларга айлык түләве хакы, узган ел белән чагыштырганда, 7,4 тапкыр арткан». **Балаларга** түгел, **балалар өчен** түләү турында бара сүз һәм шулай язарга да кирәк иде.

«Тик ул да больницада яралардан һәлак була». Монда һәлак була сүзе дөрес кулланылмаган. Сугыш кырында яки бәла-казаларга эләгеп һәлак булалар, больницада исә (кайчакта) үләләр.

«Кайбер балалар бакчасында түбән сыйфатлы, хәтта черегән ашамлыкларның булуы фаш ителгән». Монда журналист **бозылган** сүзе белән **черегән** сүзләрен бутаган, күрәсең. Балаларга черегән ашамлыклар бирүләренә һич кенә дә ышанып булмый, бозылган булырга мөмкин.

Хәзерге сөйләм һәм язма телебездәге күпсанлы җитди хаталарның төп сәбәбен менә болай аңлатырга мөмкин.

Сөйләмдә сүзләрнең үзара мәгънәви бәйләнешкә керүе билгеле бер тәртип, кагыйдә буенча гамәлгә ашырыла: теләсә кайсы сүз, башка теләсә нинди сүз белән табигый бәйләнешкә кереп, тиешле конкрет мәгънә белдерә алмый. Мәсәлән, **тәмле** сүзе **бәлеш** сүзе белән бәйләнеп, бергә килеп, татар теле өчен табигый тәгъбир (сүзтезмә) тәшкил итә: **тәмле бәлеш**. Шул ук **тәмле**, **йорт** сүзе белән бәйләнешкә кереп, табигый гыйбарә (әйтелмә) төзи алмый: татарча **тәмле йорт** дип әйтеп булмый.

Газетадан бер мисал: «Йөрәк ярсып әрни, ...нәфрәт үсә». Үсү кеше, агач, хайван, кош-корт кебек төшенчәләрнең исемнәре белән табигый бәйләнешле тәгъбирләр тәшкил итә. Әмма предмет исемнәре һәм абстракт исемнәр белән табигый бәйләнешкә керми. Әлеге җөмләдә дә **нәфрәт үс**ә түгел, бәлки **нәфрәт көчәя, арта,ташый** һ.б.ш. булырга тиеш.

Күп каләм ияләре телнең шушы иң әһәмиятле кагыйдәләренең берсен – сүзләрнең үзара табигый бәйләнешкә

керү тәртибен (нормаларын) белмиләр: еш кына кайсыдыр сүзләрдән ниндидер бер гыйбарә төзиләр. Һәм бу әйтелмә, татар телендәге сүзләрнең табигый бәйләнешен исәпкә алмыйча төзелгәнлектән, туган телебезнең хосусиятен бозуга, аның тотрыклы грамматик төзелешен какшатуга, җимерүгә өлеш кертә.

Сөйләмдә, язма текстта сүзләрнең табигый мәгънәви бәйләнешен бозу күбесенчә русчадан тәрҗемә итү, дөресрәге, ялгыш тәрҗемә итү аркасында килеп чыга.

Тәрҗемә итүдәге иң күп таралган ялгышларның нигезендә исә бер телдәге (чыганак телдәге – оригиналдагы) сүзне икенче телгә (тәрҗемә теленә) сүзгә-сүз, хәрефкә-хәреф күчерү ысулы белән эш итү ята. Бу ысул үзе шуннан гыйбарәт: тәрҗемәче тәрҗемә телендә оригиналның һәр сүзенә аерым сүздән торган тәңгәллек табарга тырыша. Хәлбуки, төрле телләрдә сүзләр саны бертөрле булмаганлыктан һәм сүзләр гомумән алганда һәр телдә дә күп мәгънәле булганлыктан, тәрҗемә иткәндә оригиналның һәр аерым сүзенә тәрҗемә теленең аерым сүзеннән торган тәңгәллек табу мөмкин булмый: еш кына оригиналның аерым бер сүзен тәрҗемә телендә берничә сүз белән дә белдерергә һәм, киресенчә, оригиналның берничә сүзен тәрҗемә телендә бер сүз белән генә дә белдерергә туры килә. Кайчакта исә тәрҗемә телендә оригиналның теге яки бу аерым сүзе үзе генә чагылыш та тапмый.

Тәрҗемә процессында ике тел сүзләре арасында тәңгәллекләр табып куйганда, күп тәрҗемәчеләр тарафыннан җибәрелә торган иң зур ялгыш шул: тәрҗемә телендә оригинал сүзенә тәңгәллек аның сөйләмнән, тексттан аңлашылган мәгънәсенә карап түгел, бәлки күбесенчә сүзлекләрдә теркәлгән һәм иң күп кулланыла торган төп мәгънәсенә нигезләнеп билгеләп куела. Һәм шуның аркасында сүзләрнең үзара табигый мәгънәви бәйләнешкә керү тәртибе (нормалары) бозыла һәм, шулай итеп, туган телнең хосусиятенә, төзелешенә җитди зыян килә.

Бу күренешне мисаллар ярдәмендә аңлату хәерле булыр.

Хәзер мәгълүмат чаралары (матбугат, радио-телевидение) телендә «Мин иртәгә Мәскәүгә очам», «Президент Кырымга очты» рәвешендә язу һәм сөйләү гадәткә керде. Бу, әлбәттә, телебезнең табигый сөйләм кагыйдәләрен тупас бозуның гыйбрәтле бер мисалы. Мондый гарип әйтелмә-тәгъбирләр телебездә тәрҗемә итә белмәү, тәгаенрәк итеп әйткәндә, татар телендә рус сүзләренә тәңгәллекләрне ялгыш билгеләп кую аркасында барлыкка килә.

Журналист, «Он полетел в Москву» җөмләсен тәрҗемә иткәндә, **лететь** сүзен татарчага аның кошларга, очу аппаратларына карата кулланыла торган төп мәгънәсендәге тәңгәллеге **очу** сүзе белән күчерә. Әмма рус телендәге **лететь** сүзенең мәгънәләре татарчадагы **очу**ның мәгънәләреннән күбрәк булуын һәм рус телендә **лететь** сүзенең кешеләргә карата да кулланыла алуын, чын татарча сөйләгәндә исә **очу** сүзен кешегә карата кулланып булмавын исеннән чыгара яки белми. **Лететь** сүзенең мәгънәләрен татар телендә барлык очракларда да **очу** сүзе белән белдерү мөмкин түгел. Чөнки татар һәм рус телләре – төрле төзелешле, үзенчәлекле телләр, аларның һәркайсы чынбарлыкны үзенчә чагылдыра.

Рус телендә кешенең кая таба һәм нәрсә ярдәмендә хәрәкәт итүе, йөрүе бер төрле, татар телендә исә – икенче төрле чаралар белән белдерелә. Русча җәяү бару **идти**, атка, машинага, поездга утырып бару – **ехать**, самолетка утырып бару – **лететь**, су транспортына утырып бару – **плыть** сүзләре белән белдерелә. Татар телендә кешенең хәрәкәт итүе, ни рәвешле һәм нинди чара ярдәмендә белдерелүенә карамастан, гомумән

генә – **бару**, **кайту**, **килү**, **китү** сүзләре белән белдерелә, нинди чара ярдәмендә икәнлекне аерып күрсәтергә кирәк булганда, тиешле транспорт чарасының исеме өстәлә: җәяү бару (кайту, килү, китү), автобус белән бару (автобуска утырып бару һ.б.), самолет белән бару һ.б.

Шулай булгач, русча **я полечу** (кудато), **он полетел** дигәнне татарча мин очам (кая да булса), **ул очты**, дип әйтеп булмый (бу телне тупас бозу була), бәлки **мин барам** (самолет белән, поезд белән һ.б.), **ул китте**, дип әйтелә.

Ике тел белән эш итүчеләр, шул исәптән тәрҗемә эше белән шөгыльләнүчеләр өчен төрле телләрнең мондый үзенчәлекләрен белү һәм эш процессында исәпкә алу – беренче шарт. Мисал өчен әйтик: менә бу җөмләнең авторы рус һәм татар телләренең һәркайсы үзенә генә хас үзенчәлекләргә ия дигән кагыйдәне истә тотып эш итмәгән, әлбәттә: «Еш кына ерак араларга **очып**, төрле сәгать поясларындагы ритмга җайлашырга тиеш булган эшмәкәрләр...» (Дөресе – «Еш кына ерак араларга **йөреп**...»).

Менә бу мисалларда тәрҗемә иткәндә төрле телләрдәге беренче карашка (төп мәгънәләре буенча) тәңгәллек булып күренгән сүзләрнең сөйләмдә башка сүзләр белән мәгънәви (семантик) бәйләнешкә керүендәге милли үзенчәлекләре исәпкә алынмавы ачык күренә.

«Татар театрына 108 яшь» (дөресе – «Татар театрына 108 ел» яки «Татар театрының ачылуына (эшли башлавына) – 108 ел»).

«Бу көннәрдә зурдан купмый гына газетаның 95 яшьлеген бәйрәм итеп алдылар» («... газетаның 95 еллыгын бәйрәм итеп алдылар» тиеш).

Әлеге ике җөмләдә **ел** сүзе урынына ялгыш **яшь** сүзе кулланылуның сәбәбе – журналистның рус телендәге **лета (годы)** сүзенең мәгънәсе татар телендә кешеләргә һәм хайваннарга карата гына **яшь** сүзе белән тәгъбир ителүеннән, җансыз нәрсәләргә карата исә **ел** сүзе белән белдерелүеннән хәбәрдар булмавы.

«**Фатирга үткәннән соң**, җинаятьчеләр үзләрен социаль хезмәткәрләр дип таныштыра» («...кергәннән соң...» кирәк). «Ир-ат, йозакны ватып, **эчкә үткән**» (дөресе – «эчкә кергән»). (Русча – проходить внутрь, в комнату һ.б. татарча – эчкә (бүлмәгә һ.б. нәрсәләргә) керү.

Тәрҗемә белән шөгыльләнүчеләр (безнең журналистларның барысы да диярлек күп материалны русчадан тәрҗемә итеп ала) еш кына теге яки бу рус сүзенең берничә төрле мәгънәгә ия булуын һәм ул мәгънәләрнең татарча төрле сүзләр белән белдерелүен исәпкә алып бетермиләр. Нәтиҗәдә, җитди ялгышлар китә. Соңгы елларда мәгълүмат чаралары телендә еш кулланыла торган ялгыш калькалаштырылган әйтелмәләрдән **кыскарту** сүзе белән ясалган гыйбарәләрне мисал итеп күрсәтергә була. Мәктәпләрне, хезмәт хакын, эшче-хезмәткәрләрне һәм башка күп нәрсәләрне кыскарталар, дип сөйлиләр һәм язалар күп очракларда. Мәсәлән: «...акча күләме 16 миллиард сумга кыскартылган» (дөресе – «...16 миллиард сумга киметелгән»); «...чиновниклар санын кыскарту турында карар кабул ителгән» («...чиновниклар санын киметү турында карар...» кирәк). Бу сүзне куллану белән мавыгуның төп сәбәбе – русчадагы **сократить** сүзен, уйлап-нитеп тормыйча, һәр очракта да **кыскарту** дип тәрҗемә итү. Әмма бераз гына булса да уйлап эш итсәң, **сократить**ның төрле мәгънәләрен татарча төрле сүзләр белән белдерергә кирәклеген күрәсең. Русча **сократить** сүзе белән тәгъбир ителгән әйтелмәләрдә бу сүзгә татар телендә **киметү**, **ябу**, **чыгару** һәм башка сүзләр туры килә. Мәсәлән: сократить зарплату – хезмәт хакын киметү, сократить расходы – чыгымнарны киметү, сократить школы – мәктәпләрне ябу, сократить преподавателей – укытучыларны эшеннән азат итү (яки эшеннән чыгару).

Призвать (призывать) сүзенең берничә төрле мәгънәсе татар телендә **чакыру**, **өндәү**, **алу** һәм башка сүзләр белән белдерелә. Әмма хәзерге мәгълүмат чараларында һәр очракта да **чакыру** сүзе кулланыла һәм, әлбәттә, ялгыш кулланыла. Мәсәлән, армиягә чакырылды, хәрби хезмәткә чакырылды, диләр. Дөресе – армиягә алынды, хәрби хезмәткә алынды; «...Имаметдин Низамовлар да, солдат хезмәтенә чакырылып, сугыш хәрәкәтендә катнаша» («...солдат хезмәтенә алынып, сугышта катнаша» кирәк.) **Өндәү** сүзен дә, читләштереп, **чакыру** белән алыштыра: «Президент республика халкын тотрыклылыкка һәм тынычлыкны сакларга чакырды» («...тынычлыкны сакларда өндәде» татарча дөресрәк булыр иде.)

«...җаваплылык хисе аны гомере буе озата килгән». Бу җөмләдәге «җаваплылык хисе озата килгән» – русчадагы «чувство ответственности сопровождал его» фразасының сүзгә-сүз (хәрефкә-хәреф) тәрҗемәсе. Ләкин «хис озата килгән» дип әйтү татарча табигый түгел. Җөмләне бераз гына үзгәртеп төзесәң, сөйләм татарча дөрес яңгырашлы булыр иде: «...җаваплылык хисе анда гомере буе сакланып килгән».

«Президент Рөстәм Миңнеханов ...Ли Сянь Луну әфәнденең тирән кайгысын уртаклашты». Мондый эчтәлекле хәбәрләрне еш укырга туры килә. Беренче карашка, бу текстта бернинди дә китек нәрсә юктыр кебек. Ләкин мондагы һәм башка шундый текстлардагы **тирән кайгы** татарча дөрес түгел. Татарча яхшы белгән кеше **тирән кайгы** димәс, татар телендә гомумән **кайгы**, **зур кайгы**, **кара кайгы** бар. **Тирән кайгы** ул – рус теленнән ялгыш калькалаштырылып алынган гыйбарә.

Тирән сүзе менә бу җөмләдә дә дөрес кулланылмаган: «...алар носилкаларда әледән-әле **тирән** ыңгыраша (чын татарча – «...нык (яки каты) ыңгыраша»).

«Террорчылык эшчәнлегенә бәйле булган 3,5 мең банк хисаплары туңдырылган, 62 җинаять эше ачылган». Бу җөмләдәге «банк хисаплары туңдырылу»ны газета укучы ничек аңларга тиеш икән? Аны язган журналист бу турыда баш ватып тормаган: язганмы – язган, укучылар теләсә нәрсә уйласын, янәсе ! Мондагы **«банк хисаплары туңдырылган»** рус телендәге **«банковские счета заморожены»** фразасының хәрефкә-хәреф тәрҗемәседер, әлбәттә. Оригиналдагы «заморожены» күчерелмә мәгънәдә – «элеккечә, үзгәрешсез, файдаланмыйча калдыру» һ.б.ш. мәгънәдә кулланылган. Татар журналисты исә аның туры мәгънәсендәге тәңгәллегеннән файдаланган. Һәм нәтиҗә күз алдында: башваткыч килеп чыккан. Ул җөмләне болайрак итеп төзергә кирәк иде: «Террорчылык эшенә (яки террорларга) бәйле 3,5 мең банк хисаплары туктатылган...»

«Медсанбатка эләгеп, гаскәр артыннан хәрәкәтләнеп, яралыларга ярдәм күрсәтә». Бу җөмләдәге **хәрәкәтләнеп** сүзе дә – русчадан уңышсыз калька. «...гаскәр артыннан барып...» дияргә кирәк.

«Чеп-чи татар балалар бакчасында әле теле генә ачылып килә торган баланы урыс программасы белән генә укыту ата-аналарда ризасызлык уята». **Чеп-чи ялган**, **чеп-чи надан**, дип әйтү бар, әмма **«чеп-чи татар балалар бакчасы»** дип сөйләмиләр (хәер, менә журналистлар әйтә икән). Бу – сүзне урынсыз куллану. Монда **укыту** сүзе дә дөрес кулланылмаган: теле ачылып кына килгән баланы укытып булмас, сүз өйрәтү турында барадыр.

«...кыпчаклар да «уйгыр мәдәниятенең бәрәкәтле тәэсирен татыган». **Тәэсирне тату**, дип әйтү – тупас хата. Җөмләне «...кыпчаклар да уйгыр мәдәниятенең бәрәкәтле йогынтысында булган» рәвешендә төзергә кирәк иде.

«Китап милли тарихыбыз һәм мәдәниятебез белән кызыксынучы киң катлам укучыларга тәкъдим ителә». «Киң катлам укучылар» инде күп еллар

мәгълүмат чаралары телендә иркен кулланыла. Ләкин берәр кешенең башында, нинди була соң ул **киң катлам укучылар**, дигән сорау туганы бармы икән? **«Киң катлам укучы»** – ялгыш ясалган гайре табигый тәгъбир.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеген алып карыйк. **Катлам** – 1. Кат-кат булып торган нәрсәнең бер каты; 2. Күч. Социаль экономик хәлләре, дөньяга карашлары, культура дәрәҗәләре буенча бериш кешеләр. Шулай булгач, бу сүзнең (катламның) туры мәгънәсенең дә, күчерелмә мәгънәсенең дә укучыларга нинди мөнәсәбәте була ала икән соң?

Тагын бер хата: катламны киңлегетарлыгы буенча билгеләмиләр, бәлки калынлыгы-юкалыгы буенча тасвирлыйлар. Димәк, **киң катлам**, дип әйтү дә татарча дөрес түгел. Әлеге җөмләдә исә **катлам** сүзенең гомумән кирәге юк: «...мәдәниятебез белән кызыксынган укучыларга» дигәч, җиткән бит инде!

Соңгы вакытларда безнең журналистларга телебезгә, ихтыяҗ булганлыктан түгел, бәлки мода өчен, тиктомалга, кызыклык өчен генә, яңалыклар кертү белән мавыгу чире йогып бара. Шундыйлардан, мәсәлән, **яңгырау**, **яңгырату**, **җиткерү**, **тере**, **ассызыклау**, **хезмәт кую** һәм кайбер башка сүзләр белән ясалган мәгънәсез, сәер әйтелмәләрне (сүзтезмәләрне) атарга мөмкин. Мисаллар: «Киңәшмәдә яңгыраган тәкъдимнәрнең файдасы булмыйча калмас»; «...иҗтимагый советның киңәйтелгән утырышында яңгыраган төп фикер»; «...мөһим белдерү яңгырады». Бу җөмләләрдәге **яңгыраган тәкъдимнәр**, **яңгыраган фикер**, **белдерү яңгырау** тәгъбирләрендә татар теленең сүзләр бәйләнеше нормалары бозылган: татарча **тәкъдим яңгырый**, **фикер яңгырый**, **белдерү яңгырый** дип әйтеп булмый. **Тәкъдим ясала**, **фикер әйтелә** яки **белдерелә**, **белдерү ясала** яки **игълан ителә**.

«Римзил Вәлиев бу конференцияне өметле чара дип кабул итүен җиткерде». **Җиткерү** монда һич кенә дә урынлы кулланылмый. «...кабул итүен әйтте», яки «...кабул иттем, диде» яки башка шулайрак итеп әйтергә мөмкин һәм кирәк тә.

«Татарстан Республикасы Премьер-министры вазыйфасында хезмәт куйган». Мондагы «**вазыйфасында хезмәт кую**»ны – мөгез чыгару, дип кенә бәяләргә мөмкин. Чын татарча – «Премьер-министры булып эшләде», яки «Премьер-министры вазыйфаларын башкарды», яки башка шулайрак.

«...эшче яшьләр мәктәбендә урта белем алуны тәмамлый» («белем алуны тәмамлый», дип сөйләмиләр). Чын татарча – «...эшче яшьләр мәктәбендә белем ала» яки «...эшче яшьләр урта мәктәбен тәмамлый».

«М.Госманов – халыкара масштабта да танылу алган галим» (**танылу алу – получать известность**ның уңышсыз калькасы). «М.Госманов – халыкара күләмдә дә (яки дәрәҗәдә дә) мәгълүм галим» яки «М.Госмановны күренекле галим буларак чит илләрдә дә беләләр» һ.б.ш. кирәк.

«Эшлекле сыйфатлары һәм кешелеклелеге... М.Г.Сабировка зур абруй һәм танылу китерде» («...**абруй һәм танылу китерү**»не татар сүзләре белән русча язу, дип әйтергә мөмкин). Дөресе – «М.Г.Сабиров эшлекле сыйфатлары, кешелеклелеге... белән абруй һәм дан казанды».

«...гайре табигый булмаган хәлләр турында халык аеруча сөйләшергә ярата». Гайре үзе – сыйфатны инкарь итә торган кисәкчә. Димәк, яки «**гайре табигый хәлләр**...» яки «**...табигый булмаган хәлләр**» дияргә кирәк, югыйсә, мәгънә кабатлавы (тавтологиясе) килеп чыга.

«...мөселман журналистлары укытып чыгару ихтыяҗы көн тәртибенә менде» (дөресе – «...көн тәртибенә куелды (кертелде)», «...ихтыяҗы туды»).

«...башкалада транспорт белән идарә итү бик күпкә катлауланачак» («...транспорт йөртү... катлауланачак» татарча табигыйрак булыр иде).

Телебездә күпсанлы ялгышлар хөкем сөрүнең тагын бер сәбәбе – сөйләмдә сүзләрнең мәгънәви бәйләнешен гамәлгә ашыра торган грамматик чараларны дөрес куллана белмәү. Грамматик чараларны бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр, кушымчалар, сүз тәртибе, янәшә тору тәшкил итә. Бу чараларны кулланудагы ялгышлар исә шулай ук русчадан хәрефкә-хәреф тәрҗемә итү аркасында килеп чыга.

Мәсәлән, рус телендәге **работать за станком** дигән әйтелмәне сүзгә-сүз, хәрефкә-хәреф ысулы белән эш итүче тәрҗемәче «**станок артында эшләү**» дип тәрҗемә итеп куя. Әмма бу гыйбарә татарча дөрес булмый, чөнки безнең телдәге сүз бәйләнеше кайгыйдәсе (нормасы) буенча оригинал мәгънәсе **станокта эшләү** рәвешендә белдерелә. Шулай ук **бои под Москвой** чын татарча **Мәскәү астындагы сугышлар** түгел, бәлки **Мәскәү тирәсендәге (яки янындагы) сугышлар**; **играть на гармони** хәзерге мәгълүмат чараларында кулланылганча **гармунда уйнау** түгел, **гармун уйнау**.

Ләкин бүгенге журналистлар еш кына рус һәм татар телләренең бу үзенчәлекләрен исәпкә алып тормыйлар, рус телендәге сүз бәйләнеше чараларын татарчага хәрефкә-хәреф тәрҗемә итеп, телебезне гайре табигый әйтелмәләр (тәгъбирләр) белән чүпли баралар. Берничә мисал китерик.

«Илшат Әминов һәм аның урынбасарлары нәкъ шушы проблема өстендә эшли» (дөресе – «...шушы проблема белән шөгыльләнә»).

«Көнбатышта **Мәскәү астындагы** Касыйм төбәгеннән алып көнчыгышта Иркутск өлкәсенә кадәр...» **(«Мәскәү тирәсендәге** (яки янындагы) Касыйм төбәгеннән алып...» кирәк).

«...дип, шатлыгы белән уртаклашты Илдус Нәфыйков» (дөресе – «...дип, шатлыгын уртаклашты»).

«Станок артында торган, төзелештә эшләгән яһүдне очрату җәй уртасында кар табуга тиң». («Станокта, төзелештә эшләгән яһүдне очрату...» кирәк).

«Гаяз Исхакый... бөтен гомерен Идел-Урал төрки-татар дәүләтен төзү өчен багышлый» («...төрки-татар дәүләтен төзүгә багышлый» тиеш).

«...башка төрле сәер ризыкларны да авыз итәргә була» (дөресе – «...ризыклардан да авыз итәргә була»).

«Руль артындагы хатын-кызны яманламыйк» (чын татарча – машина йөртүче хатын-кызны яманламыйк).

Бүгенге көндә телдән һәм язма сөйләмебездә туган телне бозып куллану күренешләре күптөрле. Бу мәкаләдә аларның бик азы гына күрсәтелде. Насыйп булса, бу хакта язулар һәм әңгәмә корулар тагын булыр әле.

Язмабызга йомгак ясап, туган телебезнең сафлыгын, дөреслеген саклауга юнәлтелгән берничә тәкъдим мәгъкуль булыр, дип уйлыйбыз.

Дәүләтнең тиешле органнары, Мәгариф министрлыгы балаларга һәм яшьләргә татар телен өйрәтүнең, укытуның сыйфатын, нәтиҗәлелеген күтәрү мәсьәләләре белән конкрет һәм җитдирәк шөгыльләнсен, туган тел укытучыларының укучылар белеменең тиешле дәрәҗәдә булуы өчен җаваплылыгын арттырсын иде.

Казан федераль университеты җитәкчелегенә, татар журналистларын әзерләү мәсьәләләренә игътибарны көчәйтеп, булачак белгечләрнең татар телен камил белүләренә ирешү өчен, аларның җитди чаралар күрүе зарур.

Татарстан хөкүмәтенең җаваплы хезмәткәрләре, Татарстан журналистлар союзы, газета-журнал, радио-телевидение җитәкчеләре журналистлардан үзләренең төп эш коралын – туган телләрен яхшы белүләрен таләп итәргә тиеш.

Мәгълүмат чаралары теле чын татарча, әдәби дөрес, җанлы, матур тел булырга тиеш. ■

Исемнәребез – халык мирасы

Айнур Тимерханов,
филология фәннәре докторы

Кеше исемнәре, аларның мәгънәләре һәрвакыт игътибар үзәгендә тора. Исемнәр мәсьәләсен өйрәнү, булган тәҗрибәгә таянып, аны яңа фәнни юнәлешләр кысаларында тикшереп хәл итү һәрвакыт актуаль санала. Ни өчен андый исем кушканнар, ул исемнең мәгънәсе нидән гыйбарәт, аның язмышка тәэсире нинди – бу һәм башка шундыйрак сораулар, уйланулар кешелекне инде борынгы чорлардан ук кызыксындырган, борчыган. Исем ул – халык хәтере, халык мирасы, халык тамгасы. Нәсел җепләрен бәйли торган тирән мәгънәгә ия сүз дә – исем! Шунлыктан, исемгә карата игътибар беркайчан да кимемәячәк.

Тарих төпкелләрендә калган исемнәрне барлап, теркәп, аларны эзлекле фәнни яссылыкта тикшергән, шулай ук исемнәребезне үткән һәм бүгенге көн ноктасыннан якын килеп өйрәнгән фәнни хезмәтләргә ихтыяҗ үзен һәрдаим сиздереп килә. Илдәге хәзерге тотрыксыз сәяси-иҗтимагый вазгыятьтә исә андый хезмәтләрнең әһәмияте тагын да арта төшә. Кеше исемнәрен куллануны Россия күләмендә аерым бер тәртипкә салу, кеше исемнәрендә чагылыш тапкан элеккеге сәяси-идеологик ышанулардан арыну нияте белән кайбер төрки-татар чыгышлы исемнәрне дә тыюны күз уңында тоткан закон проектының тәкъдим ителүе, шул ук вакытта, әйтик, яңа туган балаларына туу турында таныклык алганда, ата-аналарның тупас, мәгънәсез исемнәр сайлау очраклары һ.б. – болар барысы да татар җәмәгатьчелеген, киң даирә галимнәрне тирән борчуга сала торган, уйланырга, проблеманы төрле яктан максатчан рәвештә фәнни нигездә тикшерергә, өйрәнергә этәрә торган гамәлләр. Бу нисбәттән, **Гүзәлия Сәйфулла кызы Хаҗиева**ның яңа гына дөнья күргән монографиясе – **«Телнең этномәдәни тирәлегендә татар кеше исемнәре»** аерым игътибарга лаек.

Китап, мәсьәләне төптән аңлап, аңа бүгенге тел гыйлеме һәм аның белән арадаш фән тармаклары югарылыгында якын килеп, ачык һәм ышандырырлык итеп, эзлекле яктыртуы белән үзенә җәлеп итеп тора. Әлеге хезмәт татарларның исем системасын күзаллауга, барлауга, тикшерүгә, шуңа бәйле рәвештә, бүгенге чорның борчулы мәсьәләләрен фәнни яссылыкта хәл итүгә юнәлдерелгән хезмәтләрнең берсе дип саналырга хаклы.

Китап авторы – Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлегендә өлкән фәнни хезмәткәр булып эшләүче Гүзәлия Хаҗиева – Казан ономастика мәктәбенә нигез салган күренекле телче, тюрколог, ономаст Гомәр Саттаров шәкертләреннән берсе.

Билгеле булганча, Г.Ф.Саттаров 1973 елда «Татарстан АССРның антропотопонимнары» дип аталган күләмле фундаменталь хезмәтен докторлык диссертациясе итеп яклый һәм шул рәвешле татар ономастикасын мөстәкыйль фән югарылыгына күтәрүгә ирешә. Алга таба галимнең татар ономастикасына багышланган күпсанлы хезмәтләре дөнья күрә, шул исәптән, «Исемең матур, кемнәр куйган?» (1989), «Татар антропонимикасы» (1990), «Татар топонимикасы» (1998) һ.б. Татар дөньясы өчен бердәнбер исемнәр сүзлегенең авторы да Г.Ф.Саттаров була. Галим – татар фәне өчен генә түгел, ә төрки фән дөньясы өчен дә ныклы алмаш булырлык кадрлар әзерләүгә зур өлеш керткән шәхес.

Гүзәлия Хаҗиеваны да, ономастика өлкәсендәге фәнни эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып, мәшһүр остазының ышанычлы дәвамчысы дип атарга тулы нигез бар. Галимәнең «Телнең этномәдәни тирәлегендә татар кеше исемнәре» дигән хезмәте тел тарихы, халык авыз иҗаты, этнография, диалектология өлкәләрендәге казанышларны исәпкә алып, шушы һәм башка фәннәр кисешендә барлыкка килгән этнос, тел, культура бәйләнеше яссылыгында татар исемнәрен өйрәнүне максат итеп язылган. Глобальләшү шартларында гомуми тел белемендә тел берәмлекләрен аерым анализлау түгел, ә этномәдәният кысаларында тел моделе буларак карау, фәннәр кисешендә барлыкка килгән юнәлештә этнос, тел һәм культура мәсьәләләрен системалы-бәйләнешле рәвештә өйрәнү бүген яңа фәнни нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Әлеге хезмәт, әнә шул максатлардан чыгып, дисциплинаара бәйләнештә телнең этномәдәни тирәлегендә антропонимик берәмлекләрнең үсешен башка төрки телләр белән дә чагыштырып өйрәнүне күздә тота. Автор фикеренчә, этномәдәни тирәлек ул, бер яктан, телнең яшәешен булдырган тирәлек булса, икенче яктан – бер үк телгә, культурага, фольклорга ия булган халыкның уртак мирасы. Димәк, һәр этносның, телнең, җирле культураның үз антропонимик системасы була. Ул система фольклор,

халыкның рухи культурасы белән тыгыз бәйләнештә яши, шул ук вакытта тирә-юнь, кеше, җәмгыять турында мәгълүмат чыганагы да булып тора.

Автор күпсанлы документлар белән эш итә, архив материалларыннан тупланган татарча кеше исемнәренең сүз күрсәткечен әзерли. Һәрбер чор үзенең исемнәре белән билгеләнә. Шул чорга караган исемне фәнни калыпка керткәнче, аны барларга, теркәргә кирәк. Исемнәр индексы нәкъ менә шушы максатны күз уңында тотып әзерләнгән.

Бу гамәлләр эчтәлеге ягыннан хезмәтнең төпле һәм ышанычлы документаль нигезгә таянып эшләнгәнлеген раслый, димәк, аның уңышлы башкарылуына зур өлеш кертә.

Хезмәтнең **беренче бүлеге** *«Телнең этнокультур пространствосында антропонимик проблемаларның теоретик-методологик нигезләренең чагылышы»* дип атала. Биредә антропонимнарга караган мәсьәләләрнең тарих, фольклор, этнография, диалектология фәннәре кисешендә өйрәнелү дәрәҗәсе, бу өлкәдә булган кыенлыклар, киләчәккә бурычлар, перспективалар билгеләнгән. Дөнья күләмендә тел белеме өлкәсендә танылган этнолингвистлар В. фон Гумбольд, Ф.Боас, Э.Сепир, Б.Уорф, Н.Ильич Толстой, Е.Бартминьский, татар теле белемендә – Г.Ф.Саттаров, төрки тел белемендә – Э.Бегматов, Н.И.Егоров, Ш.Жапаров, С.Сакаоглу, А.Шайхулов, Ф.Хисаметдиновалар кебек күренекле галимнәрнең этномәдәни тирәлек хакындагы фикерләре яктыртылган. Аерым алып, бүгенге татар ономастикасын өйрәнүдә Казан төрки-татар ономастика мәктәбенең эшчәнлеге тирән анализлана, аның татар антропонимнарын, региональ топонимияне, поэтик ономастиканы өйрәнү кебек юнәлешләре билгеләнә.

Хезмәтнең **икенче бүлеге** *«Исем бирү йолаларының һәм кеше исемнәренең татар культурасында ономастик экспликациясе»* дип атала. Бу бүлектә исем бирү йолагадәтләренең диалектларда күзәтелгән төрлелеге карала, исем семантикасының потенциалы локаль культурада тулылануы, киңрәк чагылыш табуы ассызыклана, исемнең татар традицион культурасында тоткан урыны билгеләнә. Төрле почмакларга сибелеп яшәгән татар халкының исем бирү йолаларындагы уртак һәм үзенчәлекле якларны барлап, аерып чыгару һәм аларны фәнни анализлап, нәтиҗәләр ясау хезмәтне халыкка якынайта, аны гади укучыга да кызыклы һәм мәгълүматлы чыганак итеп таныта.

Чыннан да, исем бирү йола-гадәтләрен, хәрәкәтләрен аңлаткан лексика исем кушу йоласының, ритуаль символларының телдәге чагылышын аңларга ярдәм итә. Хезмәтнең отышлы сыйфатларыннан берсе шунда: биредә исем кушуда чынбарлыкны яктырткан йола хәрәкәтләре (исем кушу, ат кушу, миңне бетерү, исем алыштыру), йолада катнашучылар, аны башкаручылар (кендек әбисе, бабай әбисе, мулла, инәкә һ.б.), йола предметлары (моржа, тупса, тәрәзә) һәм аларны тәгъбирләгән лексика башка төрки телләрдәге лексик берәмлекләр белән чагыштырып өйрәнелә. Шул рәвешле, автор дөньяны танып белүгә корылган йола структурасы, символлары, предметлары, функциональ мәгънәсе татар халкының рухи һәм матди дөньясын чагылдырып, гомумтөрки һәм мөселман традицияләре нигезендә формалашкан, дигән фикерне ассызыклый. Димәк, татар культурасында исемнәр этномәдәниятнең тамгасы булып, ата-ананың, өлкән буынның теләкләрен яктыртып, дөньяны табигать белән тиңләштереп, борынгыларның рухларына табыну ысулларын ачып, дөньядагы уңай әйбер-күренешләрне арттырып, үлемне кичектерү яки алдарга омтылу, шул рәвешле язмышны яхшыга үзгәртү функциясен үти.

Хезмәттә телнең этномәдәни тирәлеген, ягъни хайван, кош-корт, вакыт, кешенең

эчке һәм тышкы дөньясын, социаль тормышын тәгъбирләгән кеше исемнәре анализлана. Киң мәгънәдә әйләнә-тирәне чагылдырган исемнәр телнең этномәдәни тирәлегендә халыкның мифопоэтик һәм психологик күзаллауларын формалаштыра. Алар кешене физик, психологик, интеллектуль яктан тасвирлый торган исемнәр ияләренең эчке һәм тышкы дөньясын ача. Бу төр исемнәрнең күпчелеге төс компонентлары нигезендә ясалган исемнәрне тәшкил итә, дигән фикергә килә автор. Әлеге исемнәрдә семантик күп мәгънәлелек очраклары теркәлә, кешенең эчке һәм тышкы дөньясын тел чаралары ярдәмендә оештырып, системалаштырып тәгъбирләүгә булышлык иткән мәгънә потенциалы ачыла. Исемнәрдә төс белдерә торган компонентлар кешенең физик үзенчәлекләрен (бит, күз, каш төсе һ.б.) һәм аның психологик халәтен (көчле, бәхетле, акыллы һ.б.) күрсәтә. Кеше исемнәре танып белүнең үзенә күрә социаль моделен булдыруга хезмәт итә, шулай итеп, кешенең социумдагы урынын чагылдыра. Социаль семантика титул атамалары нигезендә ясалган исемнәрдә (Солтангали, Солтангази, Шәехтимер, Ханморат, Ханзаман һ.б.), этноантропонимнарда (үзбәк, башкорт, типтәр, чуваш, чирмеш һ.б.) чагылыш тапса, нинди дә булса шәхескә багышланган исемнәр (Кубрат – Кубрат ханга багышланган; Минтимер – беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиевкә багышланган исем) җәмгыятьнең социаль структурасын, катламнарын, социаль структура кысаларындагы функциональ бәйләнешләрне тәгъбирләүдән гыйбарәт.

Исем бирү йола-гадәтләре, исем семантикасы этномәдәни тирәлекнең аерылгысыз өлеше булган фольклор, ягъни халык авыз иҗатында да анализлана. Татар фольклорының эпик жанрларында кулланылган исемнәрнең борынгы төрки антропонимик системаны тергезүдәге мөһим роле ассызыклана.

Өченче бүлек *«Татар этномәдәни тирәлегендә татар исемнәренең тарихи-генетик катламнары»* дип атала. Бу бүлектә архив материаллары нигезендә тупланган кеше исемнәренең һәрбер чорга хас тарихи алшартлардагы үсеше, аларның семантик, структур-төзелеш үзенчәлекләре гомумиләштерелеп анализлана. Татарларда кулланылган исемнәрнең чыгышы белән төрки, гарәп, фарсы, славян һәм көнбатыш европа телләренә мөнәсәбәтле катламнары аерылып, татар тарихының төрле чорларына хас антропонимик берәмлекләр ышанычлы чыганакларга нигезләнеп тикшерелә.

Фольклор материалларында, диалекталь-этнографик текстларда чагылыш тапкан исемнәрне халыкның рухи мирасы буларак өйрәнү татар культурасының үзенчәлекләрен, аның кыйммәтлекләрен барларга һәм аңларга ярдәм итә. Татар антропонимик системасының формалашуын һәм үсешен башка төрки телләр белән чагыштырып анализлау шулай ук хезмәтнең яңалыгы һәм уңай ягы булып тора.

Кыскасы, **«Телнең этномәдәни тирәлегендә татар кеше исемнәре»** дип аталган монография – бүгенге тел белеменең көн кадагына суккан мәсьәләләрне эзлекле фәнни нигездә тикшереп, нәтиҗәләре галимнәр өчен дә, киң катлау укучылар өчен дә кызыклы һәм файдалы булган максатчан эшчәнлекнең күркәм бер үрнәге.

Татар исемнәре – халкыбызның мирасы. Мирасыбызны армый-талмый барлау, туплау, фәнни яктан тикшерү һәм һәрдаим халык игътибарына җиткереп тору зарур. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре Гүзәлия Хаҗиева тарафыннан язылган әлеге хезмәтне дә авторның әнә шул изге бурычны үтәүгә керткән саллы өлеше дип исәпләргә мөмкин. Аңа алга таба да иҗади уңышлар телик. ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2017

Гавриил Державин истәлеге

Татарстан Республикасы Милли музее фондыннан

Шагыйрь Гавриил Романович Державинның язу өстәле, кәнәфие, кара савытлы язу приборы уникаль әһәмияткә ия булган экспонатлар рәтендә. Кызыл агачтан эшләнгән кара савытлары һәм аерым бүлемтекләре булган тартмачык (шкатулка) та безнең көннәргә килеп ирешкән. Музейда шагыйрьнең алтын сәгате дә саклана. Ул 1894 елда күренекле Казан галиме, төбәкне өйрәнүче А.Ф.Лихачевның коллекциясе белән кергән. Бу сәгать озынча түгәрәк формалы, аның Англиядә эшләнгән эмаль футляры да бар. Г.Р.Державинның башка әйберләре белән музейдагы «Казан губернасы XVIII гасырда» экспозициясендә танышырга була.

Руфия Мөхетдинова *әзерләде.* ■

ЯДКӘРЛӘРГӘ – БЕР ГАСЫР

Татарстан Республикасы Дәүләт архивы фондыннан

1917 елның 1 сентябре

ТӘТЕШ ШӘҺӘР ДУМАСЫ РӘИСЕНЕҢ КАЗАН ГУБЕРНА КОМИССАРЫНА ХАТЫННАН

Шәһәр Думасының 5 сентябрьдәге чираттагы утырышына минем тарафтан шушы мәсьәләләр буенча докладлар кертеләчәк: ... 5)Тәтеш мещан мөселман җәмгыяте вәкилләре Салаватулла Бикмуллинның һәм Хөснетдин Курамшинның А.Серебряков һәм уллары Сәүдә җәмгыяте амбарлары астындагы шәһәр җирләрен Мөселман җәмгыяте зиратын киңәйтү өчен түләүсез файдалануга бүлеп бирүне сораулары турында...

Тр ҮДА ТСД, ф.1246, тас.1, э.16, 28б.

1917 елның 11 сентябре

КАЗАН ГУБЕРНА АЗЫК-ТӨЛЕК УПРАВАСЫНЫҢ МАМАДЫШ ӨЯЗ КОМИССАРЫНА ХАТЫ

Губерна азык-төлек управасының яшелчәләр әзерләү бүлеге Сезгә шуны хәбәр итә: Азык-төлек министрлыгының Казан губернасына хәрәкәттәге армияне киптерелгән һәм гадәти хәлдәге яшелчәләр белән тәэмин итүгә бик зур наряд җиткерүе сәбәпле, яшелчәләр әзерләү бүлеге Казан губернасыннан гомумән бөтен яшелчәләрне чыгаруны тыюны, аларның ирекле әйләнешен Казан губернасы чикләрендә генә рөхсәт итүне тиеш таба. Шуңа күрә бүлек Сездән агымдагы ел яшелчә уңышын Губерна азык-төлек управасының һәр очракта махсус рөхсәтеннән башка губернадан чыгартмас өчен иң катгый чаралар күрүне сорый. Әгәр дә инде губернадан үз белдекләре белән яшелчә чыгаручылар ачыкланса, андый затларны җавапка тартырга, ә яшелчәләрен реквизицияләргә, Казан губернасы чикләрендә яшелчәләр ташуга тоткарлыклар тудырмаска кирәк.

Волость комиссарларына бу турыда кичекмәстән хәбәр итәргә.

Төп нөсхәсе белән дөрес:
Өяз комиссары вазыйфаларын башкаручы имза

ТР ҮДА ТСД, ф.5599, тас.1, э.1б, 41б. Күчермә.

Документлар урыс теленнән тәрҗемә ителеп бирелә.


Копія.

КАЗАНСКАЯ
ГУБЕРНСКАЯ
Продовольственная
Управа
Отдѣлъ
Заготовки овощей
12 Сентября 1917 г.
№ 1017.

Г. Мамадышскому Уѣздному Комиссару.

Г. Товарищъ Министра Продовольствія Зельгеймъ телеграммой отъ 6 сего Сентября за № 1597 циркулярно сообщилъ Губернскимъ Продовольственнымъ Комитетамъ, что выработка картофельнаго крахмала и продуктовъ его переработки будутъ производиться по планамъ и подъ контролемъ Министерства Продовольствія почему надлежитъ не препятствовать пріемкѣ картофеля частными и кооперативными крахмальными и крахмально паточными заводами, при чемъ продовольственнымъ органамъ предоставлено право наблюденія, чтобы пріемка картофеля заводами производилась не дороже предѣльной цѣны установленной для Казанской губерніи въ 1 р. 90 к. за пудъ.

Сообщая объ изложенномъ Отдѣлъ заготовки овощей проситъ Уѣздную Продовольственную Управу принять означенное телеграфное распоряженіе Г. Товарища Министра Продовольствія къ точному и неуклонному исполненію и немедленно объ этомъ поставить въ извѣстность Волостныхъ и Сельскихъ Комиссаровъ уѣзда. Членъ Губ. Прод. Управы № Дѣлопроизводитель №

Съ подлиннымъ вѣрно:

И. д. Уѣзднаго Комиссара

1917 елның 12 сентябре

КАЗАН ГУБЕРНА АЗЫК-ТӨЛЕК УПРАВАСЫНЫҢ МАМАДЫШ ӨЯЗ КОМИССАРЫНА ХАТЫ

Азык-төлек министры Зельгейм иптәш 6 сентябрьдәге 1597 нче телеграммасы белән губерна азык-төлек комитетларына күрсәтмә рәвешендә бәрәңге крахмалын җитештерү һәм аны эшкәртү продуктларын әзерләү Азык-төлек министрлыгы планы буенча һәм күзәтчелегендә гамәлгә ашырылачагын хәбәр итте. Шуңа күрә шәхси һәм кооператив крахмал һәм крахмал-патока заводларының бәрәңге кабул итүенә тоткарлык тудырмаска кирәк. Шул ук вакытта азык-төлек органнарына заводларның бәрәңгене Казан губернасы өчен билгеләнгән потына 1 сум 90 тиеннән югарырак бәядән кабул итмәүләрен күзәтеп тору хокукы бирелгәнлеген дә истә тоту мөһим.

Бу хакта хәбәр итеп, яшелчәләрне җитештерү бүлеге өяз азык-төлек идарәсеннән иптәш азык-төлек министрының телеграф күрсәтмәсен төгәл һәм тайпылышсыз үтәүне, бу турыда өязнең волость һәм авыл комиссарларына җиткерүне сорый.

Өяз комиссары вазыйфаларын башкаручы имза

ТР ҮДА ТСД, ф.5599, тас.1, э.1б, 42б. Кучермә.

1917 елның 18 сентябре

МАМАДЫШ ӨЯЗ ХӘРБИ БАШЛЫГЫНЫҢ ӨЯЗНЕҢ ВОЛОСТЬ КОМИТЕТЛАРЫНА ХАТЫ

Волость комитетларының күпчелеге орден һәм медальләр белән бүләкләнгән отставкадагы солдатларның, сугышта һәлак булган яки кайткач үлгән солдат хатыннарының үтенечләре буенча Георгий тәреләре һәм медальләр өчен нинди пенсия билгеләүне ачыклау максатында әлеге үтенечләрне Казна палатасына һәм башка учреждениеләргә юлларга мәҗбүр. Нәтиҗәдә, бу артык хатлар язышуга һәм пенсия билгеләү вакытының сузылуына китерә. Киләчәктә хәрби бүләкләр буенча пенсия билгеләүгә кагылышлы үтенечләрне миңа тапшырылган Идарәгә җибәрүне сорыйм.

Хәрби башлык өчен,
хәрби чор чиновнигы имза

ТР ҮДА ТСД, ф.5599, тас.1, э.1б, 48б.

Документларны басмага ТР Дәүләт архивы секторы мөдире ***Римма Садыйкова*** *әзерләде.* ■

E-mail: prm.archive@tatar.ru
www.arhiv.tatarstan.ru

Безнен мирас №9 сентябрь 2017

МӘРҖАНИЛӘРГӘ ҺӘЙКӘЛ

Бөтендөнья татар конгрессының VI корылтае делегатлары Ш.Мәрҗани һәм М.Галәү һәйкәлләре алдында

Генераль директоры Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин җитәкчелегендәге «Таттелеком» ААҖ тарафыннан Арча районының Ташкичү авылында атаклы мәгърифәтче, тарихчы Шиһабетдин Мәрҗанигә һәм аның туганы, беренче тарихи роман авторы Мәхмүт Галәү-Мәрҗанигә багышлап һәйкәлләр куелды. Мәктәп эчендәге бер бүлмәдә Мәрҗаниләр һәм аларның даирәсе турында мемориаль музей булдырылды. Зур тарихи мирасны чагылдырган әлеге объектларны рәсми рәвештә ачу тантанасы булмаса да, ташкичүлеләр инде беренче мөхтәрәм кунакларны – Бөтендөнья татар конгрессының VI корылтае делегатларын кабул итәргә өлгерде. ■

Ташкичү мәктәбенең тарих укытучысы Фәнил Кашшапов делегатларга Мәрҗаниләр турында сөйли

قوياش

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1917 елның сентябрь ае

Сәхифәне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Хәбәрсез югалды

Казан мөселман комитетының килештерү комитеты Гайшә Мөхәммәдрәхимованың эшен карап, аны иреннән аерып, талак кәгазе бирергә карар бирде. Ире, Казан губернасының крестьяны Хәбибулла Хыялетдин углы Галиев, 25 яшьләрендә булып, 1912 елдан бирле Себердә, Йәнәсәй губернасы Ачинки өязенең Даурски авылына вольное поселениегә киткән. 1915 ел башында Казанда булганнан соң, янә китеп, һичбер хәбәре юк, кайбер кеше үлгән хәбәрен дә әйтте. Күргән-белгән кеше булса, хәбәр итүләрен үтенәбез.

Кояш. – 1917. – №1158. – 3 сент.

Бөтен мөселман гаскәриләренә үрнәк

164 нче полк солдатларыннан Шәрәфетдин Җәмалетдинов 1917 нче ел 14 нче августта пороховой вакыйгалары вакытында шартлау һәм янгынның оясы булган артиллерийский складлар янында каравылда булды. Тирә-якта снарядлар шартлаган, кешеләр үлгән, төрлесе төрле якка качып беткәннәр, тик Җәмалетдинов кына, начальник гарнизон әмере булганга кадәр, утыз сәгать буенча урынын ташлап китмәгән, өстенә йөкләнгән мөкатдәс вазыйфаны үтәгән. Командующий войсками шушы турыда Хәрбия вәзиренә хәбәр иткән. Вәзир, Җәмалетдиновка үзенең вазыйфасын шундый баһадирларча үтәгәнлеге өчен, 4 нче дәрәҗә Георгиевский медаль бирергә әмер чыгарган. Казан мөселман хәрби комитеты үзе тарафыннан мөхтәрәм Җәмалетдиновка бөтен мөселман солдатлары исеменнән рәхмәт укый, Җәмалетдинов белән башка милләтләр алдында мактана һәм аңар үзе тарафыннан саф алтыннан ясалган махсус жетон тәкъдим итә.

Гаскәриләргә гает намазы

Казан хәрби ахуны Гатаулла әфәнде, Корбан намазының Хан мәсҗеде төбендә укылачагын начальник гарнизонга мәгълүм итеп, рус бәйрәмнәрендә бирелә торган бәйрәмлек акчаны мөселман гаскәрләренә мөселман бәйрәмнәрендә җибәрергә үтенеп, моннан башка, гает көнендә мөселман гаскәрләренә аш пешертү өчен, корбан ите җыеп бирүне үтенеп, җәмгыяте хәйриягә мөрәҗәгать кылган.

Яңа мөселман матбагасы

Болак буендагы Никитин матбагасын «Гасыр» көтебханәсе сатып алган. Рус хәрефләре вә машиналары мөкәммәл булган бу матбагага мөселман хәрефләре алынып, үктәбер башыннан мөселман матбагасы буларак эшли башлаячактыр.

Кояш. – 1917. – №1161. – 10 сент.

Даталар иске стиль белән бирелә.

Сөембикә манарасы төбендә гает

Гает көнне кояш чыгу белән Казан вә бистәләрендәге мөселман гаскәрләр Воскресенски урамны яңгыратып, төркем-төркем тәкбир әйтеп, Сөембикә манарасына таба агылдылар вә һәр каюсы намаз укыр өчен тәгаен ителгән, манараның гареб тарафындагы урынга, Хәрби шура вә Хәрби комитет әгъзалары, гаскәри имам вә мөәзин тарафыннан тәртип белән урынлаштырылдылар. Сәгать 8гә якынлангач, карый Вәли әфәнде тарихи азанны әйтү өчен манарага менеп китте. Бу вакыт 95 нче полктагы мөселман гаскәрләр офитсәрләре илә полкта алтынлы язулы яшел вә кызыл байраклар күтәреп, тәкбир укып килделәр. Электән килеп сафка утырган гаскәриләр, аякка торып, аларны тәкбир белән каршы алдылар. Болар урынлашып бетүгә, 164 нче полктагы гаскәрләр музыка вә шундый ук тәртип вә байраклар белән тәкбир укып килделәр. Болар да, тәкбир белән каршы алынып, сафларга урынлаштылар. Бу эшләр тәмам булганнан соң, ахун Гатаулла әфәнде Баһаветдин тарафыннан манарадан кыскача тарихи бер нотык сөйләнде.

Сәгать 8гә чирек калганда манараның 4 нче катындагы тәрәзәсеннән чыккан тарихи азан, пәйгамбәребезгә (с.г.в.) салават тавышы иртәнге саф вә тын һава эчендә бөтен күк вә этрафка яңгырады. Карый әфәнденең гүзәл вә саф тавышы вә Мисыр мәкаме белән әйтелгән бу азан, вә салават күңелләргә тәэсир итте, вә күңелләрне нечкәртте, күзләрдән яшьләр агызды. Моның соңында ук бөтен җәмәгать тарафыннан беравыздан әйтелгән тәкбир тавышы бөтен этрафны яңгыратты. Намаз укылып тәмам булган соңында имам тарафыннан татарча хөтбә, берничә аять Коръән укылып, дога әйтелде.

Моның соңында бөтен гаскәриләр саф-саф тезелеп, алда музыка булганы хәлдә, гаять тәртип белән Юнысовлар мәйданына төште. Юлда музыка уйнау, гаскәрләрнең милли җырлар җырлавы, туктап-туктап тәкбир әйтү – бер-бере белән аралашу булды. Юнысовлар мәйданына кереп урынлашканнан соң, өч мәртәбә тәкбир әйтелде. Ахун Гатаулла әфәнде бәйрәм белән вә Сөембикә манарасы янында укылган беренче гает белән гаскәриләрне тәбрик итте. Моның соңында Хәрби шура, Мөселман хәрби комитеты, мөселман гаскәриләре вә Сембер мөселман хәрби комитеты исеменнән берәр әфәнде тәбрик итте. Бу мәрәсим тәмам булганнан соң, гаскәриләр чәйханәләргә таралдылар.

Орёлны төшерү

16 нчы сентябрьдә Сөембикә манарасы башындагы орёл рәсеме дә төшерелде. Элек төбеннән кисеп алырга уйланган бу орёлны кисеп алып булмады, сүтеп алынды. Бу эш кичке сәгать 7 ярымнарга кадәр сузылды. Тамашага халык килгән иде. Крепость эче мөселманнар илә тулы иде. Орёлны урыннан төшергәндә музыка уйнап торды. Эш бик тәртип белән үтте. Бу хәл русларның да дикъкатен җәлеп итте.

Кояш. – 1917. – №1163. – 21 сент.

Рус гимназиясендә мөслимә учительница

Бишбалтаның Пономарева кызлар гимназиясенә, немец теле мөгаллимәсе буларак, Динә туташ Булатова кабул ителгән. Бу, ислам дине дәресләреннән башка, рус гимназияләрендә Казанда әүвәлге мөслимә мөгаллимәдер.

Кояш. – 1917. – №1166. – 28 сент. ■

СЕНТЯБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 1 августта Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары яңа сезонның беренче эш көненә җыелды. Баш режиссер Фәрит Бикчәнтәев театрда эшли башлаячак яңа артистларның, аерым алганда Алмаз Борһанов, Эльвир Сәлимов һәм Айгөл Шәкурованың исемнәрен атады.

● 2 августта YI Бөтендөнья татар корылтае эшли башлады.

● 5 августта Теләчедә Бөтендөнья татар конгрессының VI корылтае делегатлары катнашында Сабан туе узды.

● 7 августта Татарстан Язучылар берлегендә бер төркем каләм әһелләре – Разил Вәлиев, Данил Салихов, Лирон Хәмидуллин, Зиннур Мансуров, Вахит Имамов, Марсель Галиев, Гәрәй Рәхим, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла, Хәбир Ибраһим, Рәмис Аймәт, Ләбиб Лерон, Диләвер Осман, галим Индус Таһиров, «Безнең мирас» журналы хезмәткәре Ленар Гобәйдуллин Төркиядә яшәп иҗат итүче күренекле татар галиме Надир Дәүләт белән очрашты.

● 9 августта Актанышта урып-җыюның тәүге тантанасы – Кызыл олау бәйрәме булып узды.

● 10 августта Зәй районының Имәнлебаш авылында ТР Диния нәзарәте рәисе урынбасары Илфар Хәсәнов, Татарстан Президенты каршындагы Мәдәнияткә ярдәм фондының башкарма директоры Нурия Һашимова, район башлыгы Разиф Кәримов, галимнәр, дин әһелләре катнашында мәгърифәтче, дин галиме Таҗетдин Ялчыгол укулары узды.

● 11 августта Азнакай районының атаклы Чатыр тавында төрки халыкларның VII Халыкара «Чатыр тауда җыен» халык иҗаты фестивале узды. Бәйрәмдә катнашучылар алдында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары Ассамблеясы Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин чыгыш ясады.

● 14 августта Яшел Үзән районының Бәчек авылында «Авыл көне» узды. Бәйрәм кысаларында Коръән уку бәйгесе һәм гармунчылар ярышы оештырылган иде. Шунысын искәртү кирәк – Коръән уку бәйгесе мәшһүребез Габдулла Тукайның апасы Сәҗидә торган нигездә булды.

Бәчектә шагыйрьнең апасы Бибисаҗидә

яшәгән һәм, шушында вафат булып, авыл зиратында җирләнгән. Бибисаҗидә (1877-1956) – Арча районы Өчиле авылы мулласы Зиннәтулланың беренче хатыны Латифадан туган төпчек кыз. Латифа үлгәннән соң, Зиннәтулла бүтән хатынга өйләнә һәм аларның кызлары Бибимәмдүдә – Габдулла Тукайның әнисе туа. Бибисаҗидәнең кызы Өммеханияне Бәчеккә укытучы итеп җибәрәләр, ул үзе белән әнисен һәм сеңлесе Әкълимәне алып килә. «Авыл көне» бәйрәме Бибисаҗидә ханым яшәгән йорт нигезе янында узды. «Менә шул вакыттан бирле ул апа минем күңелемә фәрештә булып утырган да калган. Күңелем аны уйлый башлады исә, хәзер күземә ап-ак саф бер фәрештә күренә», – дип искә ала Саҗидә апасы турында Габдулла Тукай.

● 16 августта Казанның Зур Кызыл урамында – Казан дәүләт консерваториясе каршындагы скверда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында бөек композиторыбыз, Татарстан Республикасы гимны авторы Рөстәм Яхинга һәйкәл ачылды. Тантананың рәсми өлешендә республика җитәкчеләре – Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Казан шәһәре мэры Илсур Метшин һәм башкалар катнашты.

● 18 августта Мөслимдә һәм районның Элемтә авылында яңа мәчет ачылды. Тантанада катнашкан кунаклар арасында «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон да бар иде.

● 14-18 августта Төркиянең Истанбул шәһәрендә Төрки дөньяның яшь язучылары җыены булып узды. Әлеге чарада Татарстаннан яшь шагыйрьләр Эльвира Һадиева, Фәнил Гыйләҗев һәм яшь прозаик Айгөл Абдрахманова катнашты.

● 15-22 августта Буа театрында комедия жанрына нисбәтле I театраль остаханә булып узды. Чарада катнашучылар арасында «Безнең мирас» журналы хезмәткәре, драматург Рәдиф Сәгъди дә бар иде.

● 21-25 августта «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре Ләбиб Лерон һәм Ленар Гобәйдуллин Курган өлкәсенең Сафакүл һәм Әлмән районнарында булып, хакимият җитәкчеләре, шулай ук төбәкне өйрәнүчеләр белән очрашты. ■

Мирасворд

Әхәт Гаффарның 1978 елда чыккан повестьлар китабы



Кәрим Тинчурин драмасы

... -ачык

Галимҗан ... (дин галиме, педагог)

Дөнья тирәли өч тапкыр әйләнеп чыккан инглиз сәяхәтчесе

Мате ... (мадьяр әдибе)

Пассажир вагонында аерым бүлмә

Һади Такташ поэмасы

Драматург Шаһиморат ... .

... Орджоникидзе

Жырчы Георгий ...

Телеграф уйлап тапкан француз инженеры

Нурихан Фәттах романы

Салисә Гәрәеваның 1979 елда чыккан шигырьләр җыентыгы

Шәриф Камал хикәясе

Фәридә Кудашева туган авыл

Балтач районындагы авыл

Абиссиниядә (хәзерге Эфиопия) феодаль кенәз

Фукс, Либкнехт

Матур, сөйкемле (иск.)

Бала чыгармаган, ялгыз кош (диал.)

Сәгыйть Рәмиев шигыре

Шагыйрь ... Сибгатуллин

... де Мопассан

Легендар крейсер

Монголиядә административ-территориаль берәмлек

Алтын Урдада, татар ханлыкларында хан балаларын тәрбияләүче

Кәрим ... (Уфада яшәүче журналист, җәмәгать эшлеклесе)

Борынгы уртак баба, кардәшлек нигезендә оешкан кешеләр төркеме

Шагыйрь ... Ахунҗанов

Сатурн иярчене

Борынгы Рим армиясендә ярдәмче атлы отряд

Ноталар өстенә дуга рәвешендә куелган билге

Халык ... иҗаты

... Шопов (македон шагыйре)

Караиделнең сул кушылдыгы

Фәйзуллин, Тумашев

... -зыгы

Камил Мотыйгый пьесасы

... -тояк

Гали, Шәриф

Кытайда императорлар династиясе

8 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: Күәм, «Чүкеч», Фәиз, ампир, рә, офсет, Укәк, Шәфигуллин, накат, Өнәр, Аспарух, Дәрвиш, ару, Мин, Ногман, ода, Шанду, иҗек, «Авадзи», Ра.
Өстән аска: «Вөждан», Үтәмеш, сәнә, Рог, Мозаффаров, кам, Кио, Имашев, Гаташ, Нәҗар, Лут, нида, чуар, эпизод, Мәүлә, Дубин, кип, ки, юрама, Имәни, Ури, чор, шхуна.

Рәис Габдулла төзеде.

Газиз Кашаповка куелган бюст. 1992 ел

«Безнең мирас»

елъязмасы / сентябрь

630 ел элек (1387)

Көз башында Туктамыш хан, биниһая зур гаскәр туплап, Мавараәннәһергә – Аксак Тимергә каршы яу сәфәренә кузгала.

620 ел элек (1397)

Идегәй морза бөтен Алтын Урда гаскәрен үз кул астына туплый һәм Туктамыш ханны Алтын Урдадан куып җибәрә.

420 ел элек (1597)

Россиядә «крепостное право» тәртибе кертелә. Авылдагы хезмәт ияләре, җирбиләүчеләр карамагына беркетелеп, яшәгән урыннарында калырга мәҗбүр ителәләр.

85 ел элек (1932)

Әстерхан шәһәрендә татар драма театры ачыла.

80 ел элек (1937)

Ел дәвамында ТАССР Язучылар берлеге идарәсенең өч составы да (беренчесе Кави Нәҗми җитәкчелегендәге состав була, аңа алмашка килгән Ләбиб Гыйльми рәислегендәге идарә, аннары Мирсәй Әмир җитәкләгән идарә) кулга алына.

75 ел элек (1942)

«Совет әдәбияты» журналында Фатих Кәримнең «Саратский яшел гармун» шигыре дөнья күрә.

50 ел элек (1967)

15 сентябрьдә татар совет шагыйре Әхмәт Ерикәй (1902-1967) вафат була.

«Казан утлары» журналында Атилла Расихның «Ямашев» романы басыла башлый.

45 ел элек (1972)

15-22 сентябрьдә Чувашстанның Батыр районында татар һәм чуваш әдәбияты атналыгы булып уза.

25 ел элек (1992)

1 сентябрьдә язучы Газиз Кашаповның (1942-1991) туган авылында (Аксубай районы, Яңа Үзи) әдипкә бюст һәм музей ачыла.

Журналга ***Марат Закир*** *әзерләде.* ■



СЕНТЯБРЬ 2017

Историческое наследие: «История турков и татар». Ахматзаки Валиди; «Состояние эмигрантов». С.Габди; «Подлесный Утямыш: кто и когда основал деревню?» Ф.Ислаев; «Каменные надписи Атни». Р.Марданов, И.Хадиев; «Сколько жизней унесло...» А.Казаков; «Эдуард Ганиев: «Показать пример – это наш долг»; «Летопись родного края». М.Хасанов.

Татарский мир: «Достойный сын народа». Р.Шайдуллин.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Г.Ибрагимов; «Забытая семья Баруди». Х.Бадиги.

Литературное наследие: «Сохранилась ли могила писателя?» Л.Хамидуллин; «Имай Насири в наших сердцах»; «Чувства, пробудившиеся на острове»; «Гордость». Ф.Гильми.

Эхо войны: «Наше самое мощное и сильное оружие». А.Шамова.

Художественное наследие: «Заливаясь кураем, играя на гуслях и дутаре...» Э.Каюмова.

Слово – украшение языка: «Словарь национальных терминов». А.Тимергалин; «Благовоспитанный человек не будет искажать свой язык». Р.Юсупов; «Наши имена – наследие народа». А.Тимерханов.

100 лет назад..: «Казанские вести» в газете «Кояш»: сентябрь 1917 года.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

SEPTEMBER 2017

Historic heritage: «The history of the Turkish and the Tatars» by Akhmatzaki Validi; «Worries of emigrants» by S.Gabdi; «Podlesniy Ytyamish: who did the village establish and when did it take place?» by F.Islaev; «The stone signs of Atnya region» by R.Mardanov, I.Khadiev; «What a plenty lives were taken away...» by A.Kazakov, L.Khalimullina; «Edward Ganiev: «Being an example is our duty»; «The chronicle of the motherland» by M.Khasanov.

Tatar world: «The respectable son of his people» by R.Shaydullin.

Religious heritage: «The Islamic world» by Gabdurashit Ibragimov; «Forgotten the Barudy's family» by Kh.Badigi.

Literary heritage: «Was the writer's grave kept all right?» by L.Khamidullin; «Imay Nasiri is in our hearts»; «The feelings awaken the island»; «The pride (story)» by F.Gilmi.

The echo of the war: «The greatest weapon of ours» by A.Shamova.

Artistic heritage: «Playing the kuray, making a noise with the gusli and dutar» by E.Kayumova.

Word is a language's decoration: «Dictionary of national terms» by A.Timergalin; «Well-bred man won't have a wish to spoil his language» by R.Yusupov; «Our names are our people's dignity» by A. Timerkhanov.

100 years ago...: «Kazan news» is in the «Koyash» newspaper: September of 1917».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.

Төзәтмә:

Журналның 8 нче санындагы «Ул безнең өчен үле иде инде» дигән материалның икенче битендәге ахыргы язма авторының исеме (Гомәр Гали) һәм чыганагы («Яңалиф», №12, 1931), техник сәбәпләр аркасында, төшеп калган. Укучыларыбыздан әлеге ялгыш өчен гафу үтенәбез.

1 сентябрь – Мөбарәк Гыйд әл-Әзъхә яки Корбан гаете, Корбан бәйрәме. Җөмлә әһле Исламга мөбарәк, Гает корбанлыклары кабул булсын! Һәр фарыз намаздан соң Тәшрикъ тәкбирләре әйтеләчәк, иншәАллаһ.
2, 3, 4 сентябрь – Тәшрикъ көннәре.

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

«Чыңгызхан нәселен дәвам иткән Батый хан, җиңелүнең ни икәнен белмичә, XII гасыр тирәсендә үлеп китә. Батый чоры, ул чагындагы елъязмалар һәм башка археологик документлар ярдәмендә, тарихка мәңгегә кереп кала. Чыңгызхан империясе исә әлегәчә дөньядагы иң зур империя булып санала».

Локман Закир. «Батыйга бәйләнү»

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132
(П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
- *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә*

электрон версия

«БЕЗНЕҢ МИРАС» *журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман ур., 19; 29/11) кибетеннән, «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*